ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ



# «ЙОСЫФ КИТАБЫ»

## тасвирламалар

«МИЛЛИ КИТАП»

«ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ»

# «ЙОСЫФ КИТАБЫ»

«Кыйссаи Йосыф» поэмасының
Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә
саклана торган кулъязмаларына тасвирламалар

Казан
«Милли китап» нәшрияты
2026

**УДК 821.512.145.09+091(=512.145:=411.21)**
**ББК 83.3(2Рос=Тат)3+78.33**
**Й68**

*Кулъязмаларны тасвирлаучы*
*һәм махсус мәкаләләр авторы –*
*археограф, текстолог*
*Раиф Мәрданов*

Й68 **«Йосыф китабы»: «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә саклана торган кулъязмаларына тасвирламалар. Тулыландырылган икенче басма** / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2026. – 194 б. – («Татар археографиясе» сериясе; 37 нче китап).

ISBN 978-5-88473-113-4

Китапта борынгы язма әдәбиятыбыз ядкяре – мәшһүр шагыйрь Кол Гали иҗат иткән «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә саклана торган, XVII–XX гасырларга караган 43 берәмлек кулъязма күчермәсенең тасвирламалары һәм XVII гасыр кулъязмасы турындагы мәкалә тәкъдим ителә.

**УДК 821.512.145.09+091(=512.145:=411.21)**
**ББК 83.3(2Рос=Тат)3+78.33**

© Мәрданов Р.Ф., 2026
© «Милли китап» нәшрияты, 2026

# КОЛ ГАЛИ ИҖАТ ИТКӘН «КЫЙССАИ ЙОСЫФ» ӘСӘРЕНЕҢ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕНДӘГЕ КУЛЪЯЗМА КҮЧЕРМӘЛӘРЕ

Идел буе Болгар дәүләте чорындагы шагыйрь Кол Гали XIII гасыр башында (1212, 1233 елларда) иҗат иткән «Кыйссаи Йосыф» әсәре хаклы рәвештә милли әдәбиятыбызның чишмә башы дип санала. Элгәреге бай төрки фольклорга, әдипләрнең шигъри тәҗрибәләренә нигезләнгән зур күләмле Йосыф кыйссасы бөтен төрки халыкларның язма әдәбиятларында әһәмиятле урын били.

Дини сюжетка нигезләнгән «Кыйссаи Йосыф»ны Идел-Урал буйларында яшәгән татарлар гасырлар дәвамында укып, әсәр геройлары белән бергә хәсрәтләнгәннәр һәм куанганнар, юаныч һәм сабак алганнар. Бөек әсәрнең сихри һәм шигъри куәте татар һәм, гомумән, төрки телләрдәге тугандаш халыкларның әдәби үсешләренә гаҗәеп зур йогынты ясаган.

Бу китап элек-электән әдипләрнең һәм галимнәрнең игътибарын җәлеп иткән. Әүвәлрәк аның тәэсирендә һәм аңа ияреп бихисап шигъри әсәрләр иҗат ителгән булса, «Кыйссаи Йосыф» турында соңгырак чорда күп фәнни хезмәтләр, китаплар һәм мәкаләләр язылган. Кыйссаның текстын күп гасырлык өстәмәләреннән аерып, камилләштерү максатында XIX гасырның беренче чирегендә шагыйрь Габдерәхим Утыз-Имәни тырышлык куйган. XX гасырда әсәрне фәнни яктан тәфсилләп һәм җентекләп өйрәнү белән күп галимнәр шөгыльләнгән. Габдрахман Таһирҗанов, Җәвад Алмаз, Сәгыйть Исәнбаев, Хисам Мөхәммәтов, Шакир

Абилов, Миркасыйм Госманов, Нурмөхәммәт Хисамов, Фазыл Фәсиев, Резеда Ганиева һ.б. галимнәр, «Кыйссаи Йосыф»ны төрле яклап һәм комплекслы өйрәнеп, аның безнең җирлектә иҗат ителгәнлеген күп дәлилләр белән расладылар. Татар галимнәре һәм археографлары тарафыннан «Кыйссаи Йосыф» әсәренең XVII–XIX гасырлардагы йөзләрчә кульязма күчермәләре эзләп табылды, алар фәнни китапханәләрдә һәм музейларда саклана. Ә XIII гасыр башында иҗат ителгән Йосыф кыйссасының элеккерәк күчермәләре табылмавы – күптөрле тарихи, иҗтимагый һәм табигый сәбәпләргә бәйле. Кульязмаларының сакланышында өзеклек булса да, бу әсәр даими рәвештә бары тик кульязма хәлендә буыннан-буынга күчә килеп, хәзергәчә ирешкән. «Кыйссаи Йосыф»ның 1917 елга хәтле сиксәннән артык басмасы дөнья күргәнлеге[1] дә аның искиткеч популярлыгын дәлилли. Аларның тиражлары да зур булган, мәсәлән, бертуган Кәримевләр матбагасында 1909 елда 11400 данә, 1911 елда 6000 һәм 1915 елда 5000 данә басылган[2].

«Кыйссаи Йосыф», тарихтагы катлаулы дәверләрне халкыбыз белән бергә кичеп, аның рухи байлыгын, әдәбиятка һәм китапка карата тирән хөрмәтен, күңел җылысын һәм мәхәббәтен саклап килгән. Бу әсәр – хәзерге татар халкын борынгы чорлар белән тоташтырып тора торган могҗизалы алтын җеп бәрабәрендә кадерле һәм бик кыйммәтле.

---

[1] Җәвад Алмаз «Кыйссаи Йосыф» әсәренең «1841–1917 еллар эчендә Казанда 80 мәртәбәдән артык басылып» чыкканлыгын белдергән (Алмаз Җ. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» дастаны // Совет әдәбияты. – 1960. – №2. – Б. 98). 1983 елда чыккан китапта поэманың 1839–1917 елларда нәшер ителгән 76 басмасының исемлеге бирелгән (Кол Гали. Кыйссаи Йосыф (Йосыф турында кыйсса) = Кул Гали. Кысса-и Йусуф (Сказание о Йусуфе) / төп текстны (транскрипцияне) әзерләүче, кереш мәкаләне, искәрмә һәм аңлатмаларны, кульязмаларның тасвирламасын язучы Ф.С.Фәсиев. – Казан: Татар. китап нәшр., 1983. – Б. 494–504).

[2] Мирдиянова Г. Татарская учебная книга конца XVIII – начала XX в.: дисс. ... канд. истор. наук. Том 2. Приложение: «Репертуар татарской учебной книги 18 в. – 1917 г.» – Казань: ФГБОУ ВО «КазГИК», 2020. – С. 537, 543, 555. – (На правах рукописи).

«Кыйссаи Йосыф» поэмасының 1983 елда Татарстан китап нәшриятында зур форматта, 544 бит күләмендә басылып чыгуы[3] – милли-мәдәни тарихыбызның XX гасырдагы иң зур вакыйгаларыннан берсе булды. Бу китапта поэманың тулы төп тексты, хәзерге татар әдәби теленә шигъри күчермәсе һәм рус теленә сүзгә-сүз тәрҗемәсе, шулай ук бай фәнни белешмә мәгълүмат тупланган. Әлеге мәртәбәле хезмәтне ул вакыттагы СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Фазыл Фәсиев башкарган. Галимнең сокландыргыч тырышлык нәтиҗәсе замандашларыбызга, шулай ук киләчәк буыннарның тел-әдәбият галимнәренә, текстологларына һәм археографларына фидакяр иҗади хезмәт үрнәге булып тора.

Бу поэма фәнни яктан тирәнтен өйрәнелгәнлектән, без мәсьәләнең ул җәһәтенә кагылмыйча, әсәрне гасырдан-гасырга ирештергән төп чыганаклары – кулъязма күчермәләренә игътибар юнәлтәбез.

Гыйльми китапханәләрдәге, чит илләрдәге һәм галимнәрнең үз кулларындагы «Кыйссаи Йосыф» нөсхәләре 1960 нчы елга барлыгы 33 күчермәдә билгеле булган. Шуларның унысы тулы текстлы, калганнары тулы түгел, кайберләре исә берничә генә биттән торган[4]. 1962 елда әсәрнең 39 күчермәсе турында сүз барган[5]. 1960 нчы еллар башыннан фәнни һәм археографик эзләнүләрнең көчәюе сәбәпле, әсәрнең шактый нөсхәләре табылган. Нәтиҗәдә, 1980 елда

---

[3] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф (Йосыф турында кыйсса) = Кул Гали. Кысса-и Йусуф (Сказание о Йусуфе) / төп текстны (транскрипцияне) әзерләүче, кереш мәкаләне, искәрмә һәм аңлатмаларны, кулъязмаларның тасвирламасын язучы Ф.С.Фәсиев. – Казан: Татар. китап нәшр., 1983. – 544 б.

[4] Алмаз Җ. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» дастаны // Совет әдәбияты. – 1960. – №2. – Б. 101–102.

[5] Алмаз Дж. «Киссаи Юсуф» Али: сводно-сличительный текст списков поэм, перевод, словарь и исследования. – Казань, 1962. – Научная библиотека им. Н.И.Лобачевского Казанского (Поволжского) федерального университета. Восточный сектор Отдела рукописей и редких книг, рукоп. «5102т». – С. 66.

161 нөсхә кулъязмасы фәнгә мәгълүм иде[6]. Алар Идел-Урал җирлегендә күчерелгәннәр. Археографик эзләнүләр дәвам итү белән бергә, әсәрнең кулъязма нөсхәләре елдан-ел табылып торды. Галим Миркасыйм Госманов 1994 елгы китабында Кол Гали поэмасының 200-гә якын күчермәсе бар дип белдерде[7]. 1980–1998 еллар арасында «Кыйссаи Йосыф» күчермәләренең табылуы һәм аларның гомуми исәбе турында без дә яздык. Ягъни, 1986–1991 елларда Казан дәүләт университетының Горький өлкәсендә эшләгән фәнни-археографик экспедицияләрендә поэманың утызга якын кулъязмасы табылуын, Татарстан Фәннәр академиясе галимнәре тарафыннан да 1980 елдан соң унбишләп яңа табыш өстәлгәнен һәм 1992–1998 елларда Татарстан Республикасы Милли китапханәсе белән Казан дәүләт университетының берләштерелгән фәнни-археографик экспедициясе эшчәнлеге нәтиҗәсендә мәшһүр әсәрнең тагын 15 нөсхә күчермәсе табылганын исәпкә алып, 1998 елда «Кыйссаи Йосыф» кулъязмасының фәнни даирәләргә барлыгы 220 тирәсе күчерелмәсе билгеле дип белдергән идек[8]. Поэманы өйрәнгән әдәбият галимнәре дә ул елларда «Кыйссаи Йосыф»ның 200-дән артык күчермәсе бар дип яздылар[9]. Әлеге саннар «Кыйссаи Йосыф» кулъязмаларының даими табылып, гыйльми оешмаларга тупланып килгәнлеген күрсәтә.

Йосыф китабы күчермәләренең исәбен аныклап белдергән 1998 елдан соң ун ел вакыт үткәч тә әсәрнең аңарчы билгесез күчермәләре табылды дип, 2009 елда язган

---

[6] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф (Йосыф турында кыйсса) = Кул Гали. Кысса-и Йусуф (Сказание о Йусуфе)..., 1983. – Б. 490.

[7] Госманов М. Каурый каләм эзеннән: археограф язмалары. Тулыл. икенче басма. – Казан: Татар китап нәшр., 1994. – Б. 64.

[8] Мәрданов Р. «Йосыф китабы»ның көен көйләп... // Китапханә хәбәрләре = Библиотечный вестник. – 1999. – № 1. – Б. 25; Марданов Р. Драгоценные находки // Казань. – 1999. – № 5/6. – С. 82.

[9] Хисамов Н. Поэма «Кисса-и Йусуф» Кул ’Али // Средневековая татарская литература (VIII–XVIII вв.). – Казань: Фэн, 1999. – С. 50.

идек. Фәнни оешмаларда, китапханәләрдә һәм музейларда «Кыйссаи Йосыф» поэмасының ничә күчермә нөсхәсе саклануын барлап, төгәл санын ачыклауны максат итеп куймаганлыкны белдергән хәлдә, фәнгә билгеле кульъязмаларының якынча 270 тирәсе булуын чамаларга мөмкин дип яздык[10]. «Татар энциклопедиясе»нең 2012 елда дөнья күргән өченче томында поэма күчермәләренең гомуми исәбе 300-гә якын дип әйтелгән[11].

Инде хәзерге вакытта «Кыйссаи Йосыф» поэмасының фәнни оешмаларда, китапханәләрдә һәм музейларда саклана торган кулъязма күчермәләре, безнең исәпләү буенча, якынча 300 берәмлектән артык. Аларның иң күбе – 260-тан артыгы Казан шәһәрендәге китапханәләрдә һәм фәнни оешмаларда саклана (Казан университеты Фәнни китапханәсендә – 165 күчермә, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында – 52 берәмлек[12], Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә 43 берәмлек, шулай ук музейларда һәм шәхси кулларда да бар). Калганнары Петербургта, күрше Башкортстанда, Касыйм шәһәрендә, чит илләрдә һ.б.

Бу абсолют төгәл сан дип әйтмибез, чөнки яңалары ачыкланып, саннар үзгәреп тора. Һәрхәлдә, хәзерге вакытка «Кыйссаи Йосыф» әсәренең 300-дән артык кулъязмасы билгеле дип, якынча түгәрәкләп әйтергә мөмкин.

Борынгы әдәбият белгече галим Рәмил Исламов әсәрнең күчермәләре турында шундый ук фикер белдерә – ул, үз исәпләүләре нигезендә, «хәзерге вакытка «Кыйссаи Йосыф» әсәренең 300дән артык күчермәсе билгеле», «дөньяның төрле тупланмаларында хәзерге вакытка

---

[10] Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кулъязмаларына тасвирламалар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2009. – Б. 4–5.

[11] Татар энциклопедиясе. Т. 3: К–Л. – Казан: Татар энцикл. ин-ты, 2012. – Б. 620.

[12] Әхмәтҗанов М. Археографик эзләнүләр юлында. Беренче кисәк. – Казан, 2007. – Б. 150.

«Кыйссаи Йосыф» әсәренең якынча өч йөзләп күчермәләре билгеле»[13] дип язды.

Республиканың Милли китапханәсендә 2008 ел ахырында «Кыйссаи Йосыф»ның XVII–XX гасырларга нисбәтле күчермәләре 33 берәмлек булган иде һәм аларның тасвирламалары бастырып чыгарылды. Китапханәнең «Татар археографиясе» сериясендә 3 нче китап булып дөнья күргән ул китапта кулъязмаларның берәр бит факсимилеләре дә тәкъдим ителде.

Даими алып барылган археографик эзләнүләр нәтиҗәсендә Милли китапханәдә кулъязма истәлекләр артып-өстәлеп тора. Шул исәптән, «Кыйссаи Йосыф» әсәренең төрле күләмдәге күчермәләре дә табыла.

«Татар археографиясе» сериясенең бу басмасында «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә хәзерге вакытка (2026 елның 1 июненә хәтле) саклана торган 43 берәмлек күчермәсенең тасвирламалары урын алды.

Бу хезмәт чыккач та мәшһүр әсәрнең моңарчы фәнгә билгесез булган башка күчермәләре табылыр әле. Милли китапханәнең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге хезмәткәрләре тарафыннан озак еллар дәвамында алып барылган археографик экспедицияләр шушы бүлекнең мөдире Айрат Заһидуллин җитәкчелегендә уңышлы дәвам итәр һәм кызыклы фәнни табышлар белән сөендерер[14] дип ышанабыз.

---

[13] Исламов Р. Рухи хәяттә дини әдәбият // Безнең мирас. – 2022. – №5. – Б. 59; Исламов Р. Йосыф кыйссасы һәм аны өйрәнү мәсьәләләре // Безнең мирас. – 2023. – №8. – Б. 59.

[14] Китапханә белгечләренең археографик эшчәнлеге һәм уңышлы нәтиҗәләре турында тулырак карагыз: Милли китапханәнең археографик экспедицияләре: 30 еллык тәҗрибә / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2022. – 250 б.; Мәрданов Р. Гарәп хәрефле татар кулъязмаларының палеографик үзенчәлекләре. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2024. – Б. 55.

***

Әсәрнең бу китапта тасвирланган нөсхәләренә килгәндә, Татарстан Республикасы Милли китапханәсенә «Кыйссаи Йосыф» поэмасы кулъязмаларының иң беренчесе 1991 елның июнь аенда Ютазы районының Бәйрәкә авылыннан алынган иде. 1992 елда китапханәгә әсәрнең тагын ике күчермә нөсхәсе керде. Аннан соңгы елларда табышлар өстәлә барды. Һәр елда ук булмаса да, даими рәвештә диярлек Йосыф китабы күчермәләре ишәеп килде. Ягъни, 1993 елда 3 берәмлек; 1994 елда – 2; 1995 елда – 5; 1996 елда – 9; 1997 елда – 1; 1998 елда – 2; 2000 елда – 2; 2001 елда – 1; 2002 елда – 2; 2005 елда – 2; 2006 елда – 2; 2008 елда – 3; 2009 елда – 1; 2010 елда – 1; 2016 елда – 2; 2023 елда – 2 кулъязма табылып, китапханә фондына алынды. Күрсәтелгән елларда «Кыйссаи Йосыф» күчермәләренең Милли китапханә хезмәткәрләре тарафыннан иң күп табылганы 1996 елда булган иде.

Болардан 22 берәмлек кулъязма китапханәнең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге хезмәткәрләренең аерым археографик экспедицияләрендәге һәм Казан шәһәрендәге эзләнүләре нәтиҗәсендә тупланды, ә 13 берәмлек Татарстан Республикасы Милли китапханәсе белән Казан дәүләт университетының берләштерелгән фәнни-археографик экспедициясендә табылган, 5 берәмлек китапханәгә бүләк итеп бирелгән һәм 3 берәмлек сатып алынган. Китапханәдә саклана торган әлеге ядкәрләрнең 32 ел эчендә (1991–2023) туплануын исәпкә алганда, бу башкарылган эшнең нәтиҗәлелеген күрсәтеп тора.

Кулъязмаларның иң элекке өчесе XVII гасырга нисбәтле, шулардан икесе фрагментлар. Алтысы – XVIII гасырга карый. Иң күбесе – 30 кулъязма берәмлек – XIX гасырның беренче яртысында күчерелгән. Бер кулъязма 1856–1857 елларга нисбәтле. Поэманың 1950–1970 нче еллардагы соңгы дәвер күчермәләре – бу бөек әсәрнең күпгасырлык язма традициясе дәвамлылыгына дәлил буларак әһәмиятле.

Совет заманындагы өч күчермәнең берсе археограф Альберт Фәтхи кулы белән язылган. Татар кульязма һәм басма китаплары тарихы белгече Альберт Фәтхи (1937–1992) Казан дәүләт университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә 1959 елдан 1992 ел башына хәтле Шәрык кульязмалары секторында эшләгән. Ул гарәп язулы борынгы төрки-татар, гарәп һәм фарсы кульязма мирасын халык арасыннан җыеп туплауга зур көч куйган, аларны өйрәнеп, популярлаштырган күренекле галим. Археограф А.Фәтхи шулай ук татар әдипләре һәм галимнәренең кульязма мирасларын тирәнтен өйрәнеп, фәнни тасвирламаларын бастырып чыгарган. Ул, китапханәдә эшләү белән беррәттән, 1960 нчы елларда һәм аннан соң да Казан университеты студентларына кульязма чыганаклар белән эшләү, борынгы төрки тел тарихы һәм иске татар теле буенча дәресләр укыткан. Альберт Фәтхи 1962 һәм 1965 елларда студентлар өчен методик ярдәмлек һәм гарәп хәрефләрендәге текстлар җыентыгы төзегән. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре текстын А.Фәтхи нәкъ менә шул чорда студентларга укыту өчен кулланма буларак хәзерләгәнлеге аңлашыла. Аның кулы белән күчерелгән кульязмасы өлешчә сакланган бу хезмәт басылып чыкмаган. Аның Милли китапханәдәге, бу китапта тасвирланган кульязмасының бер өлеше Казан университетының Фәнни китапханәсендә саклана.

Милли китапханәдә тупланган «Кыйссаи Йосыф» күчермәләренең табылу географиясе дә шактый киң. Шулардан егерме алтысы Татарстан Республикасында: Казан шәһәрендә – унөч, Буа каласында – бер, Арча районында – алты, Апас, Әгерҗе, Әтнә, Теләче, Ютазы районнарында – берешәр; Уфа шәһәрендә – өч, Башкортстанның Тәтешле районында – ике, Пермь өлкәсенең Барда районында – өч, Марий Эл Республикасының Бәрәңге һәм Морки районнарында – берешәр, Чуашстанның Комсомол районында – бер, Пенза өлкәсенең Городище, Каменка, Кузнецк һәм

Неверкино районнарында (һәрберсендә берәр) – дүрт, Самара өлкәсенең Шонталы районында – ике, Тобольск каласында – бер кульязма табылган. Монда Казан табышлары арасында исәпләнгән, М.Садри китапханәгә бүләк иткән кульязманың 1940 нчы елда Омск өлкәсенең Тәвриз районында табып алынган булуын, ә Уфа шәһәрендәге берсе Башкортстанның Чишмә районыннан икәнлеген искәртергә кирәк.

Кульязмаларның унөче мәчетләрдән табып алынган. Аларның өчесе Казан шәһәрендәге «Мәрҗани» мәчетеннән (шулардан берсе – китапханәгә Марат Килдиевтән), икесе «Болгар» һәм бер күчермә «Нур-Ислам» мәчетләреннән, шулай ук Буа һәм Уфа (ике кульязма) шәһәрләренең, Татарстанның Әтнә районындагы Ташчишмә авылының, икесе Самара өлкәсенең Динис авылының, Пермь өлкәсенең Барда авылының мәчетләреннән. Бу уңайдан тел һәм әдәбият галиме Хәсән Галинең (1878–1940) моннан йөз елдан артык элек үк «бездә мәсҗедләрнең түбәләре, очырмалары бер архива урынын тотып, һәртөрле иске китап вә язулар шуннан табылдыгы мәгълүмдер»[15] дип, бик хаклы язган сүзләре хәтергә килә. Милли китапханәгә тупланган кульязма мирасның да аерым бер өлеше шәһәрләрнең һәм авылларның мәчетләрендә һәм аларның чормаларында электән җыелып килгән байлыктан гыйбарәт.

Китапханәдә саклана торган өч кульязма нөсхәнең шагыйрьләр исеме белән бәйле булуы шулай ук кызыклы. Аларның берсен XIX гасыр шагыйре Гали Чокрый (1826–1889) үз кулы белән күчергән булса, икенчесе – шагыйрә Заһидә Бурнашеваның (1895–1977) шәхси архивына нисбәтле, ә өченчесен – шагыйрь Мөхәммәт Садри (1913–1999), 55 ел дәвамында кадерләп саклаганнан соң, китапханәгә бүләк итеп биргән иде. XIII гасырда иҗат ителгән поэманың, дәверләр кичеп, төрле буын татар шагыйрьләрен үзенә

---

[15] Хәсән Гали. Акмулла шигырьләре хакында // Шура. – 1912. – № 14. – Б. 430.

тартып һәм җәлеп итеп торганлыгы аерым әһәмияткә ия.

Тасвирланган 43 кулъязма арасында текстлары тулы диярлек дәрәҗәдәге һәм шактый күләмлеләре (мәсәлән, 5, 6, 11, 15, 16, 26, 28, 33, 36, 43 саннары белән билгеләнгәннәре), 4–10 битле өзекләр, шулай ук 1–2 битлек, хәтта чирек бит хәтле генә фрагментлар (23, 31 һәм 34 нче санлы тасвирлар) бар. Фрагментларның күләмнәре кечкенә булса да, әһәмиятләре зур. Чөнки хәзерге вакытка ялгыз битләре генә сакланып калган аерым кәгазь кисәкләре – кайчандыр кулланылган мөстәкыйль кулъязмаларның өлешләре бит.

«Кыйссаи Йосыф» әсәре фрагментларының үзенчәлекле рәвештәге берсен искә алу шулай ук урынлы булыр. «Татар археографиясе» сериясенең 19 нчы китабы өчен кулланылган кулъязма җыентыкны XIX гасырда реставрацияләгәндә нәкъ менә «Кыйссаи Йосыф» кулъязмасының битләре кулланылган дип язган идек[16]. «Дастане җайә» тексты язылган, Милли китапханәдә «2221т» шифры белән саклана торган җыентык үзе XVII гасырның соңгы чирегенә нисбәтле. Аның тузган-таушалган төбе XVIII гасыр ахыры – XIX гасыр башындагы яшькелт-зәңгәрсу кәгазьгә язылган «Кыйссаи Йосыф» поэмасы текстының битләрен тасмасыман кисеп ябыштырылган һәм ныгытылган[17]. Бу очракта үзе дә күп укылып тузган яки битләре җуелган «Кыйссаи Йосыф» нөсхәсен файдалы эш өчен кулланганнар дип аңларга кирәк. Элекке заманнарда, бәясе кыйммәт һәм кадере зур булганлыктан, таушалган-тузган һәм кечкенә генә кәгазь кисәкләрен дә файдаланырга тырышканнар. «Кыйссаи Йосыф»ның менә шундый фрагментлары да очрый һәм алар әсәрнең аерым берәмлеге буларак исәпкә кермәсәләр дә, игътибарга алынырга тиеш.

---

[16] Дастане җайә (Мәликә китабы) / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2017. – Б. 128.

[17] «2221т» санлы кулъязмада әсәр текстының аерым өлешләре күренгән фрагментлары: 15а, 17а, 18б, 19б, 20б, 24а, 27а, 28б, 31б, 32а, 33а, 34а, 36б, 38а, 50а, 51б.

Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы халык арасында шул дәрәҗәдә популярлашкан булган ки, төрле чорларда бу әсәрнең шигъри калыбында күпсанлы бәетләр һәм җырлар иҗат ителгән. Милли китапханәдә андый әсәрләр теркәлгән кулъязмалар да саклана. Кайберләре «Татар археографиясе» сериясендәге басмаларда да дөнья күрде. Мәсәлән, 1904–1905 еллардагы рус-япон сугышы, Беренче бөтендөнья сугышы һәм солдат бәетләренең текстлары[18] нәкъ шундыйлардан.

***

Китапта «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә саклана торган барлык 43 кулъязма күчермәсенең тасвирламалары бирелде. Алар китапта хронологик тәртип буенча урнаштырылды.

Кулъязмалар түбәндәге тәртип буенча тасвирланды:

1) тасвирлау номеры (өстә, уртада);
2) китапханәдәге саклану шифры (өстәге сул почмакта);
3) әсәрнең исеме (гарәп хәрефләре белән язылышы);
4) авторы;
5) әсәр исеме;
6) кәгазенең төре һәм төсе;
7) кәгазенең филигране (су билгесе);
8) тышлыгы;
9) күләме;
10) әсәр текстының тулылыгы;
11) пагинациясе;
12) кәгазенең форматы;
13) бер биттә текст язылган мәйданның зурлыгы;

[18] «Без плиндә ятамыз читлектәге кош кебек...»: Беренче бөтендөнья сугышы бәетләре / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2014. – Б. 41–52; Сугыш һәм солдат бәетләре / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2016. – Б. 87–105, 129–138, 150–154, 159–164; Матрос Әхмәдулла дәфтәре: 1898–1906 еллар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2017. – Б. 100–103; Солдат Ярулла дәфтәре: бәетләр һәм мөнәҗәтләр. 1905–1906 еллар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2018. – Б. 18–21, 55–57, 62–63.

14) бер биттәге шигъри юллар саны

15) текстның башындагы һәм ахырындагы юллары, аларның 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасындагы ничәнче биткә һәм кайсы строфага туры килүләре;

16) текстның палеографик үзенчәлекләре;

17) язу карасы;

18) язу төре;

19) кустодлары;

20) рамкалар;

21) күчерелгән вакыты;

22) күчерелгән урыны;

23) күчерүчесе;

24) колофоны;

25) сакланыш дәрәҗәсе, дефектлары;

26) мөһер һәм штамплар;

27) җыентык эчендә булса, башка әсәрләр һәм язмалар турында кыскача мәгълүмат;

28) кулъязма хуҗасының язмалары;

29) китапханәгә кайдан, кемнән, кайчан һәм кем тарафыннан алынуы;

30) басылып чыккан мәгълүмат булганда, кыскача библиографик белешмә.

Санап үтелгән үзенчәлекләрнең кайберләре (мәсәлән, рамкалары яки колофоны) булмаган очракта, аларның юклыгы тасвирда күрсәтелмәде.

Кулъязмаларның күпчелегенә хас булган кайбер гомуми күренешләрне тасвирламаларда кабатлап тору кирәксез дип табылды. Мәсәлән, поэманың монда тасвирланган текстлары, берсеннән (№42) башка, һәммәсе дә гарәби язулы элекке шигъри әсәрләр шәкеленчә, бер кәгазь битендә икешәр баганалы итеп теркәлгәннәр. Һәр кулъязма нөсхәнең диярлек бит читләрендә төп текстка кагылышлы өстәмә (төшеп калган сүзләр һәм юллар яки хаталы сүзләргә төзәтмә) язулар бар. Күпчелегендә күчерелгән урыннары күрсәтелмәсә дә, палеографик үзенчәлекләренә нигезләнеп, Идел-Урал буй-

ларына нисбәтле татар кульязмалары икәнлеге аңлашылып тора. Менә болар тасвирларда махсус күрсәтелмәде.

Кәгазьләренең форматлары һәм бер биттәге текст язылган мәйданнары төрлечә зурлыкта булган очракларда, андый вариантлар җәяләр эчендә күрсәтелде. Шулай ук күчермәләрнең бер битендәге шигъри юлларның исәбе ике төрле сан белән – мәсәлән, «15 (17)» рәвешендә күрсәтелгән очракта, аларның бер өлеше 15 юлдан, кайберләре 17 юлдан торганлыгын аңлата. Шигъри юлларның исәпләре кайбер кульязмаларда бөтенләй тотрыксыз. Мәсәлән, «1763т» шифрлы күчермәдә (тасвирда 10 нчы сан белән бирелде) текст күбесенчә 16 (17) юллы итеп, ә бер битендә 21 шигъри юлда язылган.

Кульязма истәлекләрнең кәгазь форматлары үзләренең чорына тәңгәл булмаган очраклар бар. Андыйлар, гадәттә, кульязма җыентыкның төпләнгән яисә соңрак төзәтелеп реставрацияләнгән вакытларында кәгазь читләре киселгән булуына да бәйле.

Бу китапта 2009 елда чыккан тасвирламалар камилләштерелде. Мәсәлән, элекке басмада бер һәм берничә битле фрагментлардагы текстларның башындагы һәм ахыргы юллары тасвирда күрсәтелмәгән иде, бу китапта һәммәсенең дә мәгълүматлары тулыландырылды.

«Кыйссаи Йосыф» әсәренең кульязмалары белән эш иткәндә уңайлы булсын өчен тасвирланган күчермәләрдәге текстның башы һәм ахыры 1983 елгы басма китапта кайсы биткә туры килүләре искәртелде. Әмма текст башы һәм ахыры арасында өзеклекләр, аермалар, үзенчәлекләр дә бар. Мәсәлән, беренче карашка тулы текстлы кебек тоелган, башы һәм ахыры булган, 26 нчы номер белән тасвирланган, китапханәдә «486т» шифры белән саклана торган кульязма, беренчедән, ике аерым кульязма тексттан берләштерелгән булса, икенчедән, тексты эчендә дә җитешмәгән битләре һәм төшеп калган өлешләре бар. Аерым бер кульязманың башындагы һәм ахырындагы юллары 1983 елгы басманың

фәләненче битләренә туры килә дип язылган мәгълүмат күчереп бирелгән өземтәләрнең басмадагы текстка сүзгә-сүз тәңгәл килүен белдерми. Кулъязмалардан алынган текст башындагы һәм ахырындагы шигъри юллар үзләрендә язылганча ук (хаталы булса, шул хәлендә), үзгәртелмичә, хәзерге татар язуына транслитерация рәвешендә күчерелделәр.

Гарәп телендәге текстларга хас хәрәкәләр һәм тәнвиннәр «Кыйссаи Йосыф» әсәренең күчермәләрендә шактый кулланылган булуы турында моңарчы чыккан тасвирламалар китабында искәрткән идек[19]. Татар кулъязма ядкярләренең палеографик үзенчәлекләренә багышланган хезмәтебездә бу мәсьәләгә аерым тукталдык. Тәнвиннәр гарәп графикасында кайбер кушымчалардагы һәм сүз ахырларындагы хәрефләрнең –ан, –ән, –ин, –үн, –ун рәвешендәге өстәмә тамгалар белән язылышын аңлата. Төрки тамырлы сүзләрне тәнвиннәр һәм хәрәкәләр кулланып язу – иҗат ителү вакыты борынгырак булган әсәр күчермәләренә хас күренеш. Бу электән килгән палеографик традиция «Кыйссаи Йосыф»ның кулъязма нөсхәләрендә еш очрый[20].

Шушы әсәр текстларындагы тәнвиннәр кулланылышы тотрыксыз булганлыгын да искәртергә кирәк. Ягъни, бер кулъязмадагы янәшә килгән ике сүзнең берсе тәнвин белән, икенчесе – тутырып (бөтен хәрефләре дә куелып) язылган булса, бүтән кулъязмада алар киресенчә – беренчесе хәрефләр белән, ә икенчесе тәнвин белән язылганын күрергә мөмкин. Андый очраклар аз түгел. Димәк, «Кыйссаи Йосыф»ның XVII–XIX гасырлардагы күчермәләрендә тәнвиннәрне куллану нинди дә булса кагыйдәләргә нигезләнмәгән һәм аларны иң элекке текстлардан ук үзгәрешсез язылып килгәннәр дип санарга кирәкми.

---

[19] «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кулъязмаларына тасвирламалар..., 2009. – Б. 9.

[20] Татар палеографиясендә тәнвиннәр һәм хәрәкәләр кулланып язу традициясе озак дәвам иткән. Тәнвиннәр XIX гасырдагы гади эш кәгазьләрендә, хәрәкәләр исә шигъри текстларда XX гасыр башында, хәтта 1920 нче елларда кулланылган очраклар бар (Мәрданов Р. Гарәп хәрефле татар кулъязмаларының палеографик үзенчәлекләре..., 2024. – Б. 156–161).

Тасвирламаларда күчермәләрнең язу төрләре шартлы нигездә билгеләнде. Чөнки монда тасвирланган күчермәләрне «нәстәгъликъ»ка яки бүтән язу төрләренә нисбәт итүебез – аларның гарәп каллиграфиясендәге бөтен кагыйдәләре үтәлгән нәфис сәнгати язылышына туры килүләрен аңлатмый. Тарихтан билгеле булганча, XVIII–XIX гасырлардагы татар кульязмаларының күпчелеге мәдрәсә шәкертләре тарафыннан бозыграк нәстәгъликъ яисә нәстәгъликъ-шикәстә төрләренә охшашрак рәвештә күчерелгән. Бу тасвирламага кергән «Кыйссаи Йосыф» кульязмалары, нинди язу төренә якынрак булуларына күрә, бик тә шартлы рәвештә нисбәт ителде.

Кульязмаларның саклануш дәрәҗәләре шулай ук якынча һәм шартлы тәгаенләнде. Татар кульязмаларының, гомумән, начар сакланышта һәм күпчелегенең язулары сыйфатсыз булуының бик җитди тарихи сәбәпләре турында күп язылды, монда кабатлап тору ихтыяҗы юк.

Күчерелгән вакытлары кульязмаларның үзләрендә билгеләнмәгән очракта, тасвирламада филиграньдәге елларын күрсәттек. Димәк, кульязма филиграньдәге елдан соңгы (якынча 1–10 ел эчендәге) вакытка карый. Ә филиграньнәре булмаган кульязмаларның вакыт нисбәте, язулары һәм кәгазь төрләренә, шулай ук бүтән палеографик үзенчәлекләренә карап һәм эш тәҗрибәбезгә нигезләнеп (гасырның башы яки ахыры, беренче яки икенче чирек рәвешләрендә), якынча билгеләнде.

Китапханәнең кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге эшчәнлеген яктырткан хезмәтләрдә һәм мәкаләләрдә «Кыйссаи Йосыф» поэмасының күчермәләре искә алынган очраклар турында тасвирларда библиографик белешмә бирелде.

Кульязма тасвирламалары янәшәсендә күчермә-факсимиле үрнәкләре урын алды.

Китап ахырында өстәмә белешмәләр өчен тасвирламаларда очраган исемнәрнең һәм географик атамаларның, шулай ук күчерелгән һәм китапханәгә алынган вакытларының күрсәткечләре урнаштырылды.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә саклана торган «Кыйссаи Йосыф» күчермәләренең иң әүвәлгесе – XVII гасыр кульъязмасы –турында бу китап ахырында махсус мәкалә тәкъдим ителде.

Гомумән, иске әсәрләрнең һәр кулъязмасы игътибарга лаек, аларда нинди дә булса өстәмә яисә төзәтмә кертерлек урыннары була. Мәсәлән, «Кыйссаи Йосыф»ның 1983 елгы басмасындагы 74 биттә урын алган 118(1) нче строфасында (соңгы юлында) берничә сүзе күпнокталар белән билгеләнгән. Димәк, ул сүзләр төп чыганагында – кульъязмада – танырлык хәлдә булмаган. Ул строфаның ахыргы ике юлы Милли китапханәдәге «1859т» шифрлы (15 нче сан белән тасвирланган) күчермәнең 6б кәгазендә мондый:

Ай вә Көн, унбер йолдызларга айгыл,
Әлең йазыб, тун вирсүнләр, – дирләр имди.

Мондагы «Әлең йазыб, тун вирсүнләр» («кулыңны чишеп, кием бирсеннәр») сүзләре басмада юк[21]. Бу строфаның шундый ук язылышы «486т» (26 нчы сан астында тасвирланган күчермәнең 9б кәгазендә) һ.б. кулъязмаларда да бар.

«Кыйссаи Йосыф» күчермәләрендә бүлек-фасыл бүленешләре төрлечә булган кебек, аларның исемнәре дә күп төрле. Кайберләрен бу китаптагы тасвирламаларда да искәрттек. Мәсәлән, «2744т» шифрлы күчермәдә (китапта №35) «Фасыл: Хан хәким» дигәне әсәрнең төп текстында башкача. Шулай ук «3963т» кулъязмасында (№6) өстәмә бүлек атамалары бар, хәтта бер биттә өч фасыл исеме язылган булып, шулардан берсе нибары бер строфадан гына тора. Поэманың кулъязмаларында менә шундый текстологик хикмәтләр аз түгел һәм алар яхшылап өйрәнелергә тиеш.

---

[21] Рабгузиның 1310–1311 нче елларда иҗат ителгән «Кыйсасел-әнбийа» китабында да Йосыфның агалары «Әйделәр: ул унбер йолдыз, тәкый Ай-Көн илкиңне йаза бирсүн» дип язылган (Кыйсасел-әнбийаи Рабгузи. – Казан: ун-т табыгханәсе, 1881. – Б. 135).

Хезмәтнең ахырында бу китапның эчтәлеге турында рус телендәге резюме урнаштырылды.

Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «Кыйссаи Йосыф» әсәренең монда тасвирланган гарәп хәрефле күчермәләреннән тыш, 1970 нче елларда хәзерге татар язуында машинкада басылган һәм Казан дәүләт университетының татар әдәбияты кафедрасында кулланылган нөсхәсе дә бар. «Кыйссаи Йосыф вә Зөләйха» дип исемләнгән ул текст «1842 елда Казанда Азиатская исемендәге Казан университеты матбагасында басылган нөсхәдән күчерелде. Керешеннән баштагы 12 бәет төшереп калдырылды» дип искәртелгән. Аның һәр битендәге астөшермәләрендә сүзлекчә бирелгән. Зурлыгы 20х29 см, күләме 226 кәгазьдән торган бу нөсхә китапханәгә 1995 елда алынган иде һәм ул кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «5944т» шифры белән саклана. Шул ук бүлектә 1983 елда «Кыйссаи Йосыф» поэмасының язылуына 750 ел һәм авторы Кол Галинең тууына 800 ел тулуга багышланган документлар да бар. СССР Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты һәм Татарстан АССР Язучылар берлеге җитәкчеләре тарафыннан Мәскәүдәге һәм Татарстандагы югары оешмаларга язылган рәсми хатлар, галимнәрдән Яхъя Абдуллин, Шакир Абилов, Фазыл Фәсиев һәм Нурмөхәммәт Хисамовның шул мәсьәләгә караган докладлары, фикерләре һ.б. документлар 1982 елның май, июнь, октябрь айларында һәм 1983 елда язылганнар. Шунда ук Кол Галинең 1983 елда нәшер ителгән тәнкыйди басмасын тикшерүгә бәйле чыгыш та саклана[22].

***

Китапны басмага хәзерләгәндә күрсәткән ярдәмнәре өчен Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең директоры урынбасары Ирек Һадиевка, китапханәнең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге мөдире Айрат

[22] Әйтелгән документлар кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «9224т»–«9239т» шифрлары белән теркәлгән.

Заһидуллинга һәм ул җитәкләгән бүлек хезмәткәрләренә, шулай ук китапханәнең редакция-нәшрият бүлеге хезмәткәрләренә зур рәхмәтләремне белдерәм.

# КУЛЪЯЗМАЛАР ТАСВИРЛАМАЛАРЫ

## 1

3410т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Көнбатыш Европада XVII гасырда эшләнгән кәгазьдә. Филиграньнәре бар.

Төбе ак җеп белән тегелгән. Тышлыгы юк.

Күләме: 8 кәгазьдә (җыентыкның 1–8 нче кәгазьләрендә). Башы һәм ахыры юк. Пагинациясе соңгы чорда гади карандаш белән куелган.

Форматы: 16 х 20,5 см.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 11 х 14 см.

Бер битендә 15 шигъри юл.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Бакды ирсә нур чыкар ул койуд(ан),*
*Аны күреб, би-худ улыб дөшәр имди.*

Текстның ахыры (8б кәгазьдә):

*Йа, Йосыф, бәңа сән дәйүрс(ән),*
*Сән бойурсаң, бән ани кылсам имди.*

Бу кульязмадагы текст башы 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасының 90 битендәге 183 нче строфага, ахыры 112 битендәге 291 нче строфага туры килә.

Тексттагы төрки сүзләрдә хәрәкәләр һәм тәнвиннәр күп кулланылган. Кайбер очракларда «син» хәрефенең астында өчәр нокта куелган, «йа» хәрефенең сүз ахырларында-

гы язылышында һәр очракта диярлек икешәр нокта куелган. Сүзләрдәге «-лар» кушымчасы язылышында «ләм» һәм «әлиф»кә «р» хәрефе тоташтырылган. Сүз башындагы



*«3410т» шифрлы кульязма. 7а кәгазь.*

«у» (ү, о, ө) хәрефе һәр очракта диярлек «әлиф» өстендәге «даммә» хәрәкәсе белән белдерелгән.

Язу карасы – ачык (саргылт) көрән төстә.

Язу төре – нәстәгъликъ үзенчәлекләре белән кушылган нәсех.

Кустодлары бар.

Күчерелгән вакытын якынча XVII гасыр уртасы дип тәгаенләдек. Бу кулъязмадагыга охшашрак – өч манара рәсеме төшерелгән филиграньнар Көнбатыш Европа кәгазьләрендә 1590 нчы еллардан алып 1650 нче елларга кадәр кулланылган.

Сакланышы уртачадан түбән. Дефектлары: дымлану кичергәннән калган таплары бар, кәгазь читләре таушалган-тетелгән, аерым урыннары үтәли тишкәләнгән.

Кулъязма җыентыкның икенче өлешендә – 9–36 нчы кәгазьләрдә Камал улы Әхмәд исемле авторның «Шуридәи халь» әсәре тексты һәм 33б, 34б кәгазьләрдә дини мәсьәләләр теркәлгән. Кәгазе дә, язуы да башка төрле ул өлеш чагыштырмача соңгырак чорга – XVIII гасырның икенче яртысына карый. Кәгазенә төшерелгән, Ярославльдәге С.Яковлев мануфактурасын белдергән су билгесе шуңа ишарә итә.

Җыентыкның 33а кәгазендә «Сәгыйд бине мулла» дигән исем бар, ул исә якынча XVIII гасыр ахырына – XIX гасыр башына нисбәтле.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең фәнни-археографик экспедициясе вакытында Татарстан Республикасының Әтнә районындагы Ташчишмә авылы мәчетеннән китапханә хезмәткәре Ленар Гобәйдуллин тарафыннан 2010 елның июль аенда алынган.

Бу күчермәнең палеографик һәм текстологик үзенчәлекләре турында шушы китапның ахырында махсус мәкалә бирелде.

**Бу кулъязманың бер бите факсимилесы басылды:**

Мәрданов Р. Гарәп хәрефле татар кулъязмаларының палеографик үзенчәлекләре. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2024. – Б. 32.

## 2

590т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Европада эшләнгән ак төстәге кәгазьдә.

Күләме: 1 кәгазьдәге фрагмент. Иске кульязма китап тышлыгы өчен ябыштырылган аерым кәгазь битләренең берсе.

Форматы: 11 х 14,5 см.

Бер биттә 15 шигъри юл.



*«590т» шифрлы кульязма. 1а кәгазь.*

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Хәсәд кыйлыб [атамдан] айырдылар*

Текстның ахыры (1б кәгазьдә):

*Бу залимд(ән) кортылмага б(ән) нә кыйлайын?*
*Ходавәндә, фазлең берлә кортар имди!*

Бу фрагменттагы текст башы 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасының 102 битендәге 249 нчы строфага, ахыры 104 битендәге 261 нче строфага туры килә.

Текстта хәрәкәләр һәм тәнвиннәр күп кулланылган. Тексттагы сүзләрдә «мөһмәлләр» (ноктасыз хәреф ишарәтләре): «хә» хәрефе астында махсус билге, «дәл» һәм «ра» хәрефләре астында берәр нокта, «син» хәрефенең астына өч нокта куеп язылган. Шулай ук сүз ахырларындагы «йа» хәрефләре астында икешәр нокта куелган. Ләкин болар һәр очракта да тотрыклы түгел.

Язу карасы – кара төстә.

Язу төре – нәстәгъликъ элементлары кушылган нәсех.

Күчерелгән вакыты – XVII гасыр уртасы.

Сакланышы начар: кәгазе яртылаш диярлек кенә сакланган, ике баганалы текстның берсе тулаем укырлык түгел, кәгазь читләре бик тетелгән.

Казан шәһәренең «Болгар» мәчетеннән китапханә хезмәткәрләре Ирек Һадиев һәм Раиф Мәрданов тарафыннан 1993 елның май аенда алынган иде.

**Бу кульъязма турында мәгълүмат басылды:**

1. Мәрданов Р. «Йосыф китабы»ның көен көйләп... // Китапханә хәбәрләре = Библиотечный вестник. – 1999. – № 1. – Б. 25–26.

2. Марданов Р. Драгоценные находки // Казань. – 1999. – № 5/6. – С. 82.

3. Мәрданов Р. Тарих битләрен актарганда... // Казан утлары. – 2002. – № 3. – Б. 126.

4. Марданов Р. Сбережения // Татарский мир = Татар дөньясы. – 2005. – Январь (№23–24).

5. «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кульъязмаларына тасвирламалар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2009. – Б. 12–13. – (Бер бит факсимилесы белән).

6. Мәрданов Р. Китапларда милләт язмышлары... – Казан: «Милли китап» нәшр., 2010. – Б. 55.

3

591т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Европада эшләнгән ак төстәге кәгазьдә.

Күләме: 1 кәгазьдәге фрагмент. Иске кульязма китап тышлыгы өчен ябыштырылган аерым кәгазь битләренең берсе.

Форматы: 8,5 х 15 см.

Бер биттә 17 шигъри юл.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Һәм габид һәм дәстгир Гафур-у-Әхәд*

Текстның ахыры (1б кәгазьдә):

*Газиз әйдүр Йосыфа: «Нә иш кылдың?»*
*Уш[бу]...*

Бу фрагменттагы текст башы 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасының 168 битендәге 543(1) нче строфага, ахыры 170 битендәге 552 нче строфага туры килә.

Текст төрки сүзләрне хәрәкәләр белән һәм тәнвиннәр кулланып язылган палеографик үзенчәлекләргә ия. Мәсәлән, «кыйлс(ун)» рәвешендә. Сүзләрдә «мөһмәлләр» (ноктасыз хәреф ишарәтләре): «хә» хәрефе астында махсус билге, «дәл» хәрефе астында бер нокта, «син» хәрефләренең астына өчәр нокта куеп язылган. Шулай ук сүз ахырындагы «йа» хәрефе астында ике нокта куелган. Ләкин болар һәр очракта да тотрыклы түгел. «Имди» сүзе «эмди» рәвешендә генә, ягъни сүз башындагы «йа» хәрефеннән башка язылган.

Язу карасы – кара төстә.

Язу төре – нәстәгъликъ элементлары кушылган нәсех.

Күчерелгән вакыты – XVII гасыр уртасы.

Сакланышы начар: һәр битендә икешәр баганага бүлеп язылган текстның бер баганасы гына тулаем, икенчесенең берничәшәр сүзләре генә күренә.



*«591т» шифрлы кульъязма. 1б кәгазь.*

Казан шәһәренең «Болгар» мәчетеннән китапханә хезмәткәрләре И.Һадиев һәм Р.Мәрданов тарафыннан 1993 елның май аенда алынган иде.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең «Татар археографиясе» сериясендә нәшер ителгән басмаларның алгы (беренче) тышлык битләрендә «Кыйссаи Йосыф» әсәренең шушы – «591т» шифрлы кульязма бите иллюстрация итеп кулланылды.

**Бу кульязма турында мәгълүмат басылды:**

1. Мәрданов Р. «Йосыф китабы»ның көен көйләп... // Китапханә хәбәрләре = Библиотечный вестник. – 1999. – № 1. – Б. 25–26.

2. Марданов Р. Драгоценные находки // Казань. – 1999. – № 5/6. – С. 82.

3. Мәрданов Р. Тарих битләрен актарганда... // Казан утлары. – 2002. – № 3. – Б. 126.

4. Марданов Р. Сбережения // Татарский мир = Татар дөньясы. – 2005. – Январь (№23–24).

5. «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кульязмаларына тасвирламалар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2009. – Б. 14–15. – (Бер бит факсимилесы белән).

6. Мәрданов Р. Китапларда милләт язмышлары... – Казан: «Милли китап» нәшр., 2010. – Б. 55.

7. Мәрданов Р. Гарәп хәрефле татар кульязмаларының палеографик үзенчәлекләре. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2024. – Б. 54. – (Бер бит факсимилесы).

## 4

1401т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.
«Кыйссаи Йосыф».
Күләме: 1 кәгазьдәге фрагмент.
Европада эшләнгән ак төстәге кәгазьдә.
Форматы: 15 x 18,5 см.



*«1401т» шифрлы кулъязма. 1а кәгазь.*

Бер биттә текст язылган мәйдан: 11,3 (12) х 14 (15,5) см.

Бер битендә 14 (16) шигъри юл.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Андин соңра холәфаи рашидинләрә,*
*Голәма-у-шәһидин, табигыйнләрә.*

Текстның ахыры (1б кәгазьдә):

*Дугар көн, тулун ай, унбер йолдуз*
*Дөшүм ичрә сәҗдә кыйлды бәңа дөб-дөз.*

Бу фрагменттагы текст башы 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасының 48 битендәге 8 нче строфага, ахыры 52 битендәге 24 нче строфага туры килә.

Берничә сүздә хәрәкәләр һәм тәнвиннәр бар (мәсәлән, «с(ән)» рәвешендә).

Язу карасы – саргылт-көрән төстә.

Язу төре – нәстәгъликъ-шикәстә.

Сакланышы уртача: кәгазе бер урында тишелгән һәм язуы өлешчә уңган.

Күчерелгән вакыты – XVIII гасыр башы.

Татарстан Республикасының Арча районындагы Яңа Кишет авылында Фәйрүзә Шәрәфиевадан китапханә хезмәткәре Айрат Заһидуллин тарафыннан 1996 елның августында алынган.

**Бу кульязма турында мәгълүмат басылды:**


1. Мәрданов Р. Ун еллык археографик хезмәт // Китапханә хәбәрләре = Библиотечный вестник. – 2002. – № 1. – Б. 15.
2. Мәрданов Р. Тарих битләрен актарганда... // Казан утлары. – 2002. – № 3. – Б. 126.
3. «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кульязмаларына тасвирламалар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2009. – Б. 16–17. – (Бер бит факсимилесы белән).

## 5

1228т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.
«Кыйссаи Йосыф».



*«1228т» шифрлы кулъязма. 43б кәгазь.*

Европада XVIII гасыр уртасында эшләнгән саргылт төстәге кәгазьдә. Филиграньнәре бар.

Төбе юан җеп белән тегелгән. Тышлыгы юк.

Күләме: 60 кәгазьдә. Башы һәм ахыры юк. Пагинациясе соңгы чорда гади карандаш белән куелган.

Форматы: 16,8 x 20,5 см.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 10,5 (11) x 16 (16,5) см.

Бер битендә 16 (18) шигъри юл.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Йосыф әйдүр: «Йа, кардәшләр, бәңа кыйлмаң,*
*Шәйтан сүзенә гөмраһ кыйлыб, аңа уймаң.*

Текстның ахыры (60б кәгазьдә):

*Бәшир адлу кечек угълум сатмыш иде,*
*Йитмеш йылдур хәсрәтен тартарым имди.*

Бу кулъязмадагы текст башы 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасының 74 битендәге 117 нче строфага, ә ахыры 270 битендәге 946 нчы строфага туры килә.

Текстта, сирәк булса да, хәрәкәләр һәм тәнвиннәр куелган. Мәсәлән, 2а кәгазьдә «койуд(ан)», «хатеренд(ән)», 51б кәгазьдә «кәлс(үн)», «улс(ун)» рәвешендә.

Кустодлары бар.

Язу карасы – тексты сыек көрән, фасыл исемнәре кызыл төсләрдә. 59б кәгазендә аерым юлы кызыл белән язылган.

Язу төре – нәстәгъликъ-шикәстә. Кайбер урыннарда сөлес язуы элементлары бар.

Сакланышы уртача. Дефектлары: кулъязма юешләнү кичергән. 1а, 60б кәгазьләре аеруча пычрак. Кайбер битләрендә (мәсәлән, 22–28, 38–39 кәгазьләрдә) язуының карасы тоныкланган. 37 нче кәгазе төбеннән купкан, аеруча таушалган һәм читләре ертылган. Бу кәгазьнең урыны текст эчтәлегенә туры килми. 48б кәгазьдә язылган берничә юл өстеннән кызыл кара белән сызылган.

Күчерелү вакыты – кәгазьдәге су билгеләре 1751–1756 елларга карый.

Кулъязма соңгы хуҗаларына Башкортстанның Чишмә

районындагы Сәйран авылында яшәгән Нәбиулла Сәйфуллиннан (1943 елда вафат) калган.

Уфа шәһәрендә яшәүче милләттәшебез Нурдидә Биктимерова 1996 елның 11 декабрендә китапханәгә бүләк итеп биргән иде.

**Бу кульязма турында мәгълүмат басылды:**

1. «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кульязмаларына тасвирламалар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2009. – Б. 18–19. – (Бер бит факсимилесы белән).

2. Татар китабы = Татарская книга: альбом / төз.-авт. Р.Мәрданов, И.Һадиев; рәс. Ш.Насыйров. – Казан: Татар. китап нәшр., 2013. – Б. 86 (17б һәм 18а кәгазьләренең фоторәсеме).

3. Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 1 т.: Борынгы чор һәм Урта гасырлар / төз. Р.Рахмани. – Казан: Татар. китап нәшр., 2014. – Фототуплам, 8 нче бит (17б һәм 18а кәгазьләренең фоторәсеме).

4. Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 1 т.: Борынгы чор һәм Урта гасырлар / төз. Г.Дәүләтшин. Үзгәрт. 2 нче басма. – Казан: Татар. китап нәшр., 2021. – Фототуплам, 8 нче бит (17б һәм 18а кәгазьләренең фоторәсеме).

## 6

3963т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.
«Кыйссаи Йосыф».


61

فصل في بيان بناء القصر

*«3963т» шифрлы кулъязма. 61а кәгазь.*

Россиядә XVIII гасырның икенче яртысында эшләнгән кәгазьдә. Филиграньнәре бар.

Төбе ак җеп белән тегелгән. Тышлыгы юк.

Күләме: 77 кәгазьдә. Башы һәм ахыры бар. Пагинациясе соңгы чорда гади карандаш белән куелган.

Форматы: 15 (15,3) х 18 (18,5) см.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 10 х 15 см.

Бер битендә 16 шигъри юл.

Текстның башы (1б кәгазьдә):

*Әлхәмдү шөкер, сипас ул Әхәдә,*
*Мөлке би-зәваль ул Самәдә.*

Текстның ахыры (77б кәгазьдә):

*Бу арада бу китаби тәмам кыйлдым,*
*Вә нәфәгъна вә әййакүм кыйлыйк имди.*

Бу кулъязмадагы текст башы 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасының 46 битендәге 1 нче строфага, ахыры 294 нче битендәге 1010 нчы строфага туры килә. Кулъязманың 12 нче һәм 13 нче кәгазьләре арасындагы ике кәгазе төшкәнлектән, текстка өзеклек кергән.

Тексттагы төрки сүзләрдә тәнвиннәр шактый кулланылган. Фасыл-бүлек исемнәре үзенчәлекле. Мәсәлән, 19а кәгазьдәге текст, эчтәлек мәгънәсенә күрә, өч фасылга аерылган һәм аларның берсе бары тик бер строфадан тора.

Язу карасы – көрән һәм караңгы көрән төсләрдә.

Язу төре – нәстәгъликъ-шикәстә.

Кустодлары бар.

Күчерелгән вакыты – XVIII гасырның өченче чиреге.

Күчерүчесе – Фәйзулла.

Колофоны (77б кәгазьдә) шигъри юллар белән язылган:

«Йазучы бән Фәйзулла ирүрмен,
Ходайның рәхмәтендин раҗидурмын.
Йазванны хурламагыйл хуб дәгүл диб,
Йазуың безгә муафыйк дәгүл диб».

Шунда ук колофон язмасын дәвам итеп татарча һәм фарсыча язылган тагын ике шигъри парча бар.

Сакланышы уртача. Кулъязма XIX гасырның икенче яртысында реставрацияләнгән: кәгазьләренең төп яклары өстәмә кәгазьләр ябыштырып тегелгән, 8–10 нчы кәгазьләренең тексты яңартып язылган. Әлеге өстәмә кәгазьләр XIX гасыр уртасына нисбәтле. Дефектлары: кәгазьләре дымланып пычранган. 54а, 62б, 63а кәгазьләре аеруча пычрак. 1–2 нче кәгазьләре төбеннән аерылган.

Китап хуҗасының язмалары: 1а кәгазендә – «Ошбу китаб Мөхәммәдшакирнеке торыр, һичкемнеке ирмәс», «Мостафа, Исмәгыйль, Исхак».

Китапханәгә Казан шәһәренең Каравай бистәсендәге «Нур Ислам» мәчетеннән китапханә хезмәткәрләре А.Заһидуллин һәм И.Мөстәкыймов тарафыннан 2006 елның апрель аенда алынган.

7

7647т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Россиядә XVIII гасыр ахырында эшләнгән ачык яшел-зәңгәрсу төстәге кәгазьдә. Филиграньнәре бар.

Төбе ак җеп белән тегелгән. Тышлыгы юк.

Күләме: 37 кәгазьдә. Башы һәм ахыры юк. Пагинациясе соңгы чорда гади карандаш белән куелган.

Форматы: 16 х 19,5 см.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 11 (11,5) х 15,5 см.

Бер битендә 16 шигъри юл.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Аны күрде Йосыф нәби дога кылди,*
*Санәм сынды, ушанды – ун парә улди.*

Текстның ахыры (36б кәгазьдә):

*Мисыр әһле җөмләсенә хәбәр дөшди,*
*Бу әхвалә гаҗәибә калурлар имди.*

Бу кулъязмадагы текст башы 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасының 148 битендәге 466 нчы строфага, ахыры 266 битендәге 928 нче строфага туры килә.

Тексттагы төрки сүзләрдә тәнвиннәр шактый кулланылган.

Язу карасы – көрән һәм ачык көрән төсләрдә.

Язу төре – нәстәгъликъ-шикәстә.

Кустодлары бар.

Сакланышы уртачадан түбән. Дефектлары: бөтен кәгазьләренең дә төп ягындагы түбәнге тарафлары һәм кәгазьләрнең аскы өлешләре тетелгән-ашалган. Кәгазьләрнең шактые пычрак һәм таплы, кайберләрендә очкын төшүдән янып үтәли тишелгән урыннары бар (мәсәлән, 4 нче кәгазьдә якынча 1 см диаметрында). 29 һәм 30 нчы кәгазьләр төптән аерылган һәм алар яртышар кәгазь форматыннан бераз



*«7647т» шифрлы кулъязма. 18а кәгазь.*

гына зуррак, читләре ертылган-таушалган. 36 һәм 37 нче кәгазьләр дә төптән аерылганнар, читләре тетелгән. 37 нче кәгазьнең урыны текст эчтәлегенә туры килми.

Күчерелгән вакыты – филиграньдә «1789» ел күрсәтелгән.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең фәнни-археографик экспедициясе вакытында Татарстан Республикасының Арча районындагы Носы авылында Гарифҗан Габдрахмановтан китапханә хезмәткәре Фәридә Хафизова тарафыннан 2023 елның 19 июлендә алынган.

8

2078т قصهء یوسف

Авторы – Кол Гали.
«Кыйссаи Йосыф».



*«2078т» шифрлы кульязма. 30а кәгазь.*

Россиядә XVIII гасыр ахырында эшләнгән ачык яшел төстәге кәгазьдә. Филиграньнәре бар.

Төбе җеп белән тегелгән. Тышлыгы юк.

Күләме: 63 кәгазьдә. Башы юк. Пагинациясе соңгы чорда гади карандаш белән куелган.

Форматы: 15,5 х 24 см.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 9,5 х 14,5 см.

Бер битендә 14 (15) шигъри юл.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Ул угъланны кәм бәһайә сат(ун) алгыйл, –*
*Тәлим мал бәһайә сатгыйл имди.*

Текстның ахыры (63б кәгазьдә):

*Бу китабны бу арада тәмам кыйлдым,*
*Вә нәгъәсна вә әййакәр кыйла имди.*

Бу кулъязмадагы текст башы 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасының 90 битендәге 179 нчы строфага, ә ахыры 294 битендәге 1010 нчы строфага туры килә.

Тексттагы төрки сүзләрнең шактыенда хәрәкәләр һәм тәнвиннәр кулланылган. Тәнвиннәр, мәсәлән, 1а кәгазьдә «сат(ун)», 5а кәгазьдә «бәнд(ән)», «сүз(ин)», 15б кәгазьдә «алтунд(ан) улс(ун)» рәвешендә.

Язу карасы – төп тексты көрән, фасыл исемнәре кызыл төсләрдә.

Язу төре – нәсехкә якын нәстәгъликъ.

Кустодлары бар.

Сакланышы уртача. Кулъязманың 2–3 нче һәм 9 нчы кәгазьләре реставрацияләнгән. Дефектлары: башындагы һәм ахырдагы битләре тегелгән җебеннән аерылган. 19б кәгазе дефектлы. 23а һәм 45б кәгазьләрдәге фасыл исемнәренең язуы бозылган. Иң ахыргы – 63 нче кәгазе таушалган, язуы начар укыла.

Күчерелгән вакыты – филиграньнәрендә «1791» һәм «1795» еллар күрсәтелгән, колофонда 179? (соңгы саны танылмый).

Күчерелгән урыны – Олуг Кавал авылы.

Күчерүчесе – 25а кәгазьдә «кәтәбәһе Сәедкол» диелгән, колофондагы исем танырлык түгел.

Колофоны (63б кәгазьдә): «Буны йаздым... Бу китаб Йосыфның ... тарих мең дә йите йөз тукса[н] ... айында, йегерме бишенче көнендә йазылды. Дүшәнбә көн иде. Бу китаб Олуг Кавалның Котлы...».

2008 елның декабрь аенда Казан шәһәрендә сатып алынган.

**Бу кулъязма турында мәгълүмат басылды:**

1. «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кулъязмаларына тасвирламалар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2009. – Б. 20–21. – (Бер бит факсимилесы белән). 2009 елда чыккан тасвирламада бу кулъязма турындагы мәгълүмат «2069т» шифры белән басылган иде, дөресе – «2078т».

9

1402т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Күләме: 1 кәгазьдәге фрагмент. Иске кульъязма китапка тышлык өчен ябыштырылган аерым кәгазь битләренең берсе.

Россиядә XVIII гасырның икенче яртысында эшләнгән ак төстәге кәгазьдә.

Форматы: 14,5 х 19 см.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 12,5 х 15,5 см.

Бер битендә 16 шигъри юл.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Ошбу дөши буйлә күрдем һич гөмансыз,*
*Йа, әбәти, бәңа тәэвил кыйлгыл имди.*

Текстның ахыры (1б кәгазьдә):

*Хәмд-сәна [тәлим айгыл] Сөбханыңа*
*Сөбхан сәңа тәлим ихсан кыйлур имди.*

Бу фрагменттагы текст башы 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасының 52 битендәге 24 нче строфага, ахыры 54 битендәге 29 нчы строфага туры килә.

Язу карасы – ачык көрән төстә.

Язу төре – нәстәгъликъ-шикәстә.

Сакланышы начар. Дефектлары: кәгазе таушалган, бит читендәге язуы начар танылa.

Күчерелгән вакыты – XVIII гасыр ахыры.

Татарстан Республикасының Арча районындагы Яңа Кишет авылында Фәйрүзә Шәрәфиевадан китапханә хезмәткәре А.Заһидуллин тарафыннан 1996 елның августында алынган.

***

Әле тасвирланган «1402т» һәм «1401т» (№4 тасвир) күчермәләре, беренче карашка, бер үк кульъязма кебек, язулары бер-берсенә охшаш. Өстәвенә, икесе дә китапханәгә

бер үк вакытта һәм бер үк кешедән алынганнар. Ләкин аларның палеографик үзенчәлекләре ике аерым күчермәдән калган фрагментлар икәнлеген белдерә. Берсенең кәгазе Европада, ә икенчесенеке Россиядә төрле чорларда эшләнгән.



*«1402т» шифрлы кулъязма. 1а кәгазь.*

Шигъри юллар язылган баганалары «1401т» күчермәсендә таррак һәм язуы да ваграк. Тәфсилләп караганда хәреф элементларының язылышында да аермалар күрергә мөмкин.

Әлеге ике текстның бер-берсенә охшаш булулары, алардагы күпчелек хәрефләрнең бер төрле язылышлары һ.б. палеографик уртаклыклары үз чорларына хас язу хасиятләрен чагылдыралар. Гомумән, татар кулъязмаларының күпчелеге аерым чор-дәверләрдә (якынча гасырларда яки яртышар гасыр арасында) бер-берләренә шактый охшаш рәвешле булган. Мәсәлән, төрле кешеләрнең язу-почерклары XVII гасырның урталарына кадәр бер төрлерәк булсалар, шул ук гасырның икенче яртысыннан алып XVIII гасыр урталарына хәтле бүтәнрәк рәвештә, XVIII гасыр ахырыннан алып XIX гасыр уртасына кадәр башкачарак булганлыкларын әйтергә мөмкин.

**Бу кулъязма турында мәгълүмат басылды:**

1. Мәрданов Р. Ун еллык археографик хезмәт // Китапханә хәбәрләре = Библиотечный вестник. – 2002. – № 1. – Б. 15.

2. Мәрданов Р. Тарих битләрен актарганда... // Казан утлары. – 2002. – № 3. – Б. 126.

3. «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кулъязмаларына тасвирламалар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2009. – Б. 22–23. – (Бер бит факсимилесы белән).

1763т قصهء یوسف

Авторы – Кол Гали.
«Кыйссаи Йосыф».



*«1763т» шифрлы кулъязма. 38а кәгазь.*

Россиядә XVIII гасыр ахырында эшләнгән саргылт төстәге кәгазьдә. Филиграньнәре бар.

Күләме: 52 кәгазьдә. Башы һәм ахыры юк. Пагинациясе соңгы чорда гади карандаш белән куелган.

Тышлыгы – өстеннән күн белән тарттырылган катыргы. Аның өстеннән зәңгәр төстәге киндер тукыма белән тышланган.

Форматы: 17 (17,5) х 22 см.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 10,5 (11) х 15,5 см.

Бер битендә 16 (17), 50а кәгазендә – 21 шигъри юл.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Әүлийа вә әткыйа һөммәи динләрә,*
*Җөмләсен дә Халикъ разый улсун имди.*
*[Йа,] Мөхәммәд, бу дөшне Йосыф күрди,*
*Ай-күн, бер улдуз сәҗдә кыйлди.*

Болардан беренче бәйт әсәрнең 1983 елгы басмасында юк, ә икенче бәйте 1983 ел басмасында 424 биттәге 24(3) нче строфага туры килә.

Текстның ахыры (52а кәгазьдә):

*Һәр каныксы сү деләсә сәфә вирде,*
*Мотабәгат кыйлмаклыга тәшриф күрде.*

Бу кулъязмадагы текст ахыры 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасының 224 биттәге 764(1) нче строфага туры килә.

Текстта төрки сүзләрдә хәрәкәләр һәм тәнвиннәр куелган урыннары бар. Тәнвиннәр, мәсәлән, 1а кәгазьдә «бер(ин)-бер(ин)», 22б кәгазьдә «Халикъд(ан)» һәм «гөнаһлар(ин)», 23а кәгазьдә «сәбәбд(ән)» рәвешендә. «Уау» хәрефләре өстенә өчәр нокта куелган.

Язу карасы – төп тексты һәм 44б кәгазьдәге фасыл исеме көрән, ә башка фасыл исемнәре кызыл төстә.

Язу төре – нәстәгъликъ.

Кустодлары бар. Кайбер битләрдәге кустодлар көрән (48б кәгазьдә кызыл) төстәге гади бизәк-кыса эченә алынган.

Сакланышы уртача. Дефектлары: кулъязманың 1 нче кәгазе урталай ертылган һәм җеп белән тегелгән. 1–2

кәгазьләрнең төп яклары таушалган. 1–17, 39–52 нче кәгазьләренең читләре аеруча тетелгән. 7–8 һәм 15 нче кәгазьләре тегелгән җебеннән аерылган. Кайбер битләре (мәсәлән, 46б–47а кәгазьләр) шәмәхә төстәге карага буялган. 11 нче кәгазе үтәли тишелеп ертылган, 38 нче кәгазьнең уртасы ертылган.

Күчерелгән вакыты – филиграньдә «1801» ел күрсәтелгән.

Күчерүчесе – Шәрифулла, дусты Габделгалләм өчен.

Кулъязманың 18а кәгазендә «Шәрифулла ли-әҗли дустым Габделгалләм дәйү беләсезләр» дигән юллар язылган.

Татарстан Республикасының Теләче районындагы Урта Мишә авылында Гөлбикә Нәбиуллинадан китапханә хезмәткәре А.Заһидуллин тарафыннан 1996 елның августында алынган.

**Бу кулъязма турында мәгълүмат басылды:**

1. Мәрданов Р. Ун еллык археографик хезмәт // Китапханә хәбәрләре = Библиотечный вестник. – 2002. – № 1. – Б. 15.

2. Мәрданов Р. Тарих битләрен актарганда... // Казан утлары. – 2002. – № 3. – Б. 126.

3. «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кулъязмаларына тасвирламалар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2009. – Б. 24–25. – (Бер бит факсимилесы белән).

1121т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.
«Кыйссаи Йосыф».



*«1121т» шифрлы кулъязма. 14б кәгазь.*

Россиядә XIX гасыр башында эшләнгән яшькелт-зәңгәр төстәге кәгазьдә. Филиграньнәре бар.

Төбе җеп белән тегелгән. Тышлыгы юк.

Күләме: 76 кәгазьдә (кулъязма җыентыкның 14б–89б кәгазьләрендә). Башы бар, ахыры юк. Пагинациясе соңгы чорда гади карандаш белән куелган.

Форматы: 16,2 х 19,5 см.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 11 х 16 см.

Бер битендә 16 шигъри юл.

Текстның башы (14б кәгазьдә):

*Әлхәмдү шөкер, сипас ул Әхәдә,*
*Мөлке би-зәваль ул Самәдә.*

Текстның ахыры (89б кәгазьдә):

*Каил, самигъ бу мөзнибә дога кыйлса,*
*Мөҗиб доганы мөстәҗаб кыйлур имди.*

Бу кулъязмадагы текст башы 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасының 46 битендәге 1 нче строфага, ә ахыры 292 битендәге 1002 нче строфага туры килә.

Текст «уау» хәрефләре өстенә өчәр нокта куеп һәм тәнвиннәр (кайбер битләрендә шактый) кулланып язылган палеографик үзенчәлекләргә ия. Тәнвиннәр, мәсәлән, 15б кәгазьдә «хатеремд(ән)» һәм 69б кәгазьдә «хәл(ин)» рәвешендә.

Язу карасы – текст ачык һәм караңгы көрән, ә фасыл исемнәре кызыл төсләрдә. Кайбер гадәти бәйт-юллар да (мәсәлән, 37б кәгазьдә) кызыл төстәге кара белән язылган. Текст 83б кәгазьдә көрән төстәге кара белән бер сызыклы, 84а–89б кәгазьләрдә кызыл төстәге икешәр сызыклы рамкасыга алынган.

Язу төре – нәстәгъликъ.

Кустодлары бар.

Күчерелгән вакыты – филиграньнәрендә «1803» һәм «1804» еллар күрсәтелгән.

Сакланышы уртача. Кулъязманың битләре, бер кат сүтелгәннән соң, өстәмә кәгазьләр ябыштырып яңадан

төпләнгән. Дефектлары: 84–85 нче кәгазьләре җептән аерылган, башка берничә бите җебенә начар эләгеп тора. Битләре таплы, кайберләре (мәсәлән, 21б, 22а, 89б) аеруча пычрак.

Кулъязманың 1а–14а кәгазьләрендә Ислам дине нигезләре һәм намаз тәртипләренә багышланган текст язылган.

Казан шәһәренең «Мәрҗани» мәчетеннән китапханә хезмәткәрләре Р.Мәрданов һәм И.Һадиев тарафыннан 1996 елның 26 мартында алынган иде.

**Бу кулъязма турында мәгълүмат басылды:**

1. «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кулъязмаларына тасвирламалар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2009. – Б. 26–27. – (Бер бит факсимилесы белән).

12

2069т قصهء یوسف

Авторы – Кол Гали.
«Кыйссаи Йосыф».



*«2069т» шифрлы кулъязма. 2а кәгазь.*

Россиядә XIX гасыр башында эшләнгән зәңгәр-яшькелт төстәге кәгазьдә. Филигране бар.

Төбе ак җеп белән тегелгән. Тышлыгы юк.

Күләме: 2 кәгазьдә. Башы һәм ахыры юк. Пагинациясе соңгы чорда гади карандаш белән куелган.

Форматы: 17,4 х 22,8 см.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 12 (12,5) х 15,5 (16) см.

Бер битендә 17 шигъри юл.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Ул Таймус Малик Мәгъриб ийәси,*
*Йөз бең ирд(ән) артук дәхи аның сүзи.*

Текстның ахыры (2б кәгазьдә):

*Бу гәз мәдәд деләрмән сәнд(ән) йәнгә,*
*Бу угъланны бәңа мотыйг кыйлгыл имди.*

Бу кулъязмадагы текст башы 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасының 128 битендәге 367 нче строфага, ахыры 148 битендәге 464 нче строфага туры килә. 1б һәм 2а кәгазьләре арасында ике кәгазь күләмендәге өзеклек бар.

Текстта тәнвиннәр шактый кулланылган (һәр битендә уннан артык) һәм кайбер сүзләрдә хәрәкәләр куелган.

Язу карасы – көрән төстә.

Язу төре – нәстәгъликъ-шикәстә.

Кустодлары бар.

Күчерелгән вакыты – XIX гасырның беренче чиреге (филигране 1800–1810 нчы елларга туры килә).

Сакланышы уртачадан түбәнрәк: кәгазь читләре таушалган һәм дымланып тапланган.

Китапханәгә Казан шәһәрендә 2008 елда алынган.

13

3364т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.
«Кыйссаи Йосыф».



*«3364т» шифрлы кулъязма. 6а кәгазь.*

Россиядә XIX гасыр башында эшләнгән зәңгәрсу-яшькелт төстәге кәгазьдә. Филиграньнәре бар.

Күләме: 6 кәгазьдә. 1–4 нче кәгазьләре ак җеп белән тегелгән. Башы һәм ахыры юк. Һәр биттәге текст нәзек итеп сызылган парлы рамка эчендә. Пагинациясе соңгы чорда гади карандаш белән куелган.

Форматы: 16 х 21 см.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 11 х 15,5 (16) см.

Бер битендә 16 шигъри юл.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Аның күңели дөшмеш ике йегет,*
*Дин мөрәүвәт икеләси ике рашид.*

Текстның ахыры (6б кәгазьдә):

*Көфер ширкәт михнәтендән кортыласән,*
*Дөнья-ахирәт дәүләти күрнүр имди.*

Бу кульязмадагы текст башы 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасының 48 битендәге 7 нче строфага, ахыры 90 битендәге 175 нче строфага туры килә.

Текстта тәнвиннәр кулланылган.

Язу карасы: төп текст – ачык көрән төстә. Фасыл башы кызыл кара белән теркәлгән һәм рамкалары да кызыл белән сызылган.

Язу төре – нәстәгъликъ-шикәстә.

Кустодлары булган, хәзер бик начар күренә.

Күчерелгән вакыты – филиграньдә «[18]09» ел күрсәтелгән.

Сакланышы начар. Дефектлары: кәгазьләр бик таушалган, пычранган, читләре тетелгән. Һәммәсе дә төп ягыннан горизонталь рәвештә ертылганнар.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең фәнни-археографик экспедициясе вакытында Татарстан Республикасының Арча районындагы Югары Пошалым авылында Нургали Зариповтан китапханә хезмәткәре А.Заһидуллин тарафыннан 2016 елның август аенда алынган.

## 14

1400т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Россиядә XIX гасыр башында эшләнгән ачык зәңгәр төстәге кәгазьдә. Филиграньнәре бар.



*«1400т» шифрлы кулъязма. 8а кәгазь.*

Күләме: 10 кәгазьдә. Башы һәм ахыры юк. Пагинациясе соңгы чорда гади карандаш белән куелган.

Форматы: 16 х 21 см.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 13 (13,5) х 17,5 (18) см.

Бер битендә 15 (16) шигъри юл.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Ул угъланга сорар, әйдүр: Әйа, тыйфел!*
*Галәм ичрә йукдур сәнең һәргиз малуң.*

Текстның ахыры (10б кәгазьдә):

*Бичара Зөләйхайә ул хуш килди,*
*Шул йул үзрә һәрдәм гыйшкы артар имди.*

Бу кульязмадагы текст башы 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасының 172 битендәге 556(1) нче строфага, ә ахыры 212 битендәге 717 нче строфага туры килә. Кәгазьләре сакланмаганлыктан, бу кульязмадагы текст башы һәм ахыры арасында өзеклекләр бар. 2а кәгазендә текст язылмыйча, буш калган, 1б кәгазьдән соңгы текст 2б кәгазьдә дәвам итә.

Тексттагы аерым сүзләрдә хәрәкәләр һәм тәнвиннәр кулланылган.

Кустодлары бар.

Язу карасы – ачык көрән төстә.

Язу төре – нәстәгъликъ.

Күчерелгән вакыты – филиграньдә «1814» ел күрсә-телгән.

Сакланышы уртача: бит читләре тузган, язуы уңган.

Кульязманың 1а кәгазендә: «Ильяс, Таҗетдин, Юныс, Мөхәррәм», «Габделвахид Габделкәрим угылы» һәм «Габдеррафигъ Габделвахид угылы» дигән исемнәр язылган.

Россия, Бәйсез Дәүләтләр Берлегенең Европа илләре мөселманнарының Үзәк диния нәзарәте (Уфа шәһәре) мәчетеннән китапханә хезмәткәре Р.Мәрданов тарафыннан 1998 елның март аенда алынган иде.

**Бу кульязма турында мәгълүмат басылды:**

1. «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кульязмаларына тасвирламалар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2009. – Б. 28–29. – (Бер бит факсимилесы белән).

1859т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.
«Кыйссаи Йосыф».



*«1859т» шифрлы кулъязма. 41а кәгазь.*

Россиядә XIX гасыр башында эшләнгән саргылт төстәге кәгазьдә. Филиграньнәре бар.

Төбе җеп белән тегелгән. Тышлыгы юк.

Күләме: 73 кәгазьдә. Башы һәм ахыры юк. Пагинациясе соңгы чорда гади карандаш белән куелган.

Форматы: 16,7 (17) х 21,4 см.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 12 х 15,5 (16) см.

Бер битендә 15 шигъри юл.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Мәшһүрдүр айәтдә ул Җәббардан,*
*Бер җәһүди вар иде, ады Бостан.*

Текстның ахыры (73б кәгазьдә):

*Йосыф бер кол сәтун алды Бәшир атлу,*
*Ошпу сүзе дыңламага йаулак датлу.*

Бу кулъязмадагы текст башы 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасының 424 битендәге 24(2) нче строфага, ә ахыры 270 битендәге 937 нче строфага туры килә.

Текстта «уау» хәрефләре өстенә өчәр нокта куелган, төрки сүзләрдә хәрәкәләр һәм тәнвиннәр куелган урыннары бар. Тәнвиннәр, мәсәлән, 2б кәгазьдә «безд(ән)», 4б кәгазьдә «шәфкъәт(ин)», 48б кәгазьдә «гыйльм(ин)», 73б кәгазьдә «оҗмахд(ан)» рәвешендә.

Язу карасы – төп тексты көрән, ә фасыл исемнәре кызыл төсләрдә. Кайбер аерым юллар да (мәсәлән, 40а, 41а, 44б, 63а кәгазьләрдә) кызыл белән язылган.

Текст 1–2, 13а, 31б кәгазьләрдә кызыл төстәге кара белән, ә 3–10 кәгазьләрдә сыек яшел төстәге кара белән сызылган рамкага алынган.

Язу төре – нәстәгъликъ.

Кустодлары бар.

Күчерелгән вакыты – филиграньнәрендә «1813» һәм «1815» еллар күрсәтелгән.

Күчерүчесе – Габдулла ибне Дауд ибне Ишм[өхәммәд] ибне Динмө[хәммәд] ибне Бикмөхәммәд ибне Кодаш.

Сакланышы уртача. Дефектлары: дәфтәрләре җеп бе-

лән тегелгән төбеннән аерылган. Башындагы ике кәгазе җебеннән аерылган. Кулъязманың төбе юешләнү кичергән. 1 нче кәгазе бик таушалган. Пычрак һәм таплы битләре бар.

Кулъязманың кайбер бит читләрендә карандаш белән соңрак язылган хаталы сүзләр һәм гыйбарәләр, җыр юллары бар. Мәсәлән, 48б кәгазьдә:

1) «Базарлардан алыб кайт ике битле (?) гөл...»;

2) «Өзелеб уйлар уйлаганда дәртле күңлем йугала».

3) 57б кәгазьдә: «Миңнезакир Кәмаледдинев угылына чыкмыш».

Самара өлкәсенең Шонталы районындагы Динис авылы мәчетеннән китапханә хезмәткәре Р.Мәрданов тарафыннан 1997 елның 14 августында алынган иде.

**Бу кулъязма турында мәгълүмат басылды:**

1. Мәрданов Р. Ун еллык археографик хезмәт // Китапханә хәбәрләре = Библиотечный вестник. – 2002. – № 1. – Б. 15.

2. Мәрданов Р. Тарих битләрен актарганда... // Казан утлары. – 2002. – № 3. – Б. 126.

3. Марданов Р. Сбережения // Татарский мир = Татар дөньясы. – 2005. – Январь (№23–24).

4. «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кулъязмаларына тасвирламалар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2009. – Б. 30–31. – (Бер бит факсимилесы белән).

16

1774т قصهء یوسف

Авторы – Кол Гали.
«Кыйссаи Йосыф».



*«1774т» шифрлы кулъязма. 46б кәгазь.*

Россиядә XIX гасыр башында эшләнгән ак төстәге кәгазьдә. Филиграньнәре бар.

Төбе җеп белән тегелгән. Тышлыгы юк.

Күләме: 56 кәгазьдә. Арада 14а дип бит саны куелган өстәмә кәгазе бар. Башы һәм ахыры юк. Пагинациясе соңгы чорда гади карандаш белән куелган. Кульязманың 18а–48а кәгазьләрендә гарәп саннары белән язылган пагинация сакланган (26–60 саннары).

Форматы: 16 x 21,4 см.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 10 (10,5) x 15 см.

Бер битендә 15 шигъри юл.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Кыйссалардан, хикмәтләрдән күрклүрәге,*
*Усанмадан дыңламага датлуракы.*

Текстның ахыры (55б кәгазьдә):

*[Нәкыль кыйлд]ы, Халикъга улды васләт,*
*Әрхәм аңа рәхмәт нисар кыйлды имди.*

Бу кульязмадагы текст башы 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасының 50 битендәге 22 нче строфага, ә ахыры 288 битендәге 989 нчы строфага туры килә.

Язу карасы – төп тексты һәм кайбер фасыл исемнәре (мәсәлән, 5б, 7б, 23а кәгазьләрдә) көрән, башка фасыл исемнәре кызыл төсләрдә.

Текст 11б–12а, 22а, 41 кәгазьләрдә карандаш белән рамкага алынган. 12б–14а кәгазьләрдә ике багана итеп язылган текстның юл ахырларында түгәрәк бизәк-рәсемнәр ясалган. 34б кәгазьдәге ике баганаының юллары арасына һәм фасыл исеменең ике ягына чәчәксыман бизәкләр, 46б кәгазьдәге ике багана арасына һәмзәгә охшаш өчәр бизәк ясалган. 47б кәгазьдә ике багана арасына кызыл төстәге кара белән кечкенә түгәрәксыман бизәкләр төшерелгән.

Язу төре – нәстәгъликъ элементлары кушылган нәсех.

Кустодлары бар.

Күчерелгән вакыты – филиграньдә «1815» ел күрсәтелгән.

Күчерүчесе – Габделҗәббар Габделмәннаф угылы.

Сакланышы уртача. Дефектлары: кайбер битләре тегелгән җебеннән аерылган. Кульязма түбе ягыннан юешләнгән булу сәбәпле, саргайган. Кайбер битләре һәм аерым юллары пычрак-таплы. 1–4 кәгазьләрнең түбәнге яртышар өлешләре юк, 5–6 һәм 19 кәгазьләр урталай ертылган. 50–55 кәгазьләрнең читләре, аеруча таушалып, ертылып төшкән.

Кулъязма хуҗасының язмалары (көрән төстәге кара белән): 16а кәгазьдә «Минем никахым җомга көн, җомгадин соңбулды»; 17а кәгазьдә «Йосыф китабы Габделҗәббарныкы, үзе язды»; 18а кәгазьдә «Минем үземнең «Йосыф китабы», йәнә «Раунакыль-ислам» китабы, йәнә «Сөбате гаҗизин» китабы, йәнә «Фәзаиле шөһүр» китабы, йәнә «Әмалый» китабы, «Мокаддимәт» китабы, йәнә «Чупан» китабы, йәнә «Устуани» китабы, йәнә». 30б һәм 31б кәгазьләрдә карандаш белән хат башламнары язылган. 32а кәгазьдә шәмәхә төстәге кара белән латин язуында «Гаптрәхмәнова Зарифа». 36а кәгазьдә көрән кара белән гарәп язуында «Ошбу китабны укыгучы Фатыйма». 43б кәгазьдә карандаш белән «Ошбу китаб Габделҗәббар бине Габделмәннаф угылы – йазгучы. Укыгучы – Габделҗәббар кызы Бибифатыйма».

Россия, Бәйсез Дәүләтләр Берлегенең Европа илләре мөселманнарының Үзәк диния нәзарәте (Уфа шәһәре) мәчетеннән китапханә хезмәткәре Р.Мәрданов тарафыннан 1998 елның март аенда алынган иде.

**Бу кулъязма турында мәгълүмат басылды:**

1. «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кулъязмаларына тасвирламалар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2009. – Б. 32–33. – (Бер бит факсимилесы белән).

17

2070т قصهء یوسف

Авторы – Кол Гали.
«Кыйссаи Йосыф».




*«2070т» шифрлы кулъязма. 13а кәгазь.*

Россиядә XIX гасыр башында эшләнгән зәңгәр һәм зәңгәрсу-яшькелт төсләрдәге кәгазьләрдә. Филиграньнәре бар.

Төбе ак җеп белән тегелгән. Тышлыгы юк.

Күләме: 20 кәгазьдә. Башы һәм ахыры юк. Пагинациясе соңгы чорда гади карандаш белән куелган.

Форматы: 17 x 22 см.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 12,5 x 15 см.

Бер битендә 15 шигъри юл.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Ул дәмд[ә] шидтәтләр китде, рахәт улды,*
*Мисыр эчр[ә] Йосыф улу мәлик улды.*

Текстның ахыры (20б кәгазьдә):

*Әһле сәтер, каум, хәсъм кардәшләри,*
*Дүгәл ишә кадыйрдур Изем вари.*

Бу кулъязмадагы текст башы 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасының 210 битендәге 714 нче строфага, ә ахыры 274 битендәге 960(1) нче строфага туры килә. 16 һәм 17 нче кәгазьләр арасындагы бер кәгазе төшкәнлектән, текстка өзеклек кергән.

Текстта төрки сүзләрдә хәрәкәләр (мәсәлән, 11б кәгазьнең соңгы юлы) һәм тәнвиннәр кулланылган. Тәнвиннәр, мәсәлән, 10а кәгазьдә «койуд(ан)», 15а кәгазьдә «сезд(ән) рәвешендә. 7б кәгазенең беренче баганасы тексты алдында (уртасына хәтле) кечкенә түгәрәкләр рәвешендәге бизәкләр ясалган.

Язу карасы – кара һәм караңгы көрән төсләрдә.

Язу төре – нәстәгъликъ.

Кустодлары бар. 6б–18б кәгазьләрдәге кустодлар гади һәм бизәкле рамкаларга алынган.

Күчерелгән вакыты – филиграньдә «1821» ел күрсәтелгән.

Сакланышы уртачадан түбәнрәк. Дефектлары: кәгазьләр пычрак, читләре таушалган. Дымланудан калган зур таплары бар. 3б, 4а, 8б–10а, 15б, 16б, 20б кәгазьләре аеруча пычрак. 1а кәгазенең язуы уңган.

Казан шәһәрендә 2008 елның декабрь аенда сатып алынган.

**Бу кульязма турында мәгълүмат басылды:**

1. «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кульязмаларына тасвирламалар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2009. – Б. 34–35. – (Бер бит факсимилесы белән).

## 18

343т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Россиядә XIX гасыр башында эшләнгән ачык яшькелт төстәге кәгазьдә. Филигране бар.

Күләме: 1 кәгазьдәге фрагмент.

Форматы: 16,8 x 21 см.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 11 x 16,3 см.

Бер битендә 19 шигъри юл.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Мони кыйлуб Халикъдан рәхмәт улмаз,*
*Йәгрәк улдур – тәүбә кыйлыб дүнгел имди.*

Текстның ахыры (1б кәгазьдә):

*Йосыф әйдүр: «Һәргиз сезгә сөч кыйлмадым,*
*Буның кеби айырыксы дөш һич күрмәдем.*

Бу фрагменттагы текст башы 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасының 68 битендәге 98 нче строфага, ә ахыры 74 битендәге 115(1) нче строфага туры килә.

Язу карасы – текст ачык көрән, фасыл исеме ачык кызыл төсләрдә.

Һәр битендә ачык кызыл төстәге кара белән ике баганалы рамка-кыса сызылган.

Язу төре – нәстәгъликъ.

Күчерелгән вакыты – XIX гасыр башы.

Сакланышы уртача.

Р.Мәрдановның китапханәгә бүләк итеп биргән кульязмалар һәм иске басма китаплар тупламасыннан. Татарстан Республикасының Әгерҗе районы Яңа Аккуҗа авылында Лотфия Арслановадан 1990 елда алынган иде.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең «Татар археографиясе» сериясендә нәшер ителгән басмаларның арткы (дүртенче) тышлык битләрендә «Кыйссаи Йосыф»




*«343т» шифрлы кулъязма. 1а кәгазь*

әсәренең шушы – «343т» шифрлы кулъязма бите иллюстрация итеп кулланылды.

**Бу кулъязма турында мәгълүмат басылды:**

1. Мәрданов Р. Ун еллык археографик хезмәт // Китапханә хәбәрләре = Библиотечный вестник. – 2002. – № 1. – Б. 15.

2. Мәрданов Р. Тарих битләрен актарганда... // Казан утлары. – 2002. – № 3. – Б. 126.

3. «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кулъязмаларына тасвирламалар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2009. – Б. 38–39. – (Бер бит факсимилесы белән).

19

1667т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Күләме: 1 кәгазьдәге фрагмент.

Россиядә XIX гасыр башында эшләнгән яшькелт-зәңгәр төстәге кәгазьдә. Филигране бар.

Форматы: 14 х 19 см.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 11,5 х 15,5 см.

Бер битендә 17 шигъри юл.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*[Дидем: бу] ун урыклук карендәшләрем,*
*Уны зариф, уны шәриф ирәнләрим.*

Текстның ахыры (1б кәгазьдә):

*Йәһүдә һәргиз дәрман улумади,*
*Анлари үгүтләб манигъ кылумади.*

Бу фрагменттагы текст башы 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасының 68 битендәге 89 нчы строфага, ә ахыры 70 битендәге 105 нче строфага туры килә.

Язу карасы – көрән төстә.

Язу төре – нәстәгъликъ.

Күчерелгән вакыты – XIX гасыр башы.

Сакланышы начар, кәгазь читләре тетелгән.

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе һәм Казан дәүләт университетының берләштерелгән фәнни-археографик экспедициясе вакытында Пермь өлкәсенең Барда районы Барда авылы музееннан 2000 елның июль аенда алынган.

**Бу кульъязма турында мәгълүмат басылды:**

1. «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кульъязмаларына тасвирламалар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2009. – Б. 40–41. – (Бер бит факсимилесы белән).




*«1667т» шифрлы кулъязма. 1б кәгазь.*

20

1267т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Күләме: 1 кәгазьдәге фрагмент.

Россиядә XIX гасыр башында эшләнгән начар сыйфатлы саргылт төстәге кәгазьдә.

Форматы: 17,4 х 22 см.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 14,5 х 18 см.

Бер битендә 14 (15) шигъри юл.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Үдә икән бән бер сакынч кылдым иди,*
*Бу иш эчрә сезгә гөман кыйлдым иди.*

Текстның ахыры (1б кәгазьдә):

*Йәһүдә һәргиз дәрман улумади,*
*Үгүт берлә аслан манигъ кылумади.*

Бу фрагменттагы текст башы 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасының 68 битендәге 91 нче строфага, ахыры 70 битендәге 105 нче строфага туры килә.

Язу карасы – ачык көрән төстә.

Язу төре – нәстәгъликъ элементлары кушылган нәсех.

Күчерелгән вакыты – XIX гасыр башы.

Сакланышы начар: кәгазе таушалган, бит читендәге язулары уңган.

Китапханәгә тупланган басма китапларның берсе эченнән китапханә хезмәткәре Р.Мәрданов тарафыннан 2002 елда табып алынды.

**Бу кульязма турында мәгълүмат басылды:**

1. «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кульязмаларына тасвирламалар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2009. – Б. 42–43. – (Бер бит факсимилесы белән).




*«1267т» шифрлы кулъязма. 1б кәгазь.*

1668т قصهء یوسف

Авторы – Кол Гали.
«Кыйссаи Йосыф».
Күләме: 1 кәгазьдәге фрагмент.




*«1668т» шифрлы кулъязма. 1а кәгазь.*

Россиядә XIX гасыр башында эшләнгән яшькелт-зәңгәр төстәге кәгазьдә. Филигране бар.

Форматы: 16,3 х 20 см.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 10,5 х 15,5 см.

Бер битендә 17 шигъри юл.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Йосыф әйдү[р]: «Бәндән ишет, әйа мәлик,*
*Ишетдекүң дотубән, улгыл салик.*

Текстның ахыры (1б кәгазьдә):

*Хакыйкатьдә, йа, Йосыф, ни диден? – дир.*
*Гожәөб кылдуң, Халикъ сонгын күргел имди.*

Бу фрагменттагы текст башы 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасының 112 битендәге 292 нче строфага, ахыры 114 битендәге 307 нче строфага туры килә.

Язу карасы – караңгы көрән төстә.

Язу төре – нәстәгъликъ-шикәстә.

Күчерелгән вакыты – XIX гасыр башы.

Сакланышы яхшы.

Тобольск шәһәренең имамы Габделмәҗит хәзрәт тарафыннан 2002 елда китапханәгә бүләк итеп бирелгән.

**Бу кульъязма турында мәгълүмат басылды:**

1. Мәрданов Р. Ун еллык археографик хезмәт // Китапханә хәбәрләре = Библиотечный вестник. – 2002. – № 1. – Б. 15.

2. Мәрданов Р. Тарих битләрен актарганда... // Казан утлары. – 2002. – № 3. – Б. 126.

3. Марданов Р. Сбережения // Татарский мир = Татар дөньясы. – 2005. – Январь (№23–24).

4. «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кульъязмаларына тасвирламалар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2009. – Б. 44–45. – (Бер бит факсимилесы белән).

22

1030т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Европада XIX гасыр башында эшләнгән ак төстәге кәгазьдә. Филиграньнәре бар.

Күләме: 3 кәгазьдәге фрагмент. Өч кәгазе дә өлешчә ертылганнар. Пагинациясе соңгы чорда гади карандаш белән куелган.



*«1030т» шифрлы кулъязма. 1а кәгазь.*

Форматы: 1 нче кәгазь – 16 х 16 см; 2 нче кәгазь – 16 х 18,5 см; 3 нче кәгазь – 16 х 12 см.

Бу фрагменттагы текст 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасының 192 битендәге 644(2) нче строфасыннан алып 194 битендәге 648 нче строфага хәтле 1а кәгазьдә, 194 битнең 652 нче строфасыннан алып 196 битнең 659 нчы строфасына кадәр 1б кәгазьдә, 280 битнең 966 нчы строфасыннан 282 битнең 973 нче строфасына хәтле 2а кәгазьдә, 282 битнең 974(1) нче строфасыннан 284 битнең 979 нчы строфасына кадәр 2б кәгазьдә, 284 битнең 980 нче строфасыннан 286 битнең 983 нче строфасына хәтле 3а кәгазьдә һәм 288 битнең 989 нчы строфасыннан 992(1) нче строфасына кадәр 3б кәгазьдә теркәлгән.

Язу карасы – ачык көрән.

Язу төре – нәстәгъликъ.

Күчерелгән вакыты – филигране XIX гасырның I чирегенә нисбәтле.

Сакланышы начар. Дефектлары: 1 нче кәгазе урталай ертылган, ә 2 нче кәгазьнең ярты (түбәнге) өлеше генә сакланган.

Казан шәһәренең «Мәрҗани» мәчетеннән китапханә хезмәткәрләре Р.Мәрданов һәм И.Һадиев тарафыннан 1996 елның 26 мартында алынган иде.

**Бу кульязма турында мәгълүмат басылды:**

1. «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кульязмаларына тасвирламалар / төз. Р. Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2009. – Б. 36–37. – (Бер бит факсимилесы белән).

23

777т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Россиядә XIX гасыр башында эшләнгән ак төстәге кәгазьдә.

Күләме: 1 кәгазьдәге фрагмент. Бер кәгазь битенең дүрттән бер өлеше зурлыгында.

Форматы: 9 х 11 см.



*«777т» шифрлы кульязма. 1б кәгазь.*

Бу кульъязмадагы текст фрагментлары 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасының 264 битендәге 916–920, 923–927 нче строфаларга туры килә.

Язу карасы – көрән төстә.

Язу төре – нәстәгъликъ.

Күчерелгән вакыты – XIX гасырның беренче чиреге.

Сакланышы начар, кәгазь читләре теткәләнгән.

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе һәм Казан дәүләт университетының берләштерелгән фәнни-археографик экспедициясе вакытында Пенза өлкәсенең Кузнецк районы Татар Кынадысы авылында яшәүче Усман Габдеррәшитовтан 1996 елның июль аенда алынган.

**Бу кульъязма турында мәгълүмат басылды:**

1. «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кульъязмаларына тасвирламалар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2009. – Б. 46. – (Бер бит факсимилесы белән).

497т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.
«Кыйссаи Йосыф».



*«497т» шифрлы кульязма. 11а кәгазь.*

Россиядә XIX гасырның беренче яртысында эшләнгән зәңгәр төстәге кәгазьдә. Филиграньнәре бар.

Төбе җеп белән тегелгән.

Тышлыгының бер (арткы) өлеше сакланган. Ул иске кульязма битләреннән ябыштырып эшләнгән һәм төбе күн белән капланган булган. Тышлыкның кәгазьләре аерылган, читләре ашалып түгәрәкләнгән.

Күләме: 34 кәгазьдә. Башы юк. Пагинациясе соңгы чорда гади карандаш белән куелган.

Форматы: 15,1 х 20,6 см.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 9,5 х 14,5 см.

Бер битендә 16 (17) шигъри юл.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

> ............................................ *йиде,*
> *Камулари гаҗаибдә калурлар имди.*

Текстның ахыры (33а кәгазьдә):

> *Бу арада бу китабны тәмам кыйлдым,*
> *Вә нәфәгъна вә әййакүм кыйлам имди.*

Бу кульязмадагы текст башы 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасының 180 битендәге 594 нче строфага, ә ахыры 294 битендәге 1010 нчы строфага туры килә.

Тексттагы кайбер төрки сүзләрдә хәрәкәләр куелган һәм бик еш тәнвиннәр кулланып язылган. Мәсәлән, 1а кәгазьдә «тәңремд(ән)» һәм 17б кәгазьдә «дилд(ән)-күзд(ән)» рәвешендә.

Язу карасы – текст һәм фасыл исемнәре ачык көрән төстәге кара белән язылганнар. Бер фасыл исеме (7б кәгазьдә) кызыл кара белән, ә бер фасыл исеме (31а кәгазьдә) зәңгәр кара белән теркәлгән.

31а кәгазендә кызыл төстәге кара белән рамка-кыса сызылган.

Язу төре – нәстәгъликъ элементлары кушылган нәсех.

Кустодлары бар.

Күчерелгән вакыты – филиграньнәрендә «1805» һәм «1825» еллар күрсәтелгән.

Күчерүчесе – Габдулла бине Батыркәй, мулла Мостафаның улы өчен (исеме язылмаган).

Гади бизәкле рамкага алынган колофондагы язуы: «Кәтәбәһә фәкыйрь әл-хәкыйрь би бизагать Габдулла бине мулла Батыркәй ли-әҗли ибни мулла Мостафа».

Сакланышы яхшы диярлек. 1а кәгазьнең уртасы ертылган, өске почмагы кыйгач рәвештә ертылып төшкән. 1, 4–6 кәгазьләре тегелгән җебеннән аерылган.

Кульязманы Казан шәһәрендә яшәүче шагыйрь Мөхәммәт Садри 1995 елның 5 маенда китапханәгә бүләк итеп биргән. Аның юллама хатында гамәлдәге татар графикасы белән түбәндәгеләр язылган. Беренче кәгазьдә:

«Бисмиллаһир-рахмани-рахим.

Омск өлкәсе, Тәвриз районы Кип-Куллар авылының 82 яшьлек мәчет карты Юма Абдрашев бүләк иткән бик борынгы китап үрнәге. Юма бабай аны «җиде бабамның кулдан-кулга, озыннан-озынга укый, саклап килгән китабы» диде. Юма бабай үзе «мин Күчем ханның җиденче буыны» диде.

Бу китапны ул миңа 1940 елның 15 июлендә тапшырды. Хәзер бу бабайга 135 яшь булыр иде.

Мөхәммәт Садри.

5 май, 1995 ел. Казан».

Икенче кәгазьдә:

«Бисмиллаһир-рахмани-рахим.

Килеп кергәч белем сараена,
Тәңрем, сиңа ашты теләгем.
Шаһит булсын – китапханәбезгә
Минем дә бар икән бүләгем.
Хөр Кол Гали белән бергә яшәп,
Бергә типсен иде йөрәгем.

Изге бәйрәм көннәре мөбарәк булсын!

Мөхәммәт Садри.

5 май, 1995».

**Бу кулъязма турында мәгълүмат басылды:**

1. Мәрданов Р. «Йосыф китабы»ның көен көйләп... // Китапханә хәбәрләре = Библиотечный вестник. – 1999. – № 1. – Б. 26.

2. Марданов Р. Драгоценные находки // Казань. – 1999. – № 5/6. – С. 82.

3. Мәрданов Р. Тарих битләрен актарганда... // Казан утлары. – 2002. – № 3. – Б. 126.

4. «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кулъязмаларына тасвирламалар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2009. – Б. 47–49. – (Бер бит факсимилесы белән).

5. Мәрданов Р. Китапларда милләт язмышлары... – Казан: «Милли китап» нәшр., 2010. – Б. 55.

25

779т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Россиядә XIX гасырның беренче яртысында эшләнгән ачык яшькелт төстәге кәгазьдә. Филиграньнәре бар.

Төбе җеп белән тегелгән. Тышлыгы юк.



*«779т» шифрлы кулъязма. 9а кәгазь.*

Күләме: 69 кәгазьдә. Башы һәм ахыры юк. Пагинациясе соңгы чорда гади карандаш белән куелган.

Форматы: 17,2 х 21,3 см.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 14 х 16,5 (17) см.

Бер битендә 14 (15) шигъри юл.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Монлар әйдүр: «Бу эшни кыйлмайавыз,*
*........................................ алмайавыз.*

Текстның ахыры (69а кәгазьдә):

*Йосыф сәүчи кыйссасен белүр ирсәң,*
*Нитәлекен безә мәгълүм [кылгыл имди].*

Бу кулъязмадагы текст башы 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасының 96 битендәге 211 нче строфага, ә ахыры 426 битендәге 997(6) нчы строфага туры килә.

Тексттагы кайбер төрки сүзләрдә хәрәкәләр куелган һәм тәнвиннәр кулланып язылган. Мәсәлән, 58а кәгазьдә «Хакд(ан)» һәм 61а кәгазьдә «иленд(ән)» рәвешендә.

Язу карасы – текст һәм фасыл исемнәрендә ачык көрән төстә. Бары тик бер генә фасыл исеме (29б кәгазьдә) кызыл кара белән язылган.

Язу төре – нәстәгълйкъ.

Кустодлары кәгазь битенең ике ягы өчен дә тотрыклы рәвештә бирелгән. Гадәттә, кустодлар кәгазьнең «б» тарафындагы түбәнге сул почмакта гына языла. Ә бу күчермәдә кәгазьләрнең «а» якларында да (сул почмакта) кустодлар теркәлгән.

Күчерелгән вакыты – филиграньнәрендә «1825» һәм «1826» еллар күрсәтелгән.

Сакланышы начар. Дефектлары: 1–7 нче кәгазьләре җебеннән аерылган. Кулъязма элек тулаем юешләнгән булуы сәбәпле, язулары уңган. Һәр битенең уртасыннан түбәнге өлешендәге язулары начар күренә. 11 нче кәгазьнең өске өлеше ертылган. 62–68 кәгазьләр бер-берсенә ябышканнар. 68б һәм 69 кәгазьләрдәге язулар бөтенләй күренми, укырлык түгел.

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе һәм Казан дәүләт университетының берләштерелгән фәнни-археографик экспедициясе вакытында Пенза өлкәсенең Неверкино районы Биги авылында Мөнирә Акчуринадан 1996 елның июль аенда алынган.

**Бу кульязма турында мәгълүмат басылды:**

1. «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кульязмаларына тасвирламалар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2009. – Б. 50–51. – (Бер бит факсимилесы белән).

26

486т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Кулъязманың 1–47 кәгазьләре саргылт-ак төстәге һәм 48–78 кәгазьләре яшькелт-зәңгәр төстәге, Россиядә XIX гасырның башында эшләнгән кәгазьләрдә. Ак кәгазьдә филиграньнәре юк, ә яшькелт-зәңгәрендә бар.

Тышлыгы – 1991–1995 еллар арасында катыргы һәм яшел дермантин белән тышланган.

Күләме: 76 кәгазьдә. Башы һәм ахыры бар. 77–78 нче кәгазьләрдә башка текстлар. Пагинациясе соңгы чорда гади карандаш белән куелган. 1б–7а кәгазьләрнең өске почмакларында М.Килдиев тарафыннан шәмәхә төстәге язу карасы белән 2–13 нче бит саннары куелган.

Форматы: 16 x 20,3 см.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 1–3 кәгазьләрдә 11,5 (12) x 17; 4–76 нчы кәгазьләрдә 10 (10,5) x 14,5 (15) см.

Бер битендә: 1–3 кәгазьләрдә 13 (14), 4 нче кәгазьдә 17, 5–76 нчы кәгазьләрдә 14 (16) шигъри юл.

Текстның башы (1б кәгазьдә):

*Хәмде сәна, шөкер сипас ул Әхәдә,*
*Мөлкәтенең зәвале йук ул Самәдә.*

Текстның ахыры (76б кәгазьдә):

*Бу арада бу китабни тәмам кыйлдум,*
*Вә нәфәгъна вә әййакүм кыйлар имди.*

Бу кулъязмадагы текст башы 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасының 46 битендәге 1 нче строфага, ә ахыры 294 битендәге 1010 нчы строфага туры килә.

Кулъязманың 1б–3б кәгазьләре җыентыкның төп өлешеннән кәгазенең төре, язуы, текст мәйданының зурлыгы һәм шигъри юлларның саны белән аерылып тора. Бу өч кәгазьнең юешләнгәннән калган эзләре дә башка



*«486т» шифрлы кулъязма. 3а кәгазь.*

кәгазьләрдә юк. Шулай ук бу кульязманың 3 нче һәм 4 нче кәгазьләре арасында, әсәрнең төп тексты белән чагыштырып караганда, 16 юллык өзеклек бар. 4 нче кәгазьнең нигезе: төп ягы (2,8х20,3 см) һәм югарыдагы бер юл язылган өлеше (3х14,7 см) башка кульязманыкы. Ул тасмасыман өлешләр кульязманың төп өлешен тәшкил иткән кәгазьгә ябыштырылып, уң яктагы 2–3 сүзле шигъри юл башлары дәвам иттерелгән һәм яңартып язылган. Монда саналган үзенчәлекләрне исәпкә алганда, кульязманың башындагы өч кәгазе төп өлешенә соңгырак дәвердә генә кушылган. Әгәр ул өлеше XIX гасырда яисә XX гасыр башларында өстәлгән булса, кыйссаның җуелган 16 юлы, һичшиксез, өстәп язылган булыр иде.

Кайбер битләрдә (мәсәлән, 33а, 33б, 39б, 50б, 54а кәгазьләрдә) шигъри юлларның ахырларын тутырып язу өчен өстәмә билгеләр һәм сызыклар өстәп яки ахыргы хәрефләре сузынкы итеп, бизәкләбрәк һәм калынайтып язылган. Текстта тәнвиннәр кулланылган (мәсәлән, 69б кәгазьдә 13 сүздә).

Язу карасы – ачык һәм караңгы көрән төсләрдә. Фасыл исемнәре, 41б кәгазьдә әсәрнең төп текстында булмаган гарәп телендәге ике юллык Коръән сүзләре һәм 73б кәгазьдә шигъри юлның бер өлеше кызыл кара белән язылган.

Язу төре – 1б–3б кәгазьләрдә эрерәк язылган нәстәгъликъ; калган кәгазьләрдә тотрыксыз рәвештә өлешчә нәсех һәм күпчелеге нәстәгъликъ белән язылган. Бер үк биттә текст берничә төр (нәстәгъликъ, нәсех) белән теркәлгән урыннары бар. Мәсәлән, 7б, 10а, 32б, 54б, 58б, 59а кәгазьләр.

Кустодлары бар.

Күчерелгән вакыты – филиграньдә «1827» ел күрсәтелгән.

Колофоны «Тәммәт ә[л]-китаб би-гауни Аллаһи Мәлики әл-Ваһһаб вә иләйһи мәрҗәга вәл-мәэаб. Тәммәт тәмам булды».

Сакланышы уртача. Кульязманың башындагы өлешендә (мәсәлән, 4–7 кәгазьләрдә), таушалган кәгазь битләренең



ویدوکنده شماله اولوب توبه قیلدی / سجده قیلب تنکریه یالوارور ایدی
اول وقت ساعتده جبرائیل ینه کلدی / قادر تنکریدان یوسفه سلام قیلدی
توبه نک داغی حاجتلار روا اولدی / باشننک سجده دا آق الدور دیور ایدی
بر زمان زندان ایچره قالداچی سن / عاقبتی راحت نجات اولاچی سن
مصر شهرینک ملک ایکنه قالداچی سن / بو خبرنی جبر قیلغل دیور ایدی

فصل قصه عرب

اول زمانده یوسف زندان ایچره ایدی / کنعاندان بس بر عربی مصره کلدی
درچیدا باقب یوسف آنی کوردی / تواسوروب تعجیل بر لا کچار ایمدی
جمال عربی زندانه یقین کلدی / یوسف الله ایردوکنی دوا بلدی
یا یوسف دیو بوزلادی زاری قیلدی / بن کنعاندان کلورو دیب آغلار ایدی
آتانک یعقوبنی کنعانده کوردیکم / آنونک حالی عبرتده دور کلدیم
حسرت زاری قیلدوغنی کوروب کلدیم / اولی ... نیک ... آتاد ایدی
مدام سنینک حسرتنکده وارتار یعقوب / عالم ایچره هیچ بولماز سندا محبوب
سنی انکب آغلار دوشدیره او غنوب / بر زمان وقت بخود اولوب یاتور ایدی
اینکلا صاحب ایکی کوزی کورمز اولدی / ضعیف کلدا سونکاکلاری ...
هیچ قالمز ... اولدی / ... یوسف دیو آغلار ایدی

*«486т» шифрлы кульязма. 3а, 45а кәгазь.*

читләре өстәмә кәгазьләр ябыштырылып XIX гасырда реставрацияләнгән. Язулары уңган һәм өстәмә кәгазь белән капланган урыннары яңартылып язылган. Китапны төпләп тышлаганда (1991–1995 елларда) бүтән битләре дә реставрацияләнгән.

Китап хуҗаларының язмалары түбәндәгечә:

1) XIX гасырга караган язулар (1а кәгазьдә): «Әүвәл алдым бер такта чәй, 1 сум 5 тиен... Әүвәл Әхмәд 18.. нче йылда, нуябер. Йәнә Әхмәд... Йәнә Сафиулла. Әүвәл алдым ун баш төлке тиресе – бәһасе булды кырык сум көмеш.

Ошбу китаб ийәсе
Йәшел чапан кийәсе.
Укыб сабагын белмәсә,
Күтенә күшәкә тийәсе».

2) М.Килдиев язулары.

1а кәгазьдә: «Шедевр Золото-Ордынской культуры. Соч. Али о Йосифе Прекрасном из классики татарской литературы XIII в., список относится ко II пол. XIX в. Поволжье.

<u>Кильдеевский список</u>. Был найден Кильдеевым Маратом в Казанской соборной мечети имени Шигапа Марджани 14 августа в 1991 году. В настоящее время составляет ценность личного архива Кильдеева Марата Вил угълы. В случае его смерти или утери незамедлительно нашедшему передать эту книгу в отдел рукописей И.Я.Л.И. по улице Ленина г. Казани Ахметзянову Марселю Ибрагимовичу лично!

7а кәгазьдә (гарәп хәрефләре белән): «Ошбу китабның ийәсе Килдиев Маратдыр, һәза китаб Казандагы Шиһаб Мәрҗани җәмигындән 14 нче аугустда 1991 нче сәнәдә табыб алынмыш иде».

Кулъязманың 76б–78 кәгазьләрендә татар телендә иман мәгънәсе һәм гарәп телендә намаз шартлары турындагы текстлар язылган.

Кулъязманың 1а, 7а, 78б кәгазьләрендә «Кильдиев Марат Виль улы» дигән штамп сугылган.

Казан шәһәрендә Марат Килдиевтән 1995 елның февраль аенда китапханәгә сатып алынган иде.

**Бу кульъязма турында мәгълүмат басылды:**

1. Мәрданов Р. «Йосыф китабы»ның көен көйләп... // Китапханә хәбәрләре = Библиотечный вестник. – 1999. – № 1. – Б. 26.

2. Марданов Р. Драгоценные находки // Казань. – 1999. – № 5/6. – С. 82.

3. Каталог выставки «Литературное наследие татарского народа». Из фондов Российской национальной библиотеки (г.Санкт-Петербург) и Национальной библиотеки Республики Татарстан (г.Казань), г.Казань, 30. 08 – 30. 09. 2001 г. – С. 14.

4. «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кульъязмаларына тасвирламалар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2009. – Б. 52–57. – (Бер бит факсимилесы белән).

5. Ахунов А. Загадки «Кыйсса-и Йусуф» // Татар дөньясы = Татарский мир. – 2011. – №1. – С. 11 (26б һәм 27а кәгазьләренең фоторәсеме).

6. Татар китабы = Татарская книга: альбом / төз.-авт. Р.Мәрданов, И.Һадиев; рәс. Ш.Насыйров. – Казан: Татар. китап нәшр., 2013. – Б. 86 (51б һәм 52а кәгазьләренең фоторәсеме).

## 27

1782т قصەء يوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

1–7 кәгазьләре ак төстәге, 8–19 кәгазьләре зәңгәрсу ак төстәге, 20–21 кәгазьләре зәңгәр төстәге, Россиядә XIX гасырның беренче яртысында эшләнгән кәгазьләрдә. Филиграньнәре бар.

Төбе җеп белән тегелгән. Тышлыгы юк.

Күләме: 21 кәгазьдә. Башы һәм ахыры юк. Пагинациясе соңгы чорда гади карандаш белән куелган.

Форматы: 17 (17,4) х 21,6 (22; 22,4) см.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 11,5 (12,5) х 15,5 (16) см.

Бер битендә 14 (17) шигъри юл.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Һич иксәксез утур өч мең ирәнләрә,*
*Барчасына мөкътәда булам имди.*

Текстның ахыры (21б кәгазьдә):

*Йосыф аның үзәсынга сабит улды,*
*Аркасынд(ан) басыбан менәр имди.*

Бу кульязмадагы текст башы 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасының 48 битендәге 9 нчы строфага, ә ахыры 118 битендәге 320 нче строфага туры килә.

Текстта хәрәкәләр һәм тәнвиннәр күп кулланылган. Мәсәлән, 1а кәгазьдә берничә юл тулаем хәрәкәләр белән язылган, 3а кәгазьдә «дөш(ин)», 3б кәгазьдә «безд(ән)», 7а кәгазьдә «шәфәгат(ин)», 19б кәгазьдә «үз(ин)», «хөрмәт(ин)» һ.б. рәвешләрдәге тәнвиннәр бар.

Язу карасы – караңгы һәм ачык көрән төстә.

Язу төре – нәстәгъликъ.

Кустодлары бар.

Күчерелгән вакыты – филиграньдә «1829» ел күрсәтелгән.



*«1782т» шифрлы кулъязма. 12а кәгазь.*

Сакланышы уртача. Дефектлары: яртысыннан күбрәк өлеше тегелгән җебеннән аерылган. 15б кәгазе таушалган, 17–18 кәгазьләренең читләре ертылган.

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе һәм Казан дәүләт университетының берләштерелгән фәнни-археографик экспедициясе вакытында Пермь өлкәсенең Барда районы Үдик (Елпачиха) авылында Рәүфә Адутовадан 2001 елның июль аенда алынган.

**Бу кульязма турында мәгълүмат басылды:**

1. «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кульязмаларына тасвирламалар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2009. – Б. 58–59. – (Бер бит факсимилесы белән).

2. Мәрданов Р. Гарәп хәрефле татар кульязмаларының палеографик үзенчәлекләре. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2024. – Б. 178. – (Бер бит факсимилесы).

28

2068т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Россиядә XIX гасырның беренче яртысында эшләнгән саргылт төстәге кәгазьдә. Филиграньнәре бар.

Төбе җеп белән тегелгән. Тышлыгы юк.

Күләме: 72 кәгазьдә. Башы һәм ахыры юк. Пагинациясе соңгы чорда гади карандаш белән куелган.

Форматы: 18 х 22 см.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 11,5 х 15 (15,5) см.

Бер битендә 16 шигъри юл.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Тугар күн, тулан ай, унбер йылдыз,*
*Дөшүм эчрә сәҗдә кыйлды бәңа дөб-дөз.*

Текстның ахыры (72б кәгазьдә):

*[Әгәр сән] хакъ рәсүл улур ирсәң,*
*Рисаләт дәгъвасы кыйлур ирсәң.*

Бу кулъязмадагы текст башы 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасының 52 битендәге 24 нче строфага, ә ахыры 426 битендәге 997(6) нчы строфага туры килә.

Текст тәнвиннәр кулланылып язылган. Мәсәлән, 58а кәгазьдә «кардәшләр(ин)», «алдуклар(ин), «салдуклар(ин)» рәвешендә.

Язу карасы – ачык һәм караңгы көрән төсләрдә.

Язу төре – нәстәгъликъ элементлары кушылган нәсех.

Кустодлары бар.

Күчерелгән вакыты – филиграньнәрендә «1831» һәм «1832» еллар күрсәтелгән.

Сакланышы уртача, кәгазьләрдә юешләнүдән калган таплар бар.

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе һәм Казан дәүләт университетының берләштерелгән фәнни-ар-


حضرتلری جمله سنك قلبنك دیدی — سنی ستان سنکا قل اولا ایدی
دارلق کچدی آلتی یل تمام اولدی — انبارده آشلق هیچ قالمادی
یوسف سوزی بو حال اوزره فکر قیلدی — آلله حمد سنداه یوق ایدی
همانذم جبرائیل کلدی حاضر — ویربدی یوسفه ملك قاه ... یر
آیده بر صورتنك قیلغل ظاهر — بنی سن قدرتم کورکل ... ایدی
یوسف ایله شهره خبر قیلدی — ایرته توغ میدانه چقنکه دیدی
بنی بوکن جمالیمه بر باقنك دیدی — آچلقده بقارسه تویار ایدی
اولوکیمی حاصر عام حاضر کلدی — یوسفونك جمالنه نظر قیلدی
بیمك ایچمك قیغوسی جمله قالدی — بقاهرکز جمالنه تویار ایدی
آیده برکز یوسف بنی چقار ایردی — کورکلو یوزنده نقاب سویار ایدی
اولوغ کچك بای یوقسول بقار ایردی — بر آیده کمسه هیچ طعام یماز ایدی

فصل قصه در ایر

بیکه حضرت جبرائیل کلدی حاضر — ویربدی یوسفه ملك قادر یر
یا یوسف جلیل اری ایدور دیر — ایرته حشم برله سیران قیلغل ایدی
حقیقت کما نسر بابقی بیکیل — هرکم ستانشی سه آییب کلکل
کندو اوزنکا آنی سن وار قیلغل — حالق اری بو یله دورت تغل ایدی

٩٠

*«2068т» шифрлы кульязма. 47б кәгазь.*

хеографик экспедициясе вакытында Чуашстан Республикасының Комсомол районы Урмай авылында Илшат Фәтхуллиннан 2006 елның июль аенда алынган.

**Бу кульязма турында мәгълүмат басылды:**

1. Гобәйдуллин Л. Тарихыбыз эзләреннән // Китапханә хәбәрләре = Библиотечный вестник. – 2006. – № 2. – Б. 27–29.

2. «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кульязмаларына тасвирламалар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2009. – Б. 60–61. – (Бер бит факсимилесы белән).

29

778т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Россиядә XIX гасырның беренче яртысында эшләнгән саргылт төстәге кәгазьдә. Филиграньнәре бар.

Күләме: 7 кәгазьдә. Башы һәм ахыры юк. Пагинациясе соңгы чорда гади карандаш белән куелган.

Форматы: 17 x 21,5 см.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 10 (10,5) x 16 см.

Бер битендә 17 шигъри юл.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Йосыф әйде: «Ходавәндә Гафур, Рахман,*
*Котулмага булумадум һәргиз дәрман».*

Текстның ахыры (7б кәгазьдә):

*Үзүңез аңа эш кыйлмыш такәте так,*
*Сәнең йөзүңез күрмәгә йаулак моштак.*

Бу кулъязмадагы текст башы 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасының 168 битендәге 543 нче строфага, ә ахыры 190 битендәге 639 нчы строфага туры килә.

Текст «уау» хәрефләре өстендә өчәр нокта куеп һәм тәнвиннәр кулланып язылган. Мәсәлән, 2б кәгазьдә «танук-лык(ин)» рәвешендә.

Язу карасы – текст ачык көрән, ә фасыл исеме кызыл төсләрдә.

Язу төре – нәстәгъликъ.

Кустодлары бар.

Күчерелгән вакыты – филиграньдә «1833» ел күрсәтелгән.

Сакланышы уртача, кәгазь читләре таушалган.

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе һәм Казан дәүләт университетының берләштерелгән фәнни-археографик экспедициясе вакытында Пенза өлкәсенең Ка-



*«778т» шифрлы кулъязма. 5а кәгазь.*

менка районы Телəтен авылында Рəхимə Раковадан 1996 елның июль аенда алынган.

Бу кулъязма турында мәгълүмат басылды:

1. «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кулъязмаларына тасвирламалар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2009. – Б. 62–63. – (Бер бит факсимилесы белән).

30

411т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Россиядә XIX гасырның беренче яртысында эшләнгән аксыл һәм өлешчә ачык яшькелт төстәге кәгазьләрдә. Филиграньнәре бар.

Төбе калын җеп белән тегелгән. Тышлыгы юк.

Күләме: 32 кәгазьдә. Башы һәм ахыры юк. Пагинациясе соңгы чорда гади карандаш белән куелган.

Форматы: 17 x 21,5 см.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 12 x 16 см.

Бер битендә 15 шигъри юл.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Равиллләрдән бу ривайәт илә имеш,*
*Корга бине Талут аңа дирләр имеш.*

Текстның ахыры (31б кәгазьдә):

*Бикенде кәндү үзенә вазир кылды,*
*Һәмандәм мөэмин-мөхлис улур имди.*

Бу кулъязмадагы текст башы 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасының 124 битендәге 352 нче строфага, ә ахыры 208 битендәге 710 нчы строфага туры килә.

Язу карасы – ачык көрән төстә.

Язу төре – нәстәгъликъ-шикәстә.

Кустодлары бар.

Күчерелгән вакыты – филигранендә «1838» ел күрсәтелгән.

Кулъязманың 25а кәгазендә «Ошбу китаб мин мулла Габделкәрим угылы Шәрәфеддин» һәм 29 б кәгазьдә «Ошбу хат йазгучы мин мулла Шәрәфетдин торур. Габдрахман угылы торур» дигән язулар бар.

Сакланышы уртача. Дефектлары: кулъязма юешләнү кичергән. 1–3 кәгазьләрнең астагы уң як почмаклары те-



*«411т» шифрлы кулъязма. 25а кәгазь.*

телгән (ертык). Битләре пычрак һәм текстка бәйләнешсез язулар белән чуарланган. Ахыргы кәгазе җебеннән аерылган.

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе һәм Казан дәүләт университетының берләштерелгән фәнни-археографик экспедициясе вакытында Пенза өлкәсенең Городище районы Югары Әләзән авылында Дәүләтша Мекаевтан 1993 елның июль аенда алынган.

**Бу кулъязма турында мәгълүмат басылды:**

1. «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кулъязмаларына тасвирламалар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2009. – Б. 68–69. – (Бер бит факсимилесы белән).

2. Татарстан Республикасы Милли китапханәсе: уникаль фондлар һәм тупланмалар. Китап-альбом. – Казан: Татар. китап нәшр., 2015. – (Рус, татар, инглиз телләрендә). – Б. 108. (9б һәм 10а кәгазьләренең фоторәсеме).

31

342т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Россиядә XIX гасырның беренче яртысында эшләнгән саргылт төстәге кәгазьдә.

Күләме: 1 кәгазьдәге фрагмент. Бер бит кәгазьнең дүрттән бер өлеше (өске ягы) зурлыгында.

Тексты (1а кәгазе) 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасының 228 битендәге 776–778 нче строфаларга, 1б кәгазе шул ук биттәге 783–785 нче строфаларга туры килә.

Форматы: 7,5 x 17,5 см.

Язу карасы – көрән төстә.

Язу төре – нәстәгъликъ.

Күчерелгән вакыты – XIX гасырның икенче чиреге.

Сакланышы уртача.

Татарстан Республикасының Апас районы Кече Кайбыч авылында китапханә хезмәткәре Илгиз Галләмов тарафыннан 1992 елда табылган.



*«342т» шифрлы кулъязма. 1а кәгазь.*

**Бу кулъязма турында мәгълүмат басылды:**

1. Мәрданов Р. Ун еллык археографик хезмәт // Китапханә хәбәрләре = Библиотечный вестник. – 2002. – № 1. – Б. 15.

2. Мәрданов Р. Тарих битләрен актарганда... // Казан утлары. – 2002. – № 3. – Б. 126.

3. «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кулъязмаларына тасвирламалар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2009. – Б. 64–65. – (Факсимилесы белән).

589т قصهء یوسف

Авторы – Кол Гали.
«Кыйссаи Йосыф».



*«589т» шифрлы кулъязма. 7а кәгазь.*

Россиядә XIX гасырның беренче яртысында эшләнгән ак төстәге кәгазьдә. Филиграньнәре юк.

Күләме: 8 кәгазьдә. Башы һәм ахыры юк. Пагинациясе соңгы чорда гади карандаш белән куелган.

Форматы: 17,5 х 22,3 см.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 12 х 17 см.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*[Сәлам-]дөруд тигүргел, үгүтләгил,*
*Хатерендән гамь-госсасын йусын имди.*

Текстның ахыры (8б кәгазьдә):

*Һич кемсәнә чыкмаз улды тәдбирендән, –*
*Мәлик Дәгыйр [үзе] дөшүб эшләр имди.*

Бу кулъязмадагы текст башы 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасының 82 битендәге 152 нче строфага, ә ахыры 108 битендәге 277 нче строфага туры килә.

Язу карасы – текст һәм фасыл башлары бер төрле үк – ачык көрән төстә.

Язу төре – нәстәгъликъ.

Кустодлары бар.

Күчерелгән вакыты – XIX гасырның икенче чиреге.

Сакланышы уртачадан түбән. Дефектлары: кәгазьләре таплы, пычрак, читләре тетелгән. 1 нче һәм 8 нче кәгазьләре төбеннән аерылганнар, алар аеруча пычрак һәм таушалган. 7 нче кәгазе дә шактый таушалган. 7а һәм 8б кәгазьләрдә язулары начар күренә.

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе һәм Казан дәүләт университетының берләштерелгән фәнни-археографик экспедициясе вакытында Башкортстанның Тәтешле районы Аксәет авылында Тимергаян Әхмәтовтан 1995 елның июль аенда алынган.

**Бу кулъязма турында мәгълүмат басылды:**

1. «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кулъязмаларына тасвирламалар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2009. – Б. 66–67. – (Бер бит факсимилесы белән).

33

404т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Россиядә XIX гасырның беренче яртысында эшләнгән саргылт төстәге кәгазьдә. Филиграньнәре бар.



*«404т» шифрлы кульязма. 34а кәгазь.*

Төбе җеп белән тегелгән. Тышлыгы юк.

Күләме: 58 кәгазь (кулъязма җыентыкның 1–58 кәгазьләрендә). Башы юк, ахыры бар. Пагинациясе соңгы чорда гади карандаш белән куелган.

Форматы: 17 х 22 см.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 11,5 х 15 см.

Бер битендә 14 (16) шигъри юл.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Дәрмандәләр дәстгире Мәлик-Рахман,*
*Фазле ...*

Текстның ахыры (58б кәгазьдә):

*Аны дәхи ушал йирдә дәфен кыйлды,*
*Зийарәтә бу көн анда варырлар имди.*

Бу кулъязмадагы текст башы 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасының 76 битендәге 122 нче строфага, ә ахыры 290 битендәге 998 нче строфага туры килә.

Бу күчермә тексты әсәрнең басылып чыккан нөсхәләренә шактый якын булса да, басмалардан күчерелмәгән.

Кайбер битләрдәге текстта тәнвиннәр шактый кулланылган (мәсәлән, 27б–28б кәгазьләрдә).

Язу карасы – төп тексты караңгы көрән, фасыл исемнәре кызыл төсләрдә. Шулай ук кайбер фасылларның бәйтләре (мәсәлән, 17а, 58а кәгазьләр) һәм аерым юллары (мәсәлән, 19б кәгазь) кызыл кара белән язылган. Күпчелек битләренең уң як читләрендә гади карандаш белән вертикаль сызыклар сызылган, кайбер битләрдә (мәсәлән, 29а кәгазьдә) примитив һәм схематик рәвештә кеше рәсемнәре ясалган.

Язу төре – нәстәгъликъ.

Кустодлары бар.

Күчерелгән вакыты – 1841 ел.

Күчерелгән урыны – Нижний [Новгород] шәһәре.

Күчерүчесе – Юныс бине Фәхретдин бине Байтимер бине Биктимер.

Колофоны «Кадь вәкага әл-фирагъ мин күтүби һәзиһи ән-нөсхәтиш-шәрифәти әл-мүсәммә Йосыф гамь фи вакъ-

ти дүшәнбә фид-дөха. Кятибәһә вә маликәһә Йуныс бине Фәхретдин бине Байтимер бине Биктимер бине фәлан бине фәлан. Моны йазганда кыш иде, каләмем камыш. Гаепләмәгез сез муллалар, каләмем камыш иде. Шәһре Нижнида 1841 нче йылда».

Сакланышы уртача. Дефектлары: кульязманың элек юешләнгәннән калган таплары бар; 1 нче кәгазенең өчтән бер өлеше ертылган; 1а, 15б, 16а кәгазьләре шактый пычрак; кайбер (мәсәлән, 41, 43, 51–58) кәгазьләре ертылган һәм тишкәләнгән.

Кульязма җыентыкның 60б–72а кәгазьләрендә шул ук күчерүче тарафыннан төрки-татар телендәге дини эчтәлекле шигъри әсәрнең тулы тексты, 73а–83а кәгазьләрендә «Кыйссаи Әхтәм», 83б кәгазьдә Габделҗәббар Кандалыйның «Сахибҗәмал» поэмасының фрагмент-өзеге һәм 84б–144а кәгазьләрдә «Китабе имам Хөсәен» исемендәге төркитатарча хикәятләр язылган.

Казан шәһәрендә шагыйрә Заһидә Бурнашева туганнарыннан китапханә хезмәткәрләре Р.Мәрданов һәм И.Һадиев тарафыннан 1994 елның ноябрь аенда алынган иде.


**Бу кульязма турында мәгълүмат басылды:**

1. Мәрданов Р. «Йосыф китабы»ның көен көйләп... // Китапханә хәбәрләре = Библиотечный вестник. – 1999. – № 1. – Б. 26.
2. Марданов Р. Драгоценные находки // Казань. – 1999. – № 5/6. – С. 82.
3. Мәрданов Р. Тарих битләрен актарганда... // Казан утлары. – 2002. – № 3. – Б. 126.
4. «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кульязмаларына тасвирламалар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2009. – Б. 74–76. – (Бер бит факсимилесы белән).
5. Мәрданов Р. Китапларда милләт язмышлары... – Казан: «Милли китап» нәшр., 2010. – Б. 55.

34

1568т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Россиядә XIX гасырның беренче яртысында эшләнгән ак төстәге кәгазьдә.

Күләме: бер кәгазь битенең чирек өлеше зурлыгындагы фрагмент. Ягъни, тулы биттә икешәр багана итеп язылган текстның бер баганасы тарафы.

Форматы: 8 х 11,5 см.

Бу фрагментның 1а кәгазендәге текст башы 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасының 136 битендәге 412 нче строфага, ахыры 138 битендәге 417(1) нче строфага, ә 1б



*«1568т» шифрлы кульязма. 1а кәгазь.*

кәгазендәге башы 138 биттәге 420 нче строфага, ахыры шул ук биттәге 424 нче строфага туры килә.

Текстның 412–414 нче строфаларга туры килгән өлешендә әсәр текстындагы «Кыйтфир» исеме бу күчермә фрагментында (дүрт мәртәбә) «Канзафәр» дип теркәлгән булуы белән үзенчәлекле. Әсәрнең кайбер башка күчермәләрендә дә шундый язылыш очрый.

Язу карасы – кара төстә.

Язу төре – нәстәгъликъ.

Күчерелгән вакыты – XIX гасырның беренче яртысы.

Сакланышы начар.

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе һәм Казан дәүләт университетының берләштерелгән фәнни-археографик экспедициясе вакытында Пермь өлкәсе Барда авылы (район үзәге) мәчетеннән 2000 елның июль аенда алынган.

**Бу кульъязма турында мәгълүмат басылды:**

1. «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кульъязмаларына тасвирламалар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2009. – Б. 70–71. – (Бер бит факсимилесы белән).

## 35

2744т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Россиядә XIX гасырның беренче яртысында эшләнгән саргылт төстәге кәгазьдә. Филиграньнәре юк.

Төбе ак җеп белән тегелгән, аерым ике дәфтәр-өлештән тора. Тышлыгы юк.

Күләме: 13 кәгазьдә. Башы һәм ахыры юк. Пагинациясе соңгы чорда гади карандаш белән куелган. 1–12 нче кәгазьләрнең өске як почмакларында элекке чорда гарәп саннары белән бит номерлары язылган.

Форматы: 16,5 x 20 см.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 12 (12,5) x 15,5 (16) см.

Бер битендә 16 шигъри юл.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Ошбу дөши бөйлә күрдүм һич гөмансыз,*
*Йа, әбәти, бәңа тәэвил кыйлгыл имди.*

Текстның ахыры (13б кәгазьдә):

*Гайбе берлә сатуб кабул әйләйүрв(ән),*
*Нәчә алурсезләр әйдүң имди.*

Бу кульязмадагы текст башы 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасының 52 битендәге 24 нче строфага, ахыры 96 битендәге 208 нче строфага туры килә. 5 нче һәм 6 нчы кәгазьләр арасындагы бер кәгазе төшкәнлектән, текстка өзеклек кергән.

11а кәгазьдәге «Фасыл хан хәким» дип аталган бүлек исеме 1983 елгы басманың «Фасыл: Мәлик бине Дәгыйр дүш күрдеке» дип аталганына туры килә.

Текстта тәнвиннәр кулланылган.

Язу карасы – көрән һәм ачык көрән төсләрдә. Фасыл исемнәре кызыл кара белән теркәлгән. 12а кәгазьдәге текст тирәли һәм ике багана арасында кызыл кара белән кечкенә түгәрәкләр рәвешендәге бизәкләр ясалган.



*«2744т» шифрлы кулъязма. 12а кәгазь.*

Язу төре – нәстәгъликъ.

Кустодлары бар.

Күчерелгән вакыты – XIX гасырның беренче яртысы.

Сакланышы уртачадан яхшырак. Кәгазьләрнең өске өлешләре бераз дымланып тапланган.

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе һәм Казан дәүләт университетының берләштерелгән фәнни-археографик экспедициясе вакытында Марий Эл Республикасының Морки районындагы Күлбаш авылында Рәфкать Нәҗип улы Шакировтан 2005 елның июль аенда алынган.

## 36

7666т                    قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Россиядә XIX гасырның беренче яртысында эшләнгән саргылт төстәге кәгазьдә. Филиграньнәре юк.

Төбе ак җеп белән тегелгән. Тышлыгы юк.

Күләме: 64 кәгазьдә. Башы һәм ахыры юк. Пагинациясе соңгы чорда гади карандаш белән куелган.

Форматы: 17 x 21,5 см.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 13 (14) x 17 см.

Бер битендә 15(16) шигъри юл.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Мони кылыб Халикъдан рәхмәт улмаз,*
*Йәгрәк улдур, тәүбә кыйлыб дүнгел имди.*

Текстның ахыры (64б кәгазьдә):

*Каил, самигъ бу мөзнибә дога кыйлса,*
*Мөҗиб аны мөстәҗаб кыйла имди.*

Бу кулъязмадагы текст башы 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасының 68 битендәге 98 нче строфага, ахыры 292 битендәге 1002 нче строфага туры килә.

Тексттагы төрки сүзләрдә тәнвиннәр күп кулланылган, кайбер битләрдә алар дистәдән артык (мәсәлән, 25б, 27б кәгазьләрдә).

Язу карасы – ачык һәм караңгы көрән төсләрдә. Фасыл исемнәренең кайберләре кызыл төстәге кара белән язылган. Көрән төстәге кара белән теркәлгән фасыл исемнәре кызыл белән дә кабатланган. Кайбер шигъри юллар (мәсәлән, 21а, 22а, 33а, 49б кәгазьләрдә) кызыл кара белән теркәлгән. 54б кәгазьнең яртысында юллар көрән һәм кызыл каралар белән аралаштырып язылган. Фасыл атамаларының кайберләре кызыл нокталар белән каймаланган (мәсәлән, 39а, 49а кәгазьләрдә). «Фасыл» сүзе астында вак кына



*«7666т» шифрлы кулъязма. 54б кәгазь.*

ярымтүгәрәкләр рәвешендәге чылбырсыман бизәкләр кызыл кара белән ясалып, көрән кара белән читләнгән (мәсәлән, 60б, 61б, 62б кәгазьләрдә).

Язу төре – нәстәгъликъ.

Кустодлары бар.

Күчерелгән вакыты – XIX гасырның беренче яртысы.

Сакланышы уртача. Дефектлары: 1–10, 50 нче кәгазьләр төбеннән аерылган. 1 нче һәм 2 нче кәгазьләрнең түбәнге, төп яклары ертылып төшкән. 1а, 10б, 64б кәгазьләре шактый пычрак.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең фәнни-археографик экспедициясе вакытында Татарстан Республикасының Арча районындагы Мәмсә авылында Сания Гыйльметдиновадан китапханә хезмәткәре А.Заһидуллин тарафыннан 2023 елның 21 июлендә алынган.

37

2067т قصهء یوسف

Авторы – Кол Гали.
«Кыйссаи Йосыф».




*«2067т» шифрлы кулъязма. 1а кәгазь.*

Россиядә XIX гасырның беренче яртысында эшләнгән саргылт төстәге кәгазьдә.

Күләме: 1 кәгазьдәге фрагмент.

Форматы: 17,5 х 22 см.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 14 х 17 (17,5) см.

Бер битендә 20 шигъри юл.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Варгыл, кардәшләреңә билә улгыл,*
*Мәгъбунлыкдан, мәхзунлыкдан айырулгыл.*

Текстның ахыры (1б кәгазьдә):

*Бөйлә каты аглашалар – нә халь дигде? –*
*Тәрҗеман анлардан сорар имди.*

Бу фрагменттагы текст башы 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасының 236 битендәге 814(2) нче строфага, ахыры 242 битендәге 831 нче строфага туры килә.

Язу карасы – ачык көрән төстә.

Язу төре – нәстәгъликъ.

Күчерелгән вакыты – XIX гасырның беренче яртысы.

Сакланышы уртача, кәгазь читләре таушалган һәм таплы.

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе һәм Казан дәүләт университетының берләштерелгән фәнни-археографик экспедициясе вакытында Марий Эл Республикасы Бәрәңге районының Хәсән авылында Саимә Җидиятовадан 2005 елның июль аенда алынган.

**Бу кульязма турында мәгълүмат басылды:**

1. «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кульязмаларына тасвирламалар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2009. – Б. 72–73. – (Бер бит факсимилесы белән).

38

4090т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Россиядә XIX гасырның беренче яртысында эшләнгән саргылт төстәге кәгазьдә. Филиграньнәре юк.



*«4090т» шифрлы кулъязма. 1б кәгазь.*

Күләме: 1 кәгазьдәге фрагмент.

Форматы: 17 x 21,3 см.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 12 x 15,5 см.

Бер битендә 15 шигъри юл.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Колы йаулак миһербан һәм шәфагатьлү,*
*Дүгәл иши ихсан берлә ишләр имди.*

Текстның ахыры (1б кәгазьдә):

*Бәс, андан Йагъкуб укыды ул бетини,*
*Кандалыгын белде, дагы хәсрәтени.*

Бу фрагменттагы текст башы 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасының 270 битендәге 937 нче строфага, ахыры 272 битендәге 952 нче строфага туры килә.

Тексттагы кайбер сүзләрдә хәрәкәләр һәм тәнвиннәр кулланылган.

Язу карасы – ачык көрән төстә.

Язу төре – нәстәгъликъ-шикәстә.

Кустоды бар.

Күчерелгән вакыты – XIX гасырның беренче яртысы.

Сакланышы уртача: кәгазь читләре таушалган, пычранган таплы урыннары бар, язуы бераз уңган.

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе һәм Казан (Идел буе) федераль университетының берләштерелгән фәнни-археографик экспедициясе вакытында Самара өлкәсенең Шонталы районындагы Динис авылы мәчетеннән 2009 елның июль аенда алынган.

39

3344т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Россиядә XIX гасырның беренче яртысында эшләнгән саргылт төстәге кәгазьдә. Филиграньнәре юк.



*«3344т» шифрлы кулъязма. 1а кәгазь.*

Күләме – 1 кәгазьдәге фрагмент.

Форматы: 17 х 20,5 см.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 10,5 х 15 см.

Бер битендә 14 шигъри юл.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Оҗмах ичрә бер зариф тәхет улди,*
*Халикъ аңа ул кирамәт кыйлур имди.*

Текстның ахыры (1б кәгазьдә):

*Гыйльм-ү-хикмәт рузи кыйлмыш аңа Сөбхан, –*
*Бу дөшүң тәэвилени ул белүр имди.*

Бу кулъязмадагы текст башы 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасының 192 битендәге 644(3) нче строфага, ахыры 196 битендәге 656 нчы строфага туры килә.

Текстта тәнвиннәр кулланылган.

Язу карасы – караңгы көрән төстә.

Язу төре – нәстәгъликъ-шикәстә.

Кустоды бар.

Күчерелгән вакыты – XIX гасырның беренче яртысы.

Сакланышы начар: кәгазь бик таушалган-тетелгән һәм пычрак. Төп ягыннан бер өлеше ертылып юкка чыккан, читләре дә ертылып зарарланган.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең фәнни-археографик экспедициясе вакытында Татарстан Республикасының Арча районындагы Колачы авылында Илсөя Мөхәммәтгалиевадан китапханә хезмәткәре А.Заһидуллин тарафыннан 2016 елның август аенда алынган.

40

600т قصهء یوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Россиядә XIX гасыр уртасында эшләнгән ак төстәге кәгазьдә.

Җыентыкның 4б–5б кәгазьләрендәге бу кулъязма битләр басма (Казан, 1852) китапның төшкән 3–4 битләре урынына тулыландырып язылганнар. Пагинациясе соңгы чорда гади карандаш белән куелган.

Форматы: 13,5 х 21,5 см.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 11 х 16,5 (17,5) см.

Текстның башы (4б кәгазьдә):

*Әлхәмде шөкер вә сипас ул Әхәдә,*
*Мөлке даим би-зәваль ул Самәдә.*

Текстның ахыры (5б кәгазьдә):

*Вәләкин әманәтдер җаным угълы,*
*Дустыңны һич кемсәгә сән әйтмәгыйл.*

Бу кулъязмадагы текст башы 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасының 46 битендәге 1 нче строфага, ә ахыры 54 битендәге 30 нчы строфага туры килә.

Язу карасы – ачык көрән, 5б кәгазьдәге фасыл исеме («Йосыф галәйһиссәлам дөше») кызыл төстәге кара белән язылган.

Язу төре – нәстәгъликъ.

Кустодлары бар.

Күчерелгән вакыты – [1856–57 еллар].

Күчерүчесе – Мөхәммәтгали Чокрый.

Сакланышы яхшы диярлек. Җыентыкның җеп белән тегелгән төбе урталай ике өлешкә аерылган. Ахыргы (104 һәм 105 нче) кәгазьләре җебеннән купкан.

Басма китаплар һәм кулъязмалар бергә тупланган бу җыентыкта түбәндәгеләр бар:

1. *Кулъязма.* 2б–3б кәгазьләрдә. Шигырьләр. Мөхәммәтгали Чокрый тарафыннан 1858 елда Әстерханда язылган.

2. *Басма китап.* 4б–48б кәгазьләрдә. [Китабе Кыйссаи хәзрәти Йосыф ән-нәби галәйһиссәлам]. – Казан: Кукубин табыгханәсе, 1852. – 88 б.

Китапның башындагы төшкән 2–4 битләре шагыйрь Гали Чокрый тарафыннан кулдан язып тулыландырылган.

3. *Басма китап.* 49а–71б кәгазьләрдә. Вафаи. Китабе мөстәтаб Раунакыль-ислам. – Казан.

Ахырындагы төшкән бите (бер кәгазь) Гали Чокрый тарафыннан язып тулыландырылган.

4. *Кулъязма.* 72 нче кәгазьдә. «Бөре өязе Ирәкте илендә Чокыр авылында указной мулла Мөхәммәдгали Мөхәммәдсалих угылына» Вәрәшбаш авылыннан Камалетдин Мифтахетдин улы 1869 елның 3 февралендә язган хат.

5. *Кулъязма.* 73б–74 кәгазьләрдә. Шигырьләр һәм хикәятләр.

6. *Кулъязма.* 73а, 75а–79б һәм 104а кәгазьләрдә. Хронология һәм календарь язмалары. «Фи бәйане йыл».

7. *Кулъязма.* 80б–90б кәгазьләрдә. Хәдисләр.

8. *Кулъязма.* 91б–92а кәгазьләрдә. Шигырь. Авторы – Шәмсетдин.

9. *Кулъязма.* 91а кәгазьдә. Газалиның «Касыйдәи бөрдә» әсәре өзеге.

10. *Басма.* 92а–103а кәгазьләрдә. Бакыргани Сөләйман. Хәким ата китабы. – Казан, 1849. – 23 б.

Китап хуҗасының язмасы (3б кәгазьдә): «Тәммә нәкалә һәзиһир-рисаләти фи йәдил-фәкыйрь әл-хәкыйрь Мөхәммәдгали Чокрый тәзкирәтән минһү ли-мән хаһ шәфкати кальби фи сәнәти Хаҗитархан мин-әл-бәхрийәти вә фи сәнә 1858 минһүл-мәсихийәти».

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе һәм Казан дәүләт университетының берләштерелгән фәнни-



آدمیلر کنه سندن کی ساقلانغل بار  آدمیگا شیطان دوشمان اولور ایمدی

دده سی اسحاق سوچی دین طبیبی  خلیل الله ابراهیم بنگا اوغلی ایدی
موندین صنکره حکمت تباکی سر من  کل و ریحان در مرجان ساچه سر من
یوسف نبی نبا احوالی آچه سر من  مؤمنلره نافع دور آنکلا بنگا ایدی
قصه لردان حکمتلردان کور کلور اکی  اوصانمدان دنکلا ملفه داتلوراتی
قرآن ایچره بی شک آتنک مذکورلکی  اوشبو قصه ایردکی ظاهر ایمدی

فصل یوسف علیه السلام دوشی

عزیز یوسف تمام اون بر یشار ایدی  یعقوب سوچی اویلو قنده اویور ایدی
اویورکن بر عجب دوشی یوسف کوردی  تاؤیلنی آتاسندان سورار ایمدی
دعا رکن طولون آی اون بر یولدز  دوشوم ایچره سجده قلدی بنگا دبدز
اوشبو دوشی بیله کوردم هیچ کمانسز  یا ابتی بنگا تاؤیل آیغل ایمدی
انده یعقوب یوسفنگ دوشین یوردی  تاؤیلنی مبارک ایتور ایردی
امید درکم مولیدان مدد ایردی  سنگا عزت و رفعت کورنور ایمدی
امید درکم مولی سنگا ویره مملکت  فضلی برله روزی قیله اوکوشی نعمت
قرداشلرنگ جمله سی قیله خدمت  اون برسی سنگا خدمت قیله ایمدی
عالم ایچره سننک آدنک مشهور اوله  مشرق مغرب اولولری سنی بیله
قیامتقه دیکن آدنک باقی قاله  خلیل ذبیح دولتی کورنور ایمدی
نبوت رسالت بولداچی سن  هم مملکت ایاسی اولداچی سن
راحتلغه بشارت بولداچی سن  بو دوشی ایچره عظیم دولت کورنور ایمدی
ایا اوغلم اینانغل بایق بنگا  بو دوشی ایچره سلطنت کورنور سنگا
حمد و ثنا تلیم ایغل سبحانگا  سبحان سنگا تلیم احسان قیلور ایمدی
ولکن امانتدر جانم اوغلی  بو دوشنگنی هیچ کمسه گا سن ایتماغل

آدمیلر نسخه

*«600т» шифрлы кульъязма. 5б кәгазь.*

археографик экспедициясе вакытында Башкортстанның Тәтешле районы Иске Күрдем авылында Заһид Галишановтан 1995 елның июль аенда алынган.

**Бу кулъязма турында мәгълүмат басылды:**


1. Мәрданов Р. «Йосыф китабы»ның көен көйләп... // Китапханә хәбәрләре = Библиотечный вестник. – 1999. – № 1. – Б. 26.

2. Марданов Р. Драгоценные находки // Казань. – 1999. – № 5/6. – С. 82.

3. Каталог выставки «Литературное наследие татарского народа». Из фондов Российской национальной библиотеки (г.Санкт-Петербург) и Национальной библиотеки Республики Татарстан (г.Казань). г.Казань, 30. 08 – 30. 09. 2001 г. – С. 15.

4. Мәрданов Р. Тарих битләрен актарганда... // Казан утлары. – 2002. – № 3. – Б. 126.

5. Марданов Р. Сбережения // Татарский мир = Татар дөньясы. – 2005. – Январь (№23–24).

6. «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кулъязмаларына тасвирламалар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2009. – Б. 77–79. – (Бер бит факсимилесы белән).

7. Мәрданов Р. Китапларда милләт язмышлары... – Казан: «Милли китап» нәшр., 2010. – Б. 55.

373т قصهء یوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Юл-юл сызыклы мәктәп дәфтәре битләрендә.

Күләме: 5 кәгазьдә. Башы һәм ахыры юк. Пагинациясе соңгы чорда гади карандаш белән куелган.



*«373т» шифрлы кулъязма. 5а кәгазь.*

Форматы: 17 х 20,3 см.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 16 х 19,5 см.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Монлар әйдер: «Бу эше без кылмайавыз,*
*Кулымыза кәлә-комаш алмайурыз».*

Текстның ахыры (5б кәгазьдә):

*Калдырыб халыкка дога кыйлды,*
*Фазлең берлә миңа пәрдә виргел имди.*

Бу кулъязмадагы текст башы 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасының 96 битендәге 211 нче строфага, ә ахыры 116 битендәге 316 нчы строфага туры килә.

Текстта совет чорындагы имля үзенчәлекләре бар. Мәсәлән, яңача шәкелдәге «ө» һәм сүз уртасындагы «ы, э» хәрефләре.

Язу карасы – шәмәхә һәм ахырында (5б кәгазьдә) яшел төстә.

Һәр биттәге шигъри ике багананы аерып тора торган вертикаль рәвештәге параллель икешәр сызык сызылган.

Язу төре – нәсех.

Күчерелгән вакыты – 1950 нче еллар.

Сакланышы уртача.

Татарстан Республикасының Ютазы районы Бәйрәкә авылында Әнвәр Яхиннан китапханә хезмәткәре Р.Мәрданов тарафыннан 1991 елның июнь аенда алынган иде.

**Бу кулъязма турында мәгълүмат басылды:**

1. Мәрданов Р. «Йосыф китабы»ның көен көйләп... // Китапханә хәбәрләре = Библиотечный вестник. – 1999. – № 1. – Б. 26.

2. Марданов Р. Драгоценные находки // Казань. – 1999. – № 5/6. – С. 82.

3. Мәрданов Р. Ун еллык археографик хезмәт // Китапханә хәбәрләре = Библиотечный вестник. – 2002. – № 1. – Б. 15.

4. Мәрданов Р. Тарих битләрен актарганда... // Казан утлары. – 2002. – № 3. – Б. 126.

5. «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кулъязмаларына тасвирламалар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2009. – Б. 80–81. – (Бер бит факсимилесы белән).

42

1791т قصهء یوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Совет чорындагы ак төстәге кәгазьдә.

Күләме: 4 кәгазьдә. Кәгазьнең бер ягына бер багана рәвешендә язылган. Башы юк. Кәгазьләр тегелмәгән. Һәр


کافرلارکا هرکیز قونکشی اولمیامن
کافرلاردن آیرو تورماق کرک ایمدی
یوسف نبی موءمنلری جمله دیردی
بر خوش یره نهر العیون اسم ویردی
مصردن نقل ایدب آنده واردی
بر شهرستان آنده بنا قیلور ایمدی
عزیز یوسف آنده تلیم بولدی دولت
اول شهرده فراوان اولدی نعمت
آنده هرکز اولمادی کفر و بدعت
اول شهرننک آتین امین دیرلار ایمدی
ریان ایشدب اول شهری عجبلدی
آننک اچنه کرمکا آرزولادی
دستور ویرسنک بو شهره کرسم دیدی
یوسف ایدر مونده کافر کرمز ایمدی
ریان انی ایشدب موءمن اولدی
ولکن قادر تقدیر ایله قیلدی
اول شهره کرمدن اونك ریان اولدی
بعضیلر بیله نقل قیلور ایمدی

*«1791т» шифрлы кулъязма. 1а кәгазь.*

битенә карандаш белән бит саннары (96–99) куелган.

Форматы: 18 х 20,5 см.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 11,5 (13) х 17,5 (19) см.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Кяферләргә һәргиз куңшы улмайамән,*
*Кяферләрдән айру турмак кәрәк имди.*

Текстның ахыры (4а кәгазьдә):

*Аны дәхи ушал йирдә дәфен кыйлды,*
*Зийарәтә бу көн анда варырлар имди.*

Бу кулъязмадагы текст башы 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасының 284 битендәге 980 нче строфага, ә ахыры 290 битендәге 998 нче строфага туры килә.

Язу карасы – кара төстәге тушь.

Язу төре – нәсех.

Күчерелгән вакыты – 1960 нчы еллар.

Күчерелгән урыны – [Казан].

Күчерүчесе – [Альберт Фәтхи].

Сакланышы яхшы.

Археограф галим Альберт Фәтхи туганнарыннан Казан шәһәрендә 1992 елда алынды.

Бу китапның кереш мәкаләсендә шушы күчермә турында өстәмә мәгълүмат язылды һәм студентларны укытканда куллану өчен күчерелгәнлеге әйтелде.

А.Фәтхи кулы белән язылган бу текстның башы – 1–23 нче кәгазьләре Казан федераль (Идел буе) университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсе сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегендә «7734т» шифры белән саклана. Анысы да нәкъ шундый ук форматтагы (18х20,5 см) кәгазьгә кара тушь белән эре итеп язылган. 1а кәгазендә әсәрнең 1873 елгы Казан басмасыннан күчерелгәнлеге язып куелган.

**Бу кулъязма турында мәгълүмат басылды:**

1. «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кулъязмаларына тасвирламалар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2009. – Б. 82–83. – (Бер бит факсимилесы белән).

43

7177т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

1960–1970 нче елларда эшләнгән юл-юл сызыклы мәктәп дәфтәрләрен (уникешәр кәгазьле ун дәфтәрне) кушып, ак һәм кара җепләр белән тегелгән җыентыкта. 1–32 нче, 33–107 нче кәгазьләре ике аерым өлеш итеп тегелгән. Дермантин һәм калын кәгазьдән эшләнгән гомуми дәфтәр тышлыгы эчендә.

Күләме: 110 кәгазьдә (җыентыкның 1–110 нчы кәгазьләре). Башы һәм ахыры юк. Пагинациясе соңгы чорда гади карандаш белән куелган.

Форматы: 17 х 20,3 см.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 14 х 18,5 см.

Бер битендә 12 (16) шигъри юл.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Йалан төш илә бездин сәвеклү улдың,*
*Бүген аның җәзасын белгел имди.*

Текстның ахыры (110б кәгазьдә):

*Ул сиддыйкның табутыны хазир кыйлды,*
*Бер хуш җиргә аны мәдфүн кыйлыр имди.*

Бу кульязмадагы текст башы 1983 елгы «Кыйссаи Йосыф» басмасының 64 битендәге 78 нче строфага, ахыры 288 битендәге 990 нчы строфага туры килә.

Текст зәңгәр төстәге шарикле авторучка белән язылган.

Язу төре – нәсех.

Кустодлары юк.

Күчерелгән вакыты – 1970 нче еллар.

Сакланышы уртача. Дефектлары: 1а кәгазе пычрак. 1–6 нчы кәгазьләренең түбәнге почмаклары дымланудан тапланган һәм бөгәрләнгән. 108–109 кәгазьләре төбеннән аерылганнар һәм таушалганнар



*«7177т» шифрлы кульъязма. 20а кәгазь.*

Җыентыкның 111–119 нчы кәгазьләрендә шул ук хатын-кыз тарафыннан башка текстлар һәм мәгълүматлар язылган. 111а–117б кәгазьләрдә С.Бакырганиның «Ахыр заман» әсәре, 118а кәгазьдә «Кәлимәтед-тәүхид» догасы, 119а кәгазьдә дүртьюллык кыска җыр, Казан шәһәренең Агроном урамында яшәгән Ахунова Рәхимәнең адресы теркәлгән.

118б кәгазьдә (дәфтәрнең ахыргы битендә) кыскача хат тексты: «Сафура! Сәлам сиңа, икегезгә дә. Менә сиңа

«Тәкый гаҗәб»* китабы. Мин үлсәм, Коръән укырсың, язуымны күргәч искә төшерерсең. Алгач хат сал. Хатыңны алдым».

Татарстан Республикасының Буа шәһәрендәге «Госман» («Сахарный завод») мәчетеннән китапханәнең кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге хезмәткәре Ильяс Мөстәкыймов тарафыннан 1995 елның 7 декабрендә алынган.

---

* «Тәкый гаҗәб» – С.Бакырганига нисбәт ителгән «Ахыр заман» китабының халык телендәге атамасы.

# ИСЕМНӘР КҮРСӘТКЕЧЕ


Абдрашев Юма – № 24
Адутова Рәүфә – № 27
Акчурина Мөнирә – № 25
Арсланова Лотфия – № 18
Ахунова Рәхимә – № 43

Әхмәд – № 26
Әхмәтҗанов Марсель Ибраһим улы – № 26
Әхмәтов Тимергаян – № 32

Бакыргани Сөләйман – № 40, 43
Бибифатыйма Габделҗәббар кызы – № 16
Биктимерова Нурдидә – № 5
Бурнашева Заһидә – № 33

Вафаи – № 40

Габделвахид Габделкәрим угылы – № 14
Габделгалләм – № 10
Габделҗәббар Габделмәннаф угылы – № 16
Габделмәҗит хәзрәт – № 21
Габдеррафигъ Габделвахид угылы – № 14
Габдеррәшитов Усман – № 23
Габдрахманова Зарифа – № 16
Габдрахманов Гарифҗан – № 7
Габдулла бине мулла Батыркәй – № 24
Габдулла ибне Дауд ибне Ишмөхәммәд ибне Динмөхәммәд ибне Бикмөхәммәд ибне Кодаш – № 15
Газали – № 40
Галишанов Заһид – № 40

Галләмов Илгиз – № 31
Гобәйдуллин Ленар – № 1
Гыйльметдинова Сания – № 36

Зарипов Нургали – № 13
Заһидуллин Айрат – №№ 4, 6, 9, 10, 13, 36, 39

Ильяс – № 14
Исмәгыйль – № 6
Исхак – № 6

Камалетдин Мифтахетдин улы – № 40
Камал улы Әхмәд – № 1
Кандалый Габделҗәббар – № 33
Килдиев Марат Вил улы – № 26
Кол Гали – №№ 1–43
Котлы... – № 8
Күчем хан – № 24

Мәрданов Раиф – №№ 2, 3, 11, 14–16, 18, 20, 22, 33, 41
Мекаев Дәүләтша – № 30
Миңнезакир Кәмаледдинев угылы – № 15
Мостафа – № 6
Мостафа мулла – № 24
Мөстәкыймов Ильяс – № 6, 43
Мөхәммәдшакир – № 6
Мөхәммәтгалиева Илсөя – № 39
Мөхәррәм – № 14

Нәбиуллина Гөлбикә – № 10

Ракова Рәхимә – № 29

Садри Мөхәммәт – № 24
Сафиулла – № 26
Сафура – № 43
Сәгыйд бине мулла – № 1

Сәедкол – № 8
Сәйфуллин Нәбиулла – № 5

Таҗетдин – № 14

Фәйзулла – № 6
Фәтхи Альберт – № 42
Фәтхуллин Илшат – № 28

Хафизова Фәридә – № 7

Һидиятова Саимә – № 37
Һадиев Ирек – №№ 2, 3, 11, 22, 33

Чокрый Мөхәмммәтгали мулла Мөхәммәдсалих угылы – № 40

Шакиров Рәфкать Нәҗип улы – № 35
Шәмсетдин – № 40
Шәрәфетдин мулла Габделкәрим угылы – № 30
Шәрәфетдин мулла Габдрахман угылы – № 30
Шәрәфиева Фәйрүзә – №№ 4, 9
Шәрифулла – № 10

Юныс – № 14
Юныс бине Фәхретдин бине Байтимер бине Биктимер – № 33

Яковлев С. – № 1
Яхин Әнвәр – № 41

# ГЕОГРАФИК АТАМАЛАР КҮРСӘТКЕЧЕ


Аксәет авылы – № 32
Апас районы – № 31
Арча районы – №№ 4, 7, 9, 13, 36, 39

Әгерҗе районы – № 18
Әстерхан – № 40
Әтнә районы – № 1

Барда авылы – №№ 19, 34
Барда районы – 19, 27, 34
Башкортстан – №№ 5, 32, 40
Бәйрәкә авылы – № 41
Бәрәңге районы – № 37
Биги авылы – № 25
Бөре өязе – № 40
Буа шәһәре – № 43

Вәрәшбаш авылы – № 40

Городище районы – № 30

Динис авылы – № 15, 38

Ирәкте иле – № 40
Иске Күрдем авылы – № 40

Казан – №№ 2, 3, 6, 8, 11, 12, 17, 20, 22, 24, 26, 33, 42
Каменка районы – №№ 29
Каравай бистәсе – № 6
Кече Кайбыч авылы – № 31

Кип-Куллар авылы – № 24
Колачы авылы – № 39
Комсомол районы – № 28
Кузнецк районы – № 23
Күлбаш авылы – № 35

Марий Эл Республикасы – № 35, 37
Мәмсә авылы – № 36
Морки районы – № 35

Неверкино районы – № 25
Нижний Новгород – № 33
Носы авылы – № 7

Олуг Кавал авылы – № 8
Омск өлкәсе – № 24

Пенза өлкәсе – №№ 23, 25, 29, 30
Пермь өлкәсе – №№ 19, 27, 34

Самара өлкәсе – № 15, 38
Сәйран авылы – № 5

Татар Кынадысы авылы – № 23
Татарстан Республикасы – №№ 1, 4, 7, 9, 10, 13, 18, 31, 36, 39, 41, 43
Ташчишмә авылы – № 1
Тәвриз районы – № 24
Тәтешле районы – №№ 32, 40
Телətен авылы – № 29
Теләче районы – № 10
Тобольск – № 21

Урмай авылы – № 28
Урта Мишә авылы – № 10
Уфа – №№ 5, 14, 16

Үдик (Елпачиха) авылы – № 27

Хаҗитархан – № 40
Хәсән авылы – № 37

Чишмә районы – № 5
Чокыр авылы – № 40
Чуашстан Республикасы – № 28

Шонталы районы – № 15, 38

Югары Әләзән авылы – № 30
Югары Пошалым авылы – № 13

Ютазы районы – № 41

Яңа Аккуҗа авылы – № 18
Яңа Кишет авылы – №№ 4, 9
Ярославль – № 1

# КУЛЪЯЗМАЛАРНЫҢ КҮЧЕРЕЛГӘН ВАКЫТЛАРЫ

| *күчерелгән вакыты* | *бу китапта-гы тасвир номеры* | *китапханәдәге саклану шифры* |
|---|---|---|
| XVII гасыр уртасы | 1<br>2<br>3 | 3410т<br>590т<br>591т |
| XVIII гасыр башы | 4 | 1401т |
| 1756 елдан соң | 5 | 1228т |
| XVIII гасырның өченче чиреге | 6 | 3963т |
| 1789 елдан соң | 7 | 7647т |
| 1795–1799 еллар арасы | 8 | 2078т |
| XVIII гасыр ахыры | 9 | 1402т |
| 1801 елдан соң | 10 | 1763т |
| 1804 елдан соң | 11 | 1121т |
| 1810 елдан соң | 12 | 2069т |
| 1809 елдан соң | 13 | 3364т |
| 1814 елдан соң | 14 | 1400т |
| 1815 елдан соң | 15<br>16 | 1859т<br>1774т |
| 1821 елдан соң | 17 | 2070т |

| | | |
|---|---|---|
| XIX гасыр башы | 18<br>19<br>20<br>21 | 343т<br>1667т<br>1267т<br>1668т |
| XIX гасырның беренче чиреге | 22<br>23 | 1030т<br>777т |
| 1825 елдан соң | 24 | 497т |
| 1826 елдан соң | 25 | 779т |
| 1827 елдан соң | 26 | 486т |
| 1829 елдан соң | 27 | 1782т |
| 1832 елдан соң | 28 | 2068т |
| 1833 елдан соң | 29 | 778т |
| XIX гасырның икенче чиреге | 30<br>31<br>32 | 411т<br>342т<br>589т |
| 1841 ел | 33 | 404т |
| XIX гасырның беренче яртысы | 34<br>35<br>36<br>37<br>38<br>39 | 1568т<br>2744т<br>7666т<br>2067т<br>4090т<br>3344т |
| 1856–1857 еллар | 40 | 600т |
| 1950 нче еллар | 41 | 373т |
| 1960 нчы еллар | 42 | 1791т |
| 1970 нче еллар | 43 | 7177т |

# КУЛЪЯЗМАЛАРНЫҢ КИТАПХАНӘГӘ АЛЫНГАН ВАКЫТЛАРЫ

| *алынган датасы* | *бу китаптагы тасвир номеры* | *китапханәдәге саклану шифры* |
|---|---|---|
| 1990 ел | 18 | 343т |
| 1991 ел, июнь | 41 | 373т |
| 1992 ел | 31<br>42 | 342т<br>1791т |
| 1993 ел, май | 2<br>3 | 590т<br>591т |
| 1993 ел, июль | 30 | 411т |
| 1994 ел, ноябрь | 33 | 404т |
| 1995 ел, февраль | 26 | 486т |
| 1995 ел, 5 май | 24 | 497т |
| 1995 ел, июль | 32<br>40 | 589т<br>600т |
| 1995 ел, 7 декабрь | 43 | 7177т |
| 1996 ел, 26 март | 11<br>22 | 1121т<br>1030т |
| 1996 ел, июль | 23<br>25<br>29 | 777т<br>779т<br>778т |
| 1996 ел, август | 4<br>9<br>10 | 1401т<br>1402т<br>1763т |
| 1996 ел, 11 декабрь | 5 | 1228т |

| | | |
|---|---|---|
| 1997 ел, 14 август | 15 | 1859т |
| 1998 ел, март | 14<br>16 | 1400т<br>1774т |
| 2000 ел, июль | 19<br>34 | 1667т<br>1568т |
| 2001 ел, июль | 27 | 1782т |
| 2002 ел | 20<br>21 | 1267т<br>1668т |
| 2005 ел, июль | 37<br>35 | 2067т<br>2744т |
| 2006 ел, июль | 28 | 2068т |
| 2006 ел, апрель | 6 | 3963т |
| 2008 ел | 8<br>12<br>17 | 2078т<br>2069т<br>2070т |
| 2009 ел, июль | 38 | 4090т |
| 2010 ел, июль | 1 | 3410т |
| 2016 ел, август | 13<br>39 | 3364т<br>3344т |
| 2023 ел, 19 июль | 7 | 7647т |
| 2023 ел, 21 июль | 36 | 7666т |
| **БАРЛЫГЫ** | **43 кулъязма берәмлек** | |

# «КЫЙССАИ ЙОСЫФ» ӘСӘРЕНЕҢ XVII ГАСЫР КҮЧЕРМӘСЕ (ПАЛЕОГРАФИК ҺӘМ ТЕКСТОЛОГИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘР)

XIII гасырда иҗат ителгән бу мәшһүр поэманың хәзерге чорга килеп ирешкән иң элекке кулъязма күчермәләре XVII гасырга карый, алардан элеккерәкләре юк. Болары да санаулы гына һәм аерым кисәк-өлешләрдән гыйбарәт. Татар кулъязма истәлекләренең (шул исәптән «Кыйссаи Йосыф» күчермәләренең дә) төрле сәбәпләр аркасында элекке күчермәләре сакланмаган булуы турында галимнәр дә күп язды, без дә искәрткән идек[1].

«Кыйссаи Йосыф» кулъязмаларының XX гасыр башында галимнәр карамагында булган иң әүвәлгесе – дин һәм җәмәгать эшлеклесе, педагог, нашир һәм мөхәррир Галимҗан Мөхәммәтҗан улы Баруди (Галиев, 1857–1921) исеме белән бәйле. Аның бай китапханәсендә XVI гасырга (һиҗри IX гасырга) караган «Кыйссаи Йосыф» күчермәсе булганлыгы, ләкин 1920 нче еллар башында юкка чыкканлыгы турында хәбәрләр бар[2].

Галим Җәвад Алмаз поэманың 1960 нчы елга билгеле булган 33 күчермәсенең икесен XVII гасырга нисбәт итәргә

---

[1] Мәрданов Р. Гарәп хәрефле татар кулъязмаларының палеографик үзенчәлекләре. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2024. – Б. 31–32.

[2] Фәтхи А. Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханә кулъязмаларының тасвирламасы. X чыг.: Татар әдипләре һәм галимнәренең кулъязмалары. Икенче бүлек. – Казан, 1962. – Б.11; Кол Гали. Кыйссаи Йосыф (Йосыф турында кыйсса) = Кул Гали. Кысса-и Йусуф (Сказание о Йусуфе) / төп текстны (транскрипцияне) әзерләүче, кереш мәкаләне, искәрмә һәм аңлатмаларны, кулъязмаларның тасвирламасын язучы Ф.С.Фәсиев. – Казан: Татар. китап нәшр., 1983. – Б. 432.

мөмкин дип язган булган[3]. Тик, тәфсиллерәк тикшергәч, аларның берсе, чынлыкта, XIX гасырның беренче чирегенә, икенчесе (Дрезден нөсхәсе) XVIII гасыр ахырына караганлыклары ачыкланган[4]. Шуның белән бергә, 1980 нче еллар башында Дрезден нөсхәсе турында «хәзергә билгеле кульязмаларның иң борынгысы, аның XVII йөз ахыры – XVIII йөз башына каравын шикләнми әйтергә мөмкин»[5] дигән фикернең дә дөреслеккә туры килмәгәнлеге беленде. Кулъязма истәлекләрнең вакытын билгеләү, әлбәттә, төрле факторларга бәйле, аеруча катлаулы мәсьәләләрнең берсе. Шул сәбәпле, галимнәрнең ялгышулары табигый. Иң мөһиме – андый ялгышларның төзәтелеп баруы.

Вәләкин, төзәтелгән ялгышларга тиешле игътибар бирeп җиткерелмәве кайчакта эшне боза. Мәсәлән, Дрезденда саклана торган күчермәнең вакыты төгәлрәк итеп кырык еллап элек үк ачыкланган булуына карамастан, татар әдәбияты тарихының соңгы басмасында «Әсәр кулъязмаларының борынгыларыннан дип хәзергә Дрезден нөсхәсен саныйлар... Күчермә XVI–XVII йөзләргә карый»[6] дигән ялгыш мәгълүмат урын алган. Шунда ук телгә алынган Берлин кулъязмасы да XVIII гасыр ахыры – XIX гасыр башына нисбәтле. Фән өчен искергән әлеге җөмләләр 2021 елда дөнья күргән әдәбият тарихы томына «Татар әдәбияты тарихы» хезмәтенең 1984 елгы беренче томыннан алынган. Әдәбият галиме Шакир Абиловның ул китаптагы мәкаләсендә «Әсәр кулъязмаларының борынгыларыннан дип хәзергә Дрезден нөсхәсен санарга кирәк... Күчермә

[3] Алмаз Җ. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» дастаны // Совет әдәбияты. – 1960. – №2. – Б. 102.

[4] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф (Йосыф турында кыйсса) = Кул Гали. Кысса-и Йусуф (Сказание о Йусуфе)..., 1983. – Б. 443, 489.

[5] Хисамов Н. Бөек язмышлы әсәр. – Казан: Татар. китап нәшр., 1984. – Б. 16.

[6] Татар әдәбияты тарихы: Сигез томда. 1 т.: Борынгы чор һәм Урта гасырлар / төз. Г.Дәүләтшин. Үзгәрт. 2 нче басма. – Казан: Татар. китап нәшр., 2021. – Б. 183. Китапта «Дрезден нөсхәсе» сүзләренә карата бирелгән астөшермәсе дә дөрес түгел. Ул сылтама Баку кулъязмасына карарга тиешле.

XVI–XVII йөзләргә карый»[7] дип язылганын күрәбез. Кызганыч ки, мондый төрдәге мәгълүматларның күп еллар үткәч кабатланулары фәндә буталчыклар гына тудыра. «Татар әдәбияты тарихы»ның соңгы басмасын хәзерләгәндә төп белешмәгә – «Татар энциклопедиясе»нә мөрәҗәгать ителгән булса, андый ялгышлык китмәс тә иде. Чөнки анда «Кыйссаи Йосыф» турында язылган мәкаләнең эчендә урнаштырылган фоторәсем астында «Дрезден күчермәсе кулъязмасының башлангыч бите. 18 йөз ахыры» дип, ачык итеп язылган[8].

«Кыйссаи Йосыф» әсәренең хәзергә билгеле булган иң элекке тулы текстлы күчермәләре XVIII гасырга карый. Ә XVII гасырдан аз санлы битләрдән торган фрагментлары гына килеп ирешкән. Димәк, «Кыйссаи Йосыф» авторы тарафыннан иҗат ителгәч дүрт гасырдан артык вакыт узганнан соңгы кулъязмалары сакланган булып чыга. Ә тулы текстлы күчермәләре биш гасырдан да артыграк вакыт кичкәннән соңгы заманга карый. Әсәр тексты якынча чирек гасырга бер мәртәбә күчерелгән дип санасак, хәзерге фән дөньясына «Кыйссаи Йосыф» поэмасының 17 нче буындагы, тулы текстлыларының исә 22 нче буындагы күчермәләре килеп ирешкән дип әйтергә мөмкин. Әдәбиятыбыз тарихы өчен бу, һичшиксез, уникаль күренеш. Галимнәр билгеләгәнчә, Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре, валлаһи, «үлемсез» һәм «бөек язмышлы әсәр».

Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «Кыйссаи Йосыф» әсәренең «3410т» шифры белән саклана

---

[7] Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. Т.: Урта гасырлар дәвере. – Казан: Татар. китап нәшр., 1984. – Б. 121. 1984 елда чыккан бу хезмәттә Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәренә багышланган мәкалә дүрт бүлекчәдән тора. Шулардан 1–3 нче саннар белән билгеләнгән бүлекчәләр авторы Ш.Абилов, ә дүртенчесенеке – Н.Хисамов булганлыгы китапның эчтәлегендә (566 биттә) төгәл күрсәтелгән. Ә 2021 елгы әдәбият тарихы китабында шул ук мәкалә Н.Хисамов авторлыгында тәкъдим ителгән һәм аның 183–189 нчы битләрендә 1984 елгы басманың 120–127 нче битләрендәге 2 һәм 3 нче бүлекчәләре күчереп басылган.

[8] Татар энциклопедиясе. Т. 3: К–Л. – Казан: Татар энцикл. ин-ты, 2012. – Б. 619.

торган кулъязмасы – бу поэманың иң иске, палеографик яктан әһәмиятле күчермәләреннән берсе. Без аны XVII гасыр уртасына нисбәтле дип билгеләдек. Ул нибарысы 8 кәгазьдән генә торса да, аны тәфсилләбрәк тикшерү бу әсәрнең башка күчермәләрендәге кайбер текстологик табышмакларны төшенергә һәм четерекле мәсьәләләрне аңларга мөмкинлек бирә.

Йөзләрчә күчермәләре сакланган әсәрнең һәр кулъязмасы, әлбәттә, үзенчәлекле. «Кыйссаи Йосыф» әсәренең текстын өйрәнгән галимнәр язганча, күп гасырлар дәвамында өзлексез күчереп, күп нөсхәләре булган әсәрләрдә өстәмәләр һәм үзгәртүләр шактый була. Монда сүз барачак мәсьәләләр азмы-күпме дәрәҗәдә бүтән күчермәләрдә дә чагылыш тапкан. Ләкин нәкъ менә монысында – авторның төп текстына чагыштырмача якынрак заманныкы булган күчермәдә – махсус тикшерү өчен мөһимрәк урыннары бар. «Кыйссаи Йосыф»ның XVIII гасыр ахыры яки XIX гасыр башындагы күпсанлы күчермәләренә караганда, бусы әүвәлгерәк булуы ягыннан кызыклы. Анда элгәреге төрки-татар кулъязмаларына (һәрхәлдә, Казан ханлыгы чорына) хас палеографик хасиятләр сакланганлыгы, текст үзенчәлекләре дә күбрәк булуы аңлашыла. Казан ханлыгы чоры палеографиясе дигәндә, беренче нәүбәттә, «Сираҗел-колүб» әсәренең 1554 елдагы күчермәсен күздә тотабыз[9]. «Сираҗел-колүб» текстындагы гарәп хәрефләре элементларының язылышы (икешәр ноктаның почмаксыман шәкелдә язылуы, сүз ахырындагы «йа» хәрефләре астында икешәр нокта, «син» хәрефләре астында һәм «уау» өстендә өчәр нокта куелган булуы), хәрәкәләр кулланылганлыгы кебек специфик охшашлыкларга, гомумән, текстның күбрәк нәсехкә охшаш нәстәгъликъ төрендә язылган булуына әһәмият бирәбез. «Сираҗел-колүб»нең 1554 елга караган күчермәсе турында татар палеографиясенә багышланган хезмәтебездә язган

[9] Россия дәүләт борынгы актлар архивы (Мәскәү). – 181 фонд, 16 тасв., 1468 саклану берәмлеге.

идек[10]. Шунда ук (168 биттә) бу истәлекнең бер битенең факсимилесы да бирелде.

«Кыйссаи Йосыф»ның XVII гасырга нисбәтле, Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә «590т» һәм «591т» шифрлары белән саклана торган күчермәләренең берәр кәгазьдән генә торган ике фрагментында, шулай ук Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасының XVII гасыр уртасына нисбәтле күчермәсе фрагментында[11] да (Татарстан Республикасы Милли музеенда «ГОМРТ 18369-211» шифры белән саклана) охшаш палеографик үзенчәлекләр бар. Әлеге кулъязмаларның һәм 1554 елгы «Сираҗелколүб» күчермәсенең уртак палеографик хасиятләре Казан ханлыгы чорында Идел буендагы татарларда киң кулланылган язу рәвешен чагылдыра дип нәтиҗә ясасак, хакыйкатькә каршы килмәстер. Ягъни, Казан ханлыгы вакытында гамәлдә булган татар палеографиясе бер гасыр чамасы үзгәрешсез диярлек дәвам иткән. Аннан соңгырак чорда – XVII гасырның икенче яртысында, татар шәкертләренең Дагыстанда һәм Урта Азиядә белем алулары белән бәйле рәвештә, татар кулъязмалары кайбер үзгәрешләр кичергән.

Бу китапның кереш мәкаләсендә иске татар кулъязмаларында хәрәкәләр һәм тәнвиннәр кулланылган булуы турында язып үттек. XVII гасыр уртасы күчермәләренең тагын берсендә – «Кыйссаи Йосыф»ның Милли китапханәдә саклана торган «3410т» шифрлы күчермәсендә дә шактый сүзләр хәрәкәләр куелып, аерым сүзләрнең *–ән, –ан, –ун, –үн, –ин* дип тәмамланган өлешләре һәм кушымчалары тәнвиннәр белән язылган. Гарәп телендә кулланылган хәрәкәләр (шул исәптән, «сәкен» билгесе) дә бу текстта бар. Бу күчермәдә «сәкен» хәрәкәсе еш кына сүз ахырларын-

[10] Мәрданов Р. Гарәп хәрефле татар кулъязмаларының палеографик үзенчәлекләре..., 2024. – Б. 165–168.

[11] Мөхәммәдьярның «Нуры содур» әсәре / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2025. – Б. 49.

да да куелган һәм ул кайбер очракларда юлдагы хәрефләр белән бертигез итеп, гүяки, «ә» хәрефе кебек язылган[12].

Сүз бара торган кульязмадагы текст, нигездә, хаталарсыз теркәлгән. Кульязмаларга хас булганча, анда кайбер хәрефләр, иҗекләр һәм сүзләр төшереп калдырылган, «җ» урынына «ч» хәрефе яки киресенчә язылган һ.б. шундый күренешләр бар. Әйтелгәннәрдән тыш, бу нөсхәне күчерүчегә генә хас булган язылышлар да күренә. Мәсәлән, «ф» хәрефенең сүз ахырындагы язылышы «фә» рәвешлерәк итеп еш кабатланган. Шул сәбәпле, «Йосыф» исеменең «Йосыфа» дип укылу ихтималы бар. Шулай ук, кагыйдә буенча «әлиф» хәрефенә «р» ялганырга тиеш булмаса да, алар тоташтырып язылган сүзләр шактый. Бигрәк тә, «-лар» кушымчасында, «атар» кебек сүзләрнең ахырларындагы «р» хәрефләре үзеннән алдагы хәрефкә ялганган.

Сүз башындагы «у, ү, о, ө» авазларын белдергән «уау» хәрефе шактый очракларда язылмыйча, «әлиф» өстендәге «даммә» хәрәкәсе белән белдерелгән.

Өрелмәле «w» авазы кайбер очракларда ике ягындагы хәрефләргә тоташкан «ф» хәрефе белән белдерелгән. Мондый үзенчәлек Алтын Урда чорындагы әсәрләрнең кульязмаларында бар.

Тексттагы сүзләрнең хәрәкәләр белән язылуына күрә, алар куелмаган сүзләрнең дә гүя хәрәкә белән укылырга тиешлеге аңлашыла. Кульязмада бик күп булган андый мисалларның кайберләренә генә тукталабыз. Мәсәлән, «бәни» сүзе бу күчермәдә «бән» рәвешендә теркәлгән һәм бу очракта «нун» хәрефе астында кәсрә хәрәкәсе куелмаса да, аның бар кебек укылырга тиеш икәнлеге беленә. Күчермәдәге «сатмас» дип кенә язылган сүзнең исә чынлыкта «сатмаса» дип укылырга тиешлеге контексттан аңлашыла. «Сатун» сүзе хәрәкәләр куелганда ике хәреф

[12] Татар кульязмаларындагы мондый очраклар турында язылды: Мәрданов Р. Гарәп хәрефле татар кульязмаларының палеографик үзенчәлекләре..., 2024. – Б. 159–160.

белән – «с» һәм «т» белән генә язылып, «с» өстендә фәтхә һәм «т» өстендә «-ун» тәнвине белән теркәлгән. «Бити» (язу) сүзе дә ике тартык авазны белдергән «б» һәм «т» хәрефләре белән язылып, ул хәрефләр астында «и» авазлары өчен кәсрә хәрәкәләре куелган.

Кулъязмадагы «кан» дип кенә язылган сүзнең контексттан «канын» дип укылырга тиешлеге аңлашыла. Ягъни, бу очракта «н» хәрефе астында «ин»не белдерә торган тәнвин, гүяки, бар кебек укылырга тиеш. Текстта «каты» дигән сүз дә «қ» һәм «т» хәрефләре белән генә белдерелгән. «Кылурсән» сүзенең ахыры «с» һәм «әлиф» белән төгәлләнгән, димәк, «ән» кушымчасын тәнвин белән белдерү күздә тотылган. «Икән» дигән сүз дә, ахырында «ән» тәнвине белән укылуы күздә тотылып, кулъязмада «икә» дип язылган. Кайбер сүзләрдә тәшдид хәрәкәсе (бер авазны икеләтү билгесе) куелмаса да, укучы тарафыннан аның бар кебек күзалланырга тиешлеге аңлашыла. Мәсәлән, «коллар» сүзе «қ, л, р» хәрефләре белән генә, «сағәттә» сүзе «сағәт» дип, «михнәттән» сүзе «михнәт» дип язылган очраклар бар.

«Кыйссаи Йосыф» текстының борынгырак чорда хәрәкәләр белән язылган булуына бәйле рәвештә, кайбер сүзләрдә алар төшерелеп калдырылса да, соңгырак чор күчермәләрендә һәм басмаларда да сүзнең төп язылышы әүвәлгечә сакланган очраклар бар. Мәсәлән, 1983 елгы басмада бирелгән текстның 275 нче строфасында (108 биттә) «Һәм тәүәдән иңдерди, ат бендерди» дигән юл «3410т» кулъязмасында «Дәүәдән иңдерди, ата бендүрди» дип, ягъни «ата» сүзендәге соңгы хәреф «т» өстенә куелган фәтхә хәрәкәсе белән белдерелгән. Шулай ук «сәвеклү» сүзенең дә соңгы хәрефе кулъязмада теркәлмәгән, аның башлангычта «даммә» хәрәкәсе белән язылганлыгы аңлашыла.

Бу кулъязмада юлга сыеп җитмәгән ахыргы сүзләр (еш кына «имди» сүзе) юлның ахырында вертикаль итеп теркәлгән.

Хәрәкәләр белән язылган сүзләрнең 1983 елда басылып чыккан «Кыйссаи Йосыф» әсәре текстыннан аермалы урыннары да бар. Мәсәлән, әлеге кулъязмада «шул койудан су күтәрүң» дип, соңгы сүзе хәрәкәләр белән ачык аңлаешлы теркәлгән. Ә 1983 елгы басмада ул «шул койудан су кәтүрең» (хәзерге телдәге текстында «су алыгыз») диелгән. Коедан суны китерү яисә алуга караганда, «күтәрү» сүзе, мәгънә ягыннан төгәлрәк кебек.

Басма китаптагы кайбер сүзләрнең мәгънәләре төгәл бирелмәгән кайбер мисалларга тукталабыз. 1983 елда дөнья күргән китапның 92 битендәге 193 нче строфасында «Йусефи қойуда булмазлар имди» юлы хәзерге телгә күчермәсендә «Коеда Йосыф юклыгын күрер имди» (93 бит) дип бирелгән. Тик бу уңышлы түгел. Беренчедән, «юклыкны күрү» гыйбарәсе мантыйкка ярашсыз, икенчедән, «булмазлар» сүзе «тапмаслар» (тапмадылар) мәгънәсен белдергәнгә күрә, нәкъ шулай – «тапмадылар» дип бирелүе кулайрак. «3410т» санлы кулъязмада бу юл «Йосыфы қойу эчрә булмазлар имди» (1б кәгазь) дип теркәлгән.

Басма китапның 92 битендәге 194 нче строфасы бу рәвешле:

Анлар қачан бу мәғнәдән хәбәр белди,
Хәлқә идеб, ул кярвани чулғаб алди,
Әйдүр: «Безим қулумез қачмыш иди, –
Аны, байық, сез алмыш-сыз!» – дирләр имди.

Кулъязмада бу дүртьюллык бераз аермалы:

Ул мәлик бу мәғнәдән әхвәл белди,
Теркеләйү кәрванә анлар варди,
Әйдүр: «Безем бер қолумез қачмыш эди, –
Аны, байық, сез булмышсыз!» – дирләр имди[13].

Мондагы соңгы юлда язылган «булмышсыз» сүзе дә «тапкансыз» мәгънәсендә.

---

[13] Әлеге шигъри юл башка күчермәләрдә дә нәкъ шулай теркәлгән: 1121т (28а кәгазь), 1228т (6б кәгазь), 2744т (13а кәгазь). «Булмышсыз» сүзе урынында кайбер кулъязмаларда «алмышсыз» диелгән (404т, 589т, 3963т).




*«3410т» шифрлы кулъязма. 1а кәгазь.*



*1б кәгазь.*



*2а кәгазь.*



*2б кәгазь.*



*За кәгазь.*



*3б кәгазь.*



*4а кәгазь.*



*4б кәгазь.*



*5а кәгазь.*



*5б кәгазь.*



*6а кәгазь.*



*6б кәгазь.*



*7а кәгазь.*



مستجاب
دعاسی مستجاب قبول الدی
الوغ ساعت قار سولدی
بزاروبا سوالب براسکدی
ان کرا ملک عبرت آلب سکدی
ملک مملوکی جمله بسی بلور شدی
بلاسی جقاردی طونکیو دی
الونه کیجه الالی ویردی
جمله بکرنی یوسف مطیع الونک
بعد ان بادشاه انی بلنک
هیچ کمسه جقماس آننک بویرغندا
انداین کلکز یوسف حکیم الدی دوان
بیزلادکی یوسفنکا فهم ارثار
دنت جقیا جهاننی منور دنار
اندا اوتابلوسی شهرینه الکر دیه
الو شهر اهلی یوسفکو ردی
منو

محنت کیشب قار غمور سولدی احمدی
بغاد ارغان قار غمور ددلو دندی
کن اجلور جهان حرسم الور احمدی
باغ بوغفو یاغندین جمله شندی
قمو لرکا ملک آن توعا بلور احمدی
دوکا بندردی آج بندردی
خداوند اکرکا یوسفنک دیر للهر احمدی
الو کیجی قمو آنکا خدمت قلینک
مدام آننک امر بندکا جقمانک احمدی
الو حرمت ویردیلر کا ملک سبحان
ملک دغرکا دشب ایشلرا احمدی
سرلادالو لقفاشن شغلی ازتار
یکا هرکز جمله لنه دشمن احمدی
الو شهر اهلی جمله کا قد ادی
قمو لری غجابه قالور احمدی
جمله بسی

*7б кәгазь.*



جمله سی یوسفغه تابع در تشلر تا خالق صنع یوسف کورکالی کلدیلر

یوسف برلا ایلم سوزلشن تلار یوسفه حال احوال سورارلر ایردی

برداکلاسی بیله کیم بارلی بونک کبی کورکلو جمالی کیم کوردی

بو صورت سیننگدایر اکم بولی بارلر دغی انکا بند بولایم ایردی

یوسفا سوزین ایر اثغانم خالقدور بیر داکی قل ور لار اوزوق دور

بیر انکا رزق وبیرکالا یقدور بیسی مثل اول بیرلی بیلکلا ایردی

قوللرها اشبو سوزا ایناندیلر جمله سی بر تنکریکه ایمان کتوردیلر

هم یوسف پیغمبر ایناندیلر مومن مخلص الدیلر ایدیلر ایردی

انداکیچده بیان شهر بنه اتلرکیردیلر اول شهر اهلی یوسفنی کاکیر کوردی

یوسف بینکرا اوچ حاج اهلدیلر دکلاسی اول خاجه داپارلار ایردی

انداکیچده قدسی شهرینه اتلرکیردی قدسی ملک دوشندا اکن مشدا ایدی

قدسی ملک دوب قرشو واردی بک للدی نکر کیم دیو سورار ایردی

قدسی ملکی یوعبرتو قادنکلار اید رهر ایا بو ملک بندکیچا

شول کیم بو اول ادنه حکمت وار بو کا قرشو چیقماقا کیم کلدی یوق ایردی

امر بله چوق فرشته لار کلهشدی بو حال ایچره یوسف ابشدا الحیدی

8а кәгазь.



*8б кәгазь.*

1983 елгы басманың 217 нче строфасында (96 биттә) «Бонлар әйдүр: Йа Малик, боңа инан» дигән юлның кулъязмадагы: «Монлар әйтүр: Йа Малик, сән безгә инан» варианты мәгънә буенча дөресрәк дип аңлашыла. Чөнки хокуксыз бер колның сүзенә инануга-ышануга караганда, аны сатучылар сүзе өстенрәк булганлыгы табигый. Моны янәшәдәге 218 нче строфаның беренче юлында ук язылган «Йаланчидур, һич сүзинә инанмағыл» һәм 219 нчы строфадагы «Малик әйдер: Сүзеңезә бән инандым» дигән гыйбарәләр дә ачык раслый. Бу күчермәдә «безгә» дип ачык язылган сүзнең гарәп хәрефле текстта әүвәлге күчерүчеләр тарафыннан бары тик бер төгәлсезлек җибәрелүеннән – «з» хәрефенең «у» дип ялгыш танылуыннан «буңа» дип кабул ителгән. Башка кулъязмаларда бу юлның «Болар әйдүр: Йа малик! Антымыза сән инан» дип теркәлгән вариантлары да бар (мәсәлән, 1121т, 29б кәгазь).

Басмадагы 254 нче строфаның (104 биттә) башындагы:

Җанем уғул, бу җәфани нидән булдың,
Сәңа залим улан-ләрә нә сөч қылдың,

– диелгән ике юлы кулъязмада (5б кәгазьдә):

Җаным, уғлум, бу җәфайә нидән улдуң,
Сәңа җәвер қыйланләрә нә сөч қылдың14.

«Җәвер (кулъязмада: чәвер)» сүзе – «җәбер, рәнҗетү, золым кылу» мәгънәләренә ия.

Китапта 259 нчы строфа (104 биттә):

Қыйғырыр: «Хуаҗә!.. – әйдүр. – Дорсун кярван,
Әй, дәриғә, байық қачди бу қол уғлан».
Қафилә дорды ул дәм, ул арадан
Җөмлә кярван Йусефи эстәр имди,

– дип басылган. Кулъязмада ул бераз аермалы:

Қыйғурды, әйтүр хуҗа: «Дорсын кәрван!
Әй, дәриғә, байық қачмыш қол уғ(ы)лан».

[14] Милли китапханәдәге XVII гасырга караган «590т» кулъязмасында да (1а кәгазендә) бу юл шулай ук теркәлгән диярлек. Бары тик беренче юлында «бу җәфани нәдән булдуң» диелгән.

Қафилә дорыб дүнде ул арадан,
Җөмләләри Йосыфи эстәрләр имди.

Билгеле булганча, иске кулъязма текстларда тыныш билгеләре куелмаган. Алар соңрак текстологлар тарафыннан өстәлгән. Ләкин, безнең фикеребезчә, мәгънәви яктан кәрванны туктату турында аның хуҗасы гына әмер бирә алган, ә басмада исә ул фәрманны Кылыч исемле кол әйткән дип аңлашыла.

Басма тексттагы 267 нче строфа (106 биттә):

Малик әйдүр: «Халемез улды вәйран,
Йа-раббе, нидән улды безгә ушбу туфан?
Бардур безим арамездә бер мәзълум җан, –
Кэлең барча, истиғфар кылың имди».

Әлеге строфаның һәр юлында кулъязмадагы (7а кәгазьдә) текстан аермалы сүзләр бар:

Мәлик әйтүр: «Аһ, халемез улды йаман,
Йа, Рабб! Ишдән улды безә ошбу туфан,
Әй, дәриғә, ба[р]дур тәндә бу ғәзиз җан[15],
Килең барча, истиғфар кыйла[лы]м имди».

Басмадагы 275 нче строфаның (108 биттә) «Ходәвәнд, кярване Йусеф! – дәйүр имди» юлы кулъязмада (7б кәгазьдә) «Ходәвәндә! Кәрван Йосыфның! – дирләр имди»[16] рәвешендә. Бу очракта «кярване Йусеф» гыйбарәсенә караганда, әсәргә хас гадирәк тел белән «кәрван Йосыфның» сүзтезмәсе дөресрәк туры киләдер.

276 нчы строфадагы (108 биттә) «улуғ-кечи җөмләмез хезмәт кылың» дигән юл кулъязмада (7б кәгазьдә) «олу-ке-

---

[15] Әлеге шигъри юл 1782т (16а кәгазь) һәм 2068т (15а кәгазь) күчермәләрендә дә шулай ук язылган.

[16] Бу шигъри юл әсәрнең 486т (20б кәгазь), 2068т (15б кәгазь), 7666т (7а кәгазь) күчермәләрендә дә шулай ук теркәлгән. Ә 1859т күчермәдә (18а кәгазь) «Ходавәндә! Кәрван Йосыфи дирләр имди», 1782т күчермәдә (16б кәгазьдә) «Ходавәндә! Кәрван Йосыф сәнең дирләр имди» рәвешендә язылган. Казан университеты китапханәсендәге күчермәләрнең дә күпчелегендә «кәрван Йосыфның» дип, кайберләрендә «кәрван Йосыфың», «кәрван Йосыфи» һәм «кәрван Йосыфа» дип теркәлгән.

чи қәму аңа хезмәт кыйлың» дип теркәлгән. Ихтимал, бу очракта «қәму» сүзе белән язылган вариант дөресрәктер. Соңгысында иҗекләр саны да төгәл-тулы.

277 нче строфа (108 биттә) басмада:

Андан соңра Йусеф хөкме улди фәрман,
Улуғ мәнсаб вирди аңа мәлик-сөбхан,
Һич кемсәнә чыкмаз улди тәдбирендән, –
Малик Дәғир үзи дөшүб эшләр имди.

Бу дүртьюллык кулъязмада (7б кәгазьдә):

Андан соңра Йосфа хөкме улди рәван –
Олу хөрмәт вирди аңа Мәлик Сөбхан[17],
Һич кемсә чыкмаз аның бойруқындан, –
Мәлик Дуғар аңа дөшеб эшләр имди.

Әлеге строфаның беренче-икенче юлларында Йосыфка Аллаһының хөкеме – олы хөрмәте ирешүе турында әйтелгән. Ә басма текстның беренче юлында, «Шул вакыттан Йосыф сүзе булды фәрман» (109 бит) дип, бүтәнчә аңлашыла. Шулай ук, басмадагы «мәнсаб» (дәрәҗә) сүзенә караганда, «хөрмәт» сүзенең мәгънәсе өстенрәк.

Йосыф кыйссасының 1983 елгы басмасындагы 279–313 нче строфаларына карата 519–520 нче битләрдә бирелгән аңлатмаларда Фәләстыйннән Мисырга кәрван юлының Кол Гали әсәрендә беренче мәртәбә тәфсилләп тасвирланганлыгы (төрле шәһәрләрдә, Нил елгасы буендагы каналлар янында һ.б. тукталышлары) әйтелгән. Андый төгәл тасвир Библиядә һәм Коръәндә, хәтта Табарида да булмаганлыгы искәртелгән. 1983 елгы басма китапның 108–110 нчы битләрендә кәрванның төрле шәһәрләрдән узуына бәйле вакыйгалар тасвирланган. Ул калалар 279 нчы строфада «бер шәһәр», 284 нче строфада «дигәр шәһрә» (111 биттә: «бер шәһәргә»; дигәр – башка), 285 строфада «Қодес шәһәре»

[17] Бу шигъри юл әсәрнең башка күчермәләрендә дә шулай ук теркәлгән. Мәсәлән, 486т (20б кәгазь), 1228т (12а кәгазь), 1763т (17б кәгазь), 1774т (14а кәгазь), 1782т (17а кәгазь), 1859т (18а кәгазь), 2068т (15б кәгазь), 3963т (18б кәгазь).

дип аталганнар. Ә сүз бара торган «3410т» кульъязмасында (7б, 8а кәгазьләрдә) исә баштагы икесенең исемнәре дә бар. Беренчесе «Булуси шәһәре», икенчесе «Биин» шәһәре һәм өченчесе – басмадагыча «Қодес шәһәре» дип, барысы да исемнәре белән теркәлгән.

Басмада (279 строфада) «Андан үтди, бер шәһрә анлар керди» дигән юл кульъязмада «Андан үтә, Булуси шәһренә анлар керди» дип язылган. Ләкин бу шигъри юлда ике иҗек саны артыграк. Аларның берсе «Булуси» сүзендә икәнлеге аңлашыла, чөнки 285 нче һәм аннан соңгы строфалардагы «Қодес» атамасы да «Қодеси» һәм «Қодес» дип – ике төрле язылган. «Қодеси» дип язылган юлларда шулай ук иҗекләр саны артыграк. Димәк, «син» (с) хәрефенең ахырындагы ярымтүгәрәк дугасы бозыбрак («си» дип укырлык итеп) күчерелгән. Текстта «Булуси» (Булус) дип язылган шәһәр әсәрнең авторы тарафыннан һәм әүвәлгерәк кульъязмаларда «Набулус» дип язылган булса кирәк. Бу күчермә текстындагы «Андан үтә, Булуси шәһренә анлар керди» дигән шигъри юл башлангычта, ихтимал, бүтәнчәрәк тә булгандыр. Кала исеменең «На» иҗеге «үтә» дигән сүздән соң килгәнгә күрә, гарәп язуында бер-берсенә бик охшаш (бары тик бер нокта белән генә аерыла торган) ике иҗекнең берсе күчерүчеләр тарафыннан төшереп калдырылган булуы бик мөмкин. Андый очраклар аз түгел. Яисә бу юлдагы «үтә» дигән сүз үзе элекке нөсхәләрдә «На» иҗегеннән үзгәртеп күчерелгәндер. Бу фараз хак булса, әлеге шигъри юл башлангычта «Андан Набулус шәһренә анлар керди» рәвешендә язылганлыгы бик мөмкин.

Фәләстыйндәге Иордан елгасының көнбатыш ярында урнашкан Наблус (гарәпчә: Набулус) каласы безнең эрага кадәр якынча 1200 нче елда нигезләнгән дип исәпләнә. Ул шәһәр төрле дин тарафдарлары Йосыф пәйгамбәр кабере дип хөрмәтли торган изге урыннарның берсе белән дә шөһрәтле.

«Биин» шәһәре дигәне кульъязмада «Биан» рәвешендә теркәлгән. Аны «Бәйан» дип тә укырга мөмкин. Ләкин әсәрдә

тасвирланган урыннарда андый исемдәге шәһәр булганлыгы ачыкланмады. Бу атаманың «Биан» рәвешендәге язылышында иске палеографик үзенчәлекне күрәбез – «и» хәрефенең озын әйтелешле авазны белдергәнлеген тәгаенләү өчен «йа» хәрефеннән соң «әлиф» язылган булса кирәк. Бу җәһәттән «Биин» атамасының язылышы Идел буе болгарларының XIII–XIV гасырлардагы күпсанлы кабер ташларында «җиите» (җиде) санының уелышы кебек үк. Ягъни, «җиите» сүзендәге «и» авазының озын икәнлеген белдерү өчен шулай ук «әлиф» хәрефе өстәлгән. Беренче карашка аны да «җиат» дип укырга мөмкин. Монда тасвирлана торган кулъязманың 5б кәгазендәге «Атаң Йаґкуб бу әхвали белмәдимү» дигән шигъри юлның соңгы сүзендәге «ү» хәрефеннән соң аның озын әйтелешле икәнлеген белдерер өчен «әлиф» язылган[18]. Андый язылышлар әсәрнең башка күчермәләрендә дә очрый. Хәтта кайберләре басма текстларга да күчкән. Мәсәлән, поэманың 1884 елгы басмасындагы «тәмуг» сүзендә «у» хәрефеннән соң (озын аваз икәнлеген белдерү өчен иске кулъязмалардагыча) «әлиф» хәрефе язылган[19].

Биин дип атала торган кала – хәзерге Израильнең төньягындагы борынгы мөселман гарәпләр шәһәре. Гарәп телендә аның исеме Әл-Бигънә буларак та мәгълүм.

Кодес (Әл-Кодс) – Иерусалим шәһәренең гарәпчә атамасы.

Шушы әйтелгән өч шәһәрнең бер географик даирәдә урнашканлыгы һәм аларның «Кыйссаи Йосыф» әсәре күчермәләрендә урын алулары – кулъязма күчерүчеләрнең уйдырмасы гына булуы мөмкин түгел. Киресенчә, татар кешеләре өчен мөселман дини китапларында Кодес дип аталганы күбрәк очрап, Набулус һәм Биин дигәннәре ят атамалар булганлыктан, алары әсәр күчермәләренең бер өлешендә

[18] Элекке төрки телдәге озын авазларны белдерү өчен иске язма чыганакларда кулланылган андый үзенчәлекләр турында аңлатып язылды: Мәрданов Р. Гарәп хәрефле татар кулъязмаларының палеографик үзенчәлекләре..., 2024. – Б. 136–138.

[19] Китабе кыйссаи хәзрәти Йосыф галәйһиссәлам. – Казан: Кукубин табыгханәсе, 1884. – Б. 8.

«бер шәһәр» һәм «дигәр шәһәр» буларак кына телгә алынып киткән дип уйлыйбыз.

Бу шәһәр атамалары башка күчермәләрдә дә төрлечә язылган. Мәсәлән, Татарстан Республикасы Милли китапханәсендәге 1228т шифрлы кулъязмада алар нәкъ шулай – «Булуси» (12а кәгазьдә) һәм «Биин» (12б кәгазьдә) рәвешендә язылганнар. Бүтән нөсхәләрдә: 1121т кулъязмада «Булус» (33б кәгазьдә) һәм «Ниин» (Нийан, 34а кәгазьдә), 1763т кулъязмада «Булуш» (17б кәгазьдә) һәм «Нуйан» (18а кәгазьдә), 3963т санлы күчермәдә «Булус» һәм «Йунан» (икесе дә 19а кәгазьдә) дип теркәлгән. 1859т күчермәдә «Булус» (18а кәгазьдә) һәм «Ниин» (Нийан, 18б кәгазьдә), 1782т күчермәдә «Булус» һәм «Биин» (Бәйан, 17а кәгазьдә) һ.б. Башка күчермәләрдә (486т, 779т) «Булуш», «Булусән», «Бинан» һәм «Йәнан» рәвешле язылган.

«Кыйссаи Йосыф» әсәренең Казан (Идел буе) федераль университеты Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә саклана торган кулъязмаларында да әлеге калалар төрлечә аталган. Мәсәлән, 4380т шифрлы күчермәдә «Булус» (17а кәгазьдә) һәм «Миин» (Мийан, 17б кәгазьдә). Күчермәләрнең күпчелегендә (20-дән артыгында) «Булус» һәм «Биин» дип язылган. Бу исемнәрнең төрлечә вариантлары да: «Булуси», «Буллус», «Булусән», «Белүрсән», «Пилус», «Тулус», «Миин», «Ниин», «Тибән», «Йунан» кебек вариантлары да бар. Әсәрнең кайбер күчермәләрендә алар «бер шәһәр» һәм «дигәр шәһәр» буларак язылганнар. Ләкин андыйлары күп түгел.

Басманың 285–286 нчы строфаларындагы (110 биттә) «Қодес бике» күчермәдә (8а кәгазьдә) «Қодес мәлике» дип аталган. Мәсәлән, 286 нчы строфадагы «Қодес бике ләшкәр йиғыб, қаршу варди» дигән юл кулъязмада (8а кәгазьдә) «Қодес мәлике дорыб қаршу варди» дип теркәлгән.

Әсәрнең элеккерәк кулъязмаларындагы искергән яки аңлаешсызрак кайбер сүзләр күчерүчеләр тарафыннан җиңелрәк вариантлары белән алмаштырылган. Мәсәлән, сүз

бара торган кулъязмадагы 4а кәгазьдә «Хөрмәтең йегрәк сәнең бездән имди» юлындагы «йегрәк» сүзе «артык» сүзенә алыштырылган – «Хөрмәтең сәнең бездән артық имди» (227 нче строфа, 92 бит). Шулай ук кулъязманың (8б кәгазьдә) «Үлүр исә һәм билә үлүр имди» юлындагы «билә» сүзе соңгырак чордагы «бергә» дигән сүз белән алыштырылган – «Үләр ирсә йәнә бергә үләр имди» (287(2) нче строфа, 110 бит).

Басмадагы 270, 273, 282, 287(3), 287(4) һ.б. строфаларның кулъязма белән чагыштырганда шулай ук аермалары бар.

«Кыйссаи Йосыф» әсәре текстының «3410т» санлы кулъязма белән 1983 елгы басмадагы аермалы строфаларының һәм юлларының кайберләренә тукталып үтәбез. Бер яисә берничә сүзләре генә башкачарак булса да, текстологик җәһәттән аларны мөһим дип саныйбыз. Мисалларның кулъязмада ничәнче кәгазьдә теркәлгәне, басманың бите һәм строфа номеры күрсәтелде. Басма китаптагы вариантлар курсив белән бирелде. Мәсәлән, кулъязмадагы «Қолларындан икин қолә варыб әйде» (1а кәгазьдә) юлы басмада: «*Қол-ларындан ики қулә әмер қылди» (90 биттә, 184 нче строфада).*

Вә дуғлайу қуаләринә су тулдырды (1а кәгазь).

*Тулуғлайу қауғә-ләрин тулдурдиләр (92 бит, 186 нчы строфа).*

Җәбраил әйтүр: Имди үрә дорғыл,
Мөштәри хазир дорур, алур имди (1а кәгазь).
*Җәбраил әйдер: Халя хазир үрә дорғыл,*
*Мөштәри-ләр хазирдер, алур имди (92 бит, 188 нче строфа).*

Қолларына белдереб асмарлады (1б кәгазь).
*Қол-ларинә һәр дәуам сөйләр иди (92 бит, 190 нчы строфа).*

Варыб йитеб Йосыфуң әлин алди (1б кәгазь).
*Сәүенүбән Йусефең әлин алди (92 бит, 192 нче строфа).*

Сизенди, қатарлашу йөгерүб кәлди (1б кәгазь).
*Тәғҗил берлә қатарлашу йүгрүб варди (92 бит, 193 нче строфа).*

Хәсрәт-ү-ғәриб утына атармусез (2а кәгазь).
*Хәсрәт-ғөрбәт мәйданенә атарму-сез (94 бит, 199 нчы строфа).*

Ғөрбәт уды хәсрәтә вармайалум (2а кәгазь).
*Ғөрбәт уды бәгеринә йақмайалум (94 бит, 200 нче строфа).*

Әйде улар: «Саталым бу көн сәңа» (2а кәгазь).
*Әйдерләр: «Қули саталым бу күн сәңа» (94 бит, 203(1) нче строфа).*

«Сату нәчә қылавыз?» дәйүрләр имди (2б кәгазь).
*«Нәчүк сәүдә қылурмез?» дәйүр имди (96 бит, 209 нчы строфа).*

Мисырға тике бағлу варсун имди (3а кәгазь).
*Мисърә дикен боғаулу варсун имди (96 бит, 217 нче строфа).*

Дурмадан сәвекле, игү сүз сүзләмәгел (3а кәгазь).
*Һәргиз аңа изгү сүз сүзләмәгил (96 бит, 218 нче строфа).*

Шәмғун үзи кәндү әли бити йазди,
Бити йазды, қәмулардан фетнә уздырди.
Йосыфдин йөз дүндерди анлар, бизди
Пәйғәмбәри саттылар анлар имди (3б кәгазь).
*Шәмғун кәндү әлилә бети йазди,*
*Бети йазыб кәнделәрдән шәфкәт үзди.*
*Йусефдән йүз дүндереб, җөмлә бэзди,*
*Пәйғәмбәри қоллықғә сатар имди (98 бит, 221 нче строфа).*

Видағ қылыб айрулалым, бизәлем имди (3б кәгазь).

*Видағ қылыб айрылалум безләр имди (98 бит, 224 нче строфа).*

Һәм ул дағи Йосыфдин битәр йанар (3б кәгазь).

*Ул дәхи Йусефдән битәр ағлар (98 бит, 225 нче строфа).*

Бу ғибрәтә ғәҗаибә қалур имди (3б кәгазь).

*Бу мәгнәйә гәҗаибә қалур имди (98 бит, 225 нче строфа).*

Анлар сәни кем саттылар йармақға,
Деләдекләри сәндин айырылмақға...
Хөрмәтең йегрәк сәнең бездән имди (4а кәгазь).
*Анлар сәни сатдылар кәм йармақгә,*
*Деләкләри – байық сәндән айрылмақгә...*
*Хөрмәтең сәнең бездән артық имди (98 бит, 227 нче строфа).*

Бән шәфағәт кисмәсвән дәйүр имди (4а кәгазь).

*Һәр кеши үз лайықын ишләр имди (98 бит, 229 нчы строфа).*

Аһ, дәриғә, атам Йағқуб мәхрүм қалди[20] (4а кәгазь).

*Ва-вәйля, Исраилне мәхрүм қуйдум (100 бит, 232 нче строфа).*

Җөмләсенә исәнлек деләр, қочар-үбәр (4б кәгазь).

*Җөмлә-синә доға қылыб, видағ әйләр (100 бит, 238 нче строфа).*

Сәни кирү қәйра аңа илтүмәзвез (4б кәгазь).

*Сәни кирү атамызә илтүмәзез (100 бит, 241 нче строфа).*

[20] Башка күчермәләрдә дә шундый ук вариант бар. Мәсәлән, 1121т (31б кәгазь), 1228т (8б кәгазь), 3963т (15б кәгазь).

Сәвегем уғылум, сәңа нә халь тигде...
Йосыфым, сән бу халә дөштүң имди (5б кәгазь)[21].
*Йа, Йусуфем, хәлең нәтә буйлә улди...*
*Нэчүк гафил бу бәля-йә дүшдең имди (104 бит, 253 нче строфа).*

Бер гүр үзрә йөзин дүшәб ağлар имди (6а кәгазь).
*«Нәчүн буйлә қачарсен?!» – дәйүр имди (104 бит, 260 нчы строфа).*

Азар итмеш вар ирсә, күңел алуң (7а кәгазь).
*Азар итмеш кемсә-ңез, сафи улуң (106 бит, 267(1) нче строфа).*

Ул Қылыч ани ишетеб хазир килди (7а кәгазь).
*Шул уқ сағәт ул Қылыч хазир кәлди (106 бит, 269 нчы строфа).*

Малик Дуғар Йосыфа чуқ йалварди,
«Хатамызи кичерү виргел!» – дәйүр имди (7а кәгазь).
*Зари қылди Йусефә чуқ йалуарди,*
*«Хәтамези сән кәчүргел!» – дәйүр имди (108 бит, 272 нче строфа).*

Бәғдәзан бадишаһ аны белең (7б кәгазь)[22]
*Бәгда-зан мөқтәда аны белең (108 бит, 276 нчы строфа).*

Йосыфа биңзәтү хач әйләдиләр[23], –
Дөкүләси ул хача дабарлар имди (8а кәгазь).

---

[21] Милли китапханәдәге XVII гасырга караган «590т» кульъязмасында да (1а кәгазендә) бу юл нәкъ шулай теркәлгән.

[22] Милли китапханәдәге «7666т» кульъязмасында да (7а кәгазендә) бу юл нәкъ шулай теркәлгән.

[23] Китапханәдәге 486т (21а кәгазь), 779т (6б кәгазь) һәм 2068т (16а кәгазьдә) күчермәләрендә бу юл: «Йосыфа биңзәтү анлар хач әйләде» дип теркәлгән.

*Йусефә биңзәтү бер сурәт қылди, –*
*Җөмлә-си ул сурәтә тапар имди (110 бит, 284 нче строфа).*

Бәс, мәлик ушал сағәт хазир килде (8б кәгазь).

*Улуқ сағәт ушал бик анда килде (112 бит, 288 нче строфа).*

Бән – улвән, сәңа дөшдә бойурдылар (8б кәгазь).

*Бән – ул-мән, дүшдә сәңа белдердиләр (112 бит, 289 нчы строфа).*

Соңгы мисалдагы «улвән» язылышы һәм алдарак теркәлгән «қылавыз», «кисмәсвән», «илтүмәзвез» кебек сүзләр – борынгы төрки тел формалары. «Кыйссаи Йосыф» текстының телен тәфсилләп өйрәнгән галим Җәвад Алмаз андый төр кушымчаларны үзенең хезмәтендә нигезле итеп аңлаткан[24]. Ул шундый ук кушымчалардан «-вән» дигәненә «кәчәсәрвән», «сачасәрвән», «ачысәрвән» сүзләрен борынгырак төрки формалар мисаллары арасында күрсәткән[25].

«3410т» санлы кулъязма белән 1983 елгы басмадагы аермаларның бер өлеше түбәндәге чагыштырма таблицада күрсәтелә.

| *кулъязмада* | *1983 елгы басмада* |
|---|---|
| ташра (1а кәгазь) | тышра (92 бит, 186, 189 нчы строфалар) |
| хөкме улур (1а кәгазь) | хөкме ула (92 бит, 189 нчы строфа) |
| саталым (1б кәгазь) | сатам (92 бит, 196 нчы строфа) |
| үлдүрүрүз йукса (2а кәгазь) | үлдерермез йухсә (94 бит, 197 нче строфа) |

[24] Алмаз Дж. «Киссаи Юсуф» Али: сводно-сличительный текст списков поэм, перевод, словарь и исследования. – Казань, 1962. – Научная библиотека им. Н.И.Лобачевского Казанского (Поволжского) федерального университета. Восточный сектор Отдела рукописей и редких книг, рукоп. «5102т». – С. 174, 175, 219, 231, 262.

[25] Шунда ук. – Б. 72.

| | |
|---|---|
| шадкям (2а кәгазь) | шадлық (94 бит, 198 нче строфа) |
| сүзләдүк (2а кәгазь) | сөйләдек (94 бит, 201 нче строфа) |
| аңлайурвән (2б кәгазь) | аңлайурмен (96 бит, 208 нче строфа) |
| алурвән (2б кәгазь) | алурмен (96 бит, 208 нче строфа) |
| қабул һәм қылурвән (2б кәгазь) | қабул әйләйүрмен (96 бит, 208 нче строфа) |
| разый виргел (3а кәгазь) | рази улғыл (96 бит, 215 нче строфа) |
| йуқ дәйүрсәң (3а кәгазь) | «йуқ» дир ирсәң (96 бит, 215 нче строфа) |
| қолвән (3а кәгазь) | қол мән (96 бит, 216 нчы строфа) |
| бағ-боғағу шишмәгел (3а кәгазь) | бағ-буғавин чишмәгил (96 бит, 217 нче строфа) |
| деләйен (3б кәгазь) | деләйәлүм (98 бит, 224 нче строфа) |
| бу сүзләри иштеб (3б кәгазь) | бони ишедүбән (98 бит, 225 нче строфа) |
| учуз вирди (4а кәгазь) | учуз сатди (98 бит, 226 нчы строфа) |
| бәһайә алды (4а кәгазь) | бәһа илә (98 бит, 228 нче строфа) |
| андан бәрү (4б кәгазь) | мондан соңра (100 бит, 233 нче строфа) |
| дурғузуб, дөрлү (4б кәгазь) | уйғансам, түрлүк (100 бит, 235 нче строфа) |
| рәхәтдән (4б кәгазь) | ниғмәтдин (100 бит, 235 нче строфа) |
| қазғурур (4б кәгазь) | қайғырыр (100 бит, 238 нче строфа) |
| ишетеб ағлашалар (4б кәгазь) | күрүб ағлашдилар (100 бит, 239 нчы строфа) |
| чуғлашалар (4б кәгазь) | чуғлашдилар (100 бит, 239 нчы строфа) |
| улумазвыз (4б кәгазь) | улумазез (100 бит, 241 нче строфа) |
| илтүмәзвез (4б кәгазь) | илтүмәзез (100 бит, 241 нче строфа) |
| қылумазвыз (4б кәгазь) | улумазез (100 бит, 241 нче строфа) |
| нитәк улди (5а кәгазь) | нитә-леген (102 бит, 248 нче строфа) |
| йа анам (5б кәгазь) | йа анә (102 бит, 251 нче строфа) |
| өмид вар (6а кәгазь) | үмиддүр (104 бит, 255(1) нче строфа) |
| Ходавәндә (6а кәгазь) | Хода-йа (104 бит, 256 нчы строфа) |
| дүш килди (6а кәгазь) [26] | дуғри кәлди (104 бит, 257 нче строфа) |

[26] Милли китапханәдәге, XVII гасырга караган «590т» кульъязмасында да (1б кәгазендә) бу сүзләр нәкъ шулай теркәлгән.

| | |
|---|---|
| һəм малик улди (6а кəгазь) | вə солтанəт булди (104 бит, 257 нче строфа) |
| қачмыш (6а кəгазь) | қачди (104 бит, 259 нчы строфа) |
| дорыб дүнди (6а кəгазь) | дорды ул дəм (104 бит, 259 нчы строфа) |
| сөйрəр (6а кəгазь) | сүрəр (104 бит, 260 нчы строфа) |
| əмреңе рəва күрди (6б кəгазь) | əмреңə мотиғ улди (106 бит, 261(2) нче строфа) |
| Падишаһ (6б кəгазь) | Ходавəндə (106 бит, 263 нче строфа) |
| анчадан (6б кəгазь) | бу хальдə (106 бит, 264 нче строфа) |
| бер-берин (6б кəгазь) | берин-берси (106 бит, 266 нчы строфа) |
| тəпусына (7а кəгазь) | тəпуғинə (108 бит, 271 нче строфа) |
| бойруқындан (7б кəгазь) | тəдбирендəн (108 бит, 277 нче строфа) |
| һəмишə (7б кəгазь) | ғəля-д-дəвам (110 бит, 287(1) нче строфа) |
| олу фəрештə (8б кəгазь) | фəрештəлəр (110 бит, 287(3) нче строфа) |
| сəн ани белгел (8б кəгазь) | шул кеши-мəн, белгел (112 бит, 289 нчы строфа) |

Бу кульязмадагы «əйтүр, мəнем, бондан, дагы, игү, йырак, йукса» кебек сүзлəр 1983 елгы басма китапта «əйдүр, бəнем, мундан, дəхи, изгү, ирак, йухса» рəвешлəрендə булып, аларга охшаш бүтəн аермалар да күп.

Монда мисаллары китерелгəн, XVII гасырга нисбəтле «3410т» шифрлы кульязманың текстына XIX гасырның беренче яртысындагы «7666т» санлы күчермəнең тексты башкаларына караганда якынрак булуына игътибар иттек.

***

«Кыйссаи Йосыф» əсəре текстында кайбер строфаларның шигъри юлларында иҗеклəр саны күбрəк яисə кимрəк икəнлеге билгеле. Бу хакта Генрих Флейшер, Карл Броккельман, Җəвад Алмаз, Хатыйп Госман, Нурмөхəммəт Хисамов һ.б. галимнəр тарафыннан күп язылган. Поэманың төп шигъри юллары, автор үзе белдергəнчə, 12 иҗектəн тор-

са да, галимнәр 11 һәм 13 иҗекле юлларның да күплеген, хәтта тагын да азрак яки күбрәк санлылары барлыгын да искәрткәннәр. Бу мәсьәләне тәфсилле өйрәнгән Җ.Алмаз баштарак «моны күбрәк күчереп язучылар хатасы дип уйларга кирәк»[27] дип язган булса, аннары андый үзенчәлек, нигездә, автордан ук килгән дип, «Кыйссаи Йосыф» текстының көйләп укылу хасиятенә бәйләп аңлаткан[28]. Поэманың шигъри юлларындагы иҗекләр саны тотрыксыз булуы турында башка галимнәр дә «Мондый хәл кулъязма күчермәләрендә дә, төрле елларда чыккан басма нөсхәләрендә дә очрый. Әсәр юлларының хәреф-аваз санындагы бу төрлелекне тик күчерүчеләрнең яисә басучыларның хатасы дип кенә әйтеп булмый»[29] дигәннәр. Галим Хатыйп Госман, «Кыйссаи Йосыф» әсәрендәге 1010 дүртьюллыкның бары тик бер йөз кырыгы (13,86%) гына 12 иҗекле итеп язылганын, ә 870 дүртьюллыкта (86,14%) андый төгәллек сакланмаганлыгын күрсәтеп, мондый күренеш автордан ук килгән дип белдерде. Бу – Кол Галинең шигъри талантының үзенчәлеге һәм төрки шигърият үсешендәге яңа баскыч дип, мисаллар белән аңлатты[30].

Галимнәрнең фикерләренә каршы килмәгән хәлдә, мәсьәләнең торышын гамәли яктан тикшереп, кайбер иҗекләрнең чынлап та күчерүчеләр тарафыннан үзгәртелгәнлеген искәртәбез. Хәзерге – «Кыйссаи Йосыф»ның күчермәләре өч йөз чамасы булган чорда һәр кулъязманы, барлык фрагментларын да җентекләп тикшерү – әсәр

[27] Алмаз Җ. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» дастаны // Совет әдәбияты. – 1960. – №2. – Б. 99.

[28] Алмаз Дж. «Киссаи Юсуф» Али: сводно-сличительный текст списков поэм, перевод, словарь и исследования..., рукоп. «5102т». – С. 15–28.

[29] Борынгы татар әдәбияты / төз.: Х.Мөхәммәтов, Х.Хисмәтуллин, Ш.Абилов, Ү.Беляева, С.Исәнбаев. – Казан: Татар. китап нәшр., 1963. – Б. 94.

[30] Усманов Х. Тюркский стих в средние века. – Казань: изд-во ун-та, 1987. – С. 41–59; Усманов Х. Вклад Кул Гали в разитие тюркского стиха // Поэт-гуманист Кул Гали. Сб. статей: материалы юбилейных торжеств и научной конференции, посвящённых 800-летию со дня рождения и 750-летию его поэмы «Кысса-и Йусуф». – Казань: Татар. кн. изд-во, 1987. – С. 175–186.

текстына (шул исәптән, иҗекләргә) күчерүчеләр керткән үзгәрешләрнең шактыен күрергә мөмкинлек бирәчәк. Бу исә киләчәктә әсәрнең камилрәк басмасын хәзерләүгә нигез булыр иде. Монда «Кыйссаи Йосыф»ны киләчәктә өйрәнү мәсьәләләренә игътибар юнәлткән галим Р.Исламов фикерен искә алу да урынлы булыр. Ул болай дип язды: «Иң борынгы күчермәне ачыклау максатында хәзергә билгеле булган барлык нөсхәләрнең аерым-аерым (җыйнама түгел!) текстологик башкарылган тулы корпусын булдыру әһәмиятле. Бу күчерүчеләр тарафыннан текстларга кертелгән кайбер моментларны ачыкларга ярдәм итәчәк»[31].

Сүз бара торган «3410т» санлы кулъязмага күзәтү ясасак, анда кайбер иҗекләрнең тулы икәнлеге беленә. (Кайберләре алдагы мисалларда да күрсәтелде). Мәсәлән, 1983 елгы басма китапның 220 нче строфасында (98 биттә): «Қәбаләсен вирмәгә йазар имди» дигән, бер иҗеккә кимрәк юлы кулъязмада «Қәбаласын вирмәгә йаздылар имди» дип, иҗекләре тулы итеп теркәлгән.

Басма текстның 102 битендәге 245 нче строфада «Улдәм йулә Йусефи күндердиләр» шигъри юлының бер иҗеге ким. Ә кулъязмада (5а кәгазьдә) аның тулы рәвештә «Бәс Йосыфи ул дәм йулға күндердиләр» диелгәнен күрәбез.

Шулай ук басмадагы 255 нче строфаның (104 биттә) «Ибне-Йәмин сәнеңлә кәлмәдимү?» юлында бер иҗек азрак, ә кулъязмада (5б кәгазьдә) әлеге юл «Ибне-Йәбин сәнең биләә килмәдемү?» дип, иҗекләр саны төгәл рәвештә. Бу очрактагы «билә» сүзе «белән» теркәгече түгел, ә «бергә» дигәнне аңлата.

Басма китаптагы 255(1) нче строфаның (104 биттә) «сән дәғи рәхмәтә улғыл мөштақ» юлында ике иҗек кимрәк, ә кулъязмада ул «һәм дәғи рәхмәтенә булғыл мөштақ» диелгән, монысында бер иҗек җитми.

[31] Исламов Р. Йосыф кыйссасы һәм аны өйрәнү мәсьәләләре // Безнең мирас. – 2023. – №8. – Б. 59.

Китаптагы 106 битнең 261(2) нче строфасында «деләдисә сәүдегин, – дирләр имди» юлының бер иҗеге азрак. Ә кулъязмада (6б кәгазьдә) бу юл «деләдисә сәүдегени, – дәйүр имди» рәвешендә, ягъни иҗекләр саны камил.

108 биттәге 270 нче строфаның беренче юлы да бер иҗеккә кимрәк: «Малик андан диде ул қара қолә». Кулъязмада бу шигъри юлның күчерүче тарафыннан ялгыш төшереп калдырылган беренче сүзен өстәп укыганда, ул «[Малик] андан бойурды ул қара қола» дип, иҗекләре тулы булганлыгы аңлашыла.

208 нче строфаның (110 биттә) басмадагы «Җөмлә Йусеф қатынә дирнешдиләр» дигән юлы бер иҗеккә кимрәк, кулъязмада исә (8а кәгазьдә) иҗекләрнең саны төгәл: «Җөмләси Йосыф қатына дирештеләр».

Басмадагы 287(2) нче строфаның (110 биттә) беренче юлында: «Адәм уғлы илә бер пәри улур имеш» дигәндә бер иҗек артык икәнлеге күренә. Кулъязмада (8б кәгазьдә) иҗекләр саны дөрес: «Адәм уғлы берлә пәри улур имеш».

290 нчы строфадагы (112 биттә) «Бу сүзи ишедеб ғәҗәбләде» юлында ике иҗек кимрәк, ә кулъязмада (8б кәгазьдә) иҗекләр саны тулы: «Мәлик бу сүзи ишетеб ғәҗәбләде». Шул ук строфаның ахыргы юлы да басмада бер иҗеккә азрак: «Әғзаз әйләб, мөкәррәм дутар имди», бу юлның иҗекләре кулъязмада дөрес: «Мөхтәрәм-ү-мөкәррәм дотарлар имди». Текстларны чагыштырганда мондый мисалларның тагын да барлыгы күренә.

Әсәр текстындагы Йосыф коесының сыйфатларын тасвирлаган бүлекнең беренче юлында – 1983 елгы басманың 72 битендәге «Ул қойу ашнудан калмыш иде» дигән 108 нче строфасында ике иҗек кимрәк икәнлеге күренә. Ә күчермәләрдә иҗек саннары тулырак вариантлары бар. Мәсәлән, 343т кулъязманың 1б кәгазендә, 486т кулъязманың 9а кәгазендә һәм 1859т күчермәнең 5б кәгазендә ул шигъри юл бер иҗеккә артыграк итеп – «Бәс ул қойу ашнудан калмыш иде» дип теркәлгән. Әсәр кулъязмаларында текстның

иҗек саннарын төзекләндерердәй урыннар шактый. Бу мәкаләдә без аларның кайберләрен күрсәтү белән чикләндек.

Мәкаләдә санап үтелгән текст аермаларының бер өлеше, алда әйткәнебезчә, «Кыйссаи Йосыф»ның бүтән күчермәләрендә дә очрый. Ләкин монда тасвирланган «3410т» кульязмасы, әсәрнең хәзергәчә сакланып калган иң элеккеләреннән берсе буларак, аеруча әһәмиятле. Дөрес, кайбер фаразлар әсәрнең башка күчермәләрен тәфсилләп өйрәнү нәтиҗәсендә расланырга яки кире кагылырга мөмкин.

Алда әйтеп үтелгәнчә, бу мәкаләдә бөтен төр аермаларны һәм үзенчәлекләрне тасвирлау максаты куелмады. Монда язылган һәм әйтелмәгән хасиятләрне белгечләр «3410т» шифрлы кульязманың шушы мәкалә белән бергә бирелгән тулы факсимилесыннан үзләре дә күрә алалар.

XVII гасырдагы кульязмада теркәлгән «Кыйссаи Йосыф» күчермәсен тикшереп чыгу нәтиҗәсендә, әсәрнең басылган текстына кайбер искәрмәләр һәм төзәтмәләр кертүнең зарурлыгы күренә. Поэманың төп текстына күчерүчеләр керткән өстәмәләр дип исәпләнгәннәренең XVII гасыр кульязмасында теркәлгәнлеге – «Кыйссаи Йосыф» андый текстологик үзгәрешләргә бик күптәннән дучар булганын күрсәтә. Бу мәсьәлә дә бик мөһим.

Әсәрнең Милли китапханәдәге XVII гасырга караган тагын ике фрагментына да кыскача тукталыйк. «590т» һәм «591т» шифрлары белән билгеләнгән бу фрагментларның язулары, беренче карашка, бер үк кульязманыкы кебек. Аларны бер үк кеше кулы белән язылган дип тә фаразларга була. Ләкин тәфсиллерәк тикшергәч, бу ике фрагмент «Кыйссаи Йосыф»ның ике күчермәсенеке булганлыгы аңлашыла. Моның дәлилләре:

1) ике текстның юл аралары бер-берсенә тәңгәл түгел («591т» кульязманыкы тыгызрак) һәм «590т» шифрлы күчермәнең һәр битендә 15 шигъри юл булса, «591т» санлысында 17 шигъри юл;

2) һәр строфа ахырында кабатланган «имди» сүзе «590т» кулъязмасында «имди» дип (сүз башында ике нокталы «и» хәрефе белән) язылган, ә «591т» күчермәсендә сүз башындагы «и» хәрефе теркәлмәгән. Анысын «эмди» дип укырга да мөмкин;

3) сүз уртасында ике ягыннан да кушылып язылган «һ» хәрефенең әлеге кулъязмаларда ике төрле икәнлеген күрәбез. «591т» күчермәсендә ул гадәти – ярымтүгәрәкләре юлның өстендә һәм астында итеп, ә «591т» кулъязмасында «һ» хәрефе сүз уртасында да сүз башындагыча – бөтерчек рәвешендә теркәлгән;

4) шигъри юллар тигез-тулы булсын өчен кайберләренә өстәлгән гади бизәкләр ике кулъязмада ике төрле. Ягъни, «590т» текстында ул кечкенә өч түгәрәк (икесе аста, берсе өстә) рәвешендә, ә «591т» күчермәсендә «һәмзә» сыман икешәр тамга ясалган.

Болардан тыш, кайбер хәрефләрнең элементлары язылышында да аермалар күренә.

Ике текстны язган кешеләр бер үк остазның шәкертләре булып, бер-берсенә бик охшаш язу-почеркка ия булулары да ихтимал икәнлеген искәртик. Тарихта андый очраклар билгеле.

Әйтелгән ике күчермәнең кайбер үзенчәлекләрен бу мәкаләдә искәртеп үттек. Шуларга өстәп әйтсәк, «591т» шифрлы фрагментның 1а кәгазендә «Илһам бәрди Йосыфа Қадыйр Уған» юлы 1983 елгы басмада 544(2) нче строфада (168 биттә) «Илһам бирди Йусефә қадир дәййан» диелгән. Күрәсең, Аллаһының «Уган» дигән исеме архаиклашып, күчермәләрдә бүтән сүз белән алыштырылгандыр. Шул ук кулъязманың 1а кәгазендәге «Гүр эчендә гирифтар әсир қылам» һәм 1б кәгазендәге «Қортарам сәни Зөләйха михнәтендән» дигән юллары басмада «Гүр ичиндә гирифтар аны қыйлам» (168 биттәге 545(1) нче строфа), «Бән қортарам Зөләйха фитнәсендән» (170 биттәге 547 нче строфа) рәвешендә бирелгән.

Гомумән, «Кыйссаи Йосыф» кебек тиңсез дәрәҗәдәге кыйммәтле әдәби ядкярнең һәрбер күчермәсе текстологик яктан тәфсилле тикшерелеп, ачыкланган нәтиҗәләр әсәрнең яңа басмаларында аңлатылырга һәм кулланылырга тиеш дип саныйбыз. Һичьюгы әсәрнең әүвәлгерәк чордагы күчермәләрендә хәрәкәләр белән язылуга бәйле булган кайбер сүзләрнең язылышларына һәм тексттагы иҗекләр санының төгәллегенә карата искәрмәләр булса да өстәлүе зарур.

«Кыйссаи Йосыф»ның фундаменталь басмасын яңадан нәшер иткәндә текстолог галимнәрнең, төрле кулъязма күчермәләрдәге үзенчәлекләргә әһәмият биреп, аларны тулырак куллануларын телибез.

# РЕЗЮМЕ

Тридцать седьмая книга серии «Татарская археография» представляет собой описание рукописей поэмы Кул Гали «Кысса-и Йусуф», хранящихся в Отделе рукописей и редких книг Национальной библиотеки Республики Татарстан.

Поэма «Кысса-и Йусуф», являющаяся выдающимся средневековым литературным памятником волжских булгар-татар, сохранилась до наших дней в многочисленных рукописных списках. Из года в год обнаруживаются новые списки. По нашим подсчётам, сегодня известны около 300 рукописей «Кысса-и Йусуф».

В настоящее время в фондах Национальной библиотеки Республики Татарстан хранятся 43 списка поэмы Кул Гали. Они были приняты в фонды в 1990–2023 годах сотрудниками Отдела рукописей и редких книг в результате проведённых археографических изысканий, а также во время объединённой научно-археографической экспедиции Национальной библиотеки Республики Татарстан и Казанского государственного университета. Списки поэмы «Кысса-и Йусуф» обнаружены в Казани (четырнадцать рукописей), Уфе (три рукописи), Тобольске, а также в г.Буинске, в Арском, Атнинском, Апастовском, Агрызском, Тюлячинском и Ютазинском районах Татарстана, в Татышлинском районе Башкортстана, в Бардымском районе Пермской области, в Моркинском и Параньгинском районах Республики Марий Эл, в Комсомольском районе Чувашской Республики, в четырёх районах Пензенской области, в Шенталинском районе Самарской области.

Самыми древними списками поэмы, представленными в фондах библиотеки, являются три рукописи (из них два

– фрагменты), относящиеся к XVII веку. Шесть единиц относятся к XVIII веку, большинство же (30 рукописей) датируются первой половиной XIX века. Одна рукопись 1856–57 годов, и три единицы – списки XX века. Последние являются доказательством многовековой письменной традиции поэмы.

Описания рукописей в настоящем издании соответствуют общепринятым правилам. Вместе с тем имеются и некоторые особенности. Например, к указанным начальным и конечным строфам списков поэмы дополнительно дана информация о соответствии их печатному тексту «Кысса-и Йусуф» 1983 года издания.

Кроме описаний рукописей в сборнике представлены обзорная статья, именной, географический и другие указатели. Книга включает в себя и образцы факсимиле рукописей.

В конце книги приведена статья, посвящённая палеографическому и текстологическому особенностям рукописи поэмы, относящейся XVII веку. Там же размещено полное факсимиле этого списка, хранящегося в Национальной библиотеке Республики Татарстан.

# «ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ» СЕРИЯСЕНДӘ ЧЫККАН КИТАПЛАР

(Төзүчесе – археограф, текстолог Раиф Мәрданов;
«Милли китап» нәшрияты)

**Мәүла Колый поэмалары: «Береккәннәр сыйфаты»; «Хәләл нәфәка эстәгәннәр сыйфаты».** – Казан, 2008. – 88 б. – (1 нче китап). Шул ук. Икенче басма. – Казан, 2011. – 88 б.

**Түләк китабы: дастан.** – Казан, 2008. – 76 б. – (2 нче китап).

**«Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кульязмаларына тасвирламалар.** – Казан, 2009. – 92 б. – (3 нче китап).

**Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасы: әсәрнең Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кульязмалары.** – Казан, 2009. – 128 б. – (4 нче китап).

**Мәрданов Р. Китапларда милләт язмышлары...** – Казан, 2010. – 92 б. – (5 нче китап).

**[Мөхәммәтәмин]. Кыйссаи Мансур.** – Казан, 2010. – 128 б. – (6 нчы китап).

**[Фәезханов Хөсәен]. Кыскача татар тарихы.** – Казан, 2011. – 68 б. – (7 нче китап).

**Сәяхәтнамәләр.** – Казан, 2011. – 84 б. – (8 нче китап).

**Шанхай Төрк-татар мәдәният җәмгыяте.** – Казан, 2012. – 184 б. – (9 нчы китап).

**Кыз хикәяте.** – Казан, 2012. – 184 б. – (10 нчы китап).

**Сөрген хатлары.** – Казан, 2013. – 103 б. – (11 нче китап).

**«Гәүһәр Болгарга килдем...»: тарихи бәетләр.** – Казан, 2013. – 128 б. – (12 нче китап).

**«Без плиндә ятамыз читлектәге кош кебек...»: Беренче бөтендөнья сугышы бәетләре.** – Казан, 2014. – 119 б. – (13 нче китап).

**Гали авылы тарихы.** – Казан, 2014. – 164 б. – (14 нче китап).

**Тинчурин К. Каракүз: музыкаль мелодрама; Нәни абый: комедия.** – Казан, 2015. – 192 б. – (15 нче китап).

**Тинчурин К. Чит илләрдә: хыялый комедия.** – Казан, 2015. – 108 б. – (16 нчы китап).

**[Мөхәммәтәмин]. Гыйлем Хакка илтер.** – Казан, 2016. – 124 б. – (17 нче китап).

**Сугыш һәм солдат бәетләре.** – Казан, 2016. – 264 б. – (18 нче китап).

**Дастане җайә (Мәликә китабы).** – Казан, 2017. – 148 б. – (19 нчы китап).

**Матрос Әхмәдулла дәфтәре: 1898–1906 еллар.** – Казан, 2017. – 140 б. – (20 нче китап).

**Алдым каләм, яздым сәлам...: хатлар.** – Казан, 2018. – 180 б. – (21 нче китап).

**Солдат Ярулла дәфтәре: бәетләр һәм мөнәҗәтләр. 1905–1906 еллар.** – Казан, 2018. – 92 б. – (22 нче китап).

**«Чыңгызнамә»: тарихи дастаннар.** – Казан, 2019. – 288 б. – (23 нче китап).

**Халык җырлары: XVII–XX гасырлар.** – Казан, 2019. – 146 б. – (24 нче китап).

**Бөек Ватан сугышы хатлары, солдат хатирәләре: Җиңүнең 75 еллыгына.** – Казан, 2020. – 276 б. – (25 нче китап).

**Бакый Урманче көндәлекләре: 1965–1976 еллар.** – Казан, 2020. – 218 б. – (26 нчы китап).

**Шигъри ядкярләр: XII–XIX гасырлар.** – Казан, 2021. – 252 б. – (27 нче китап).

**Шәҗәрәләр.** – Казан, 2021. – 196 б. – (28 нче китап).

**«Утызынчы елларда...»: халык тормышының фаҗигале сәхифәләре.** – Казан, 2022. – 180 б. – (29 нчы китап).

**Милли китапханәнең археографик экспедицияләре: 30 еллык тәҗрибә.** – Казан, 2022. – 250 б. – (30 нчы китап).

**Җәбәли Минһаҗетдин. Тәварихы Болгарийә вә татарийә.** – Казан, 2023. – 234 б. – (31 нче китап).

**Килешү-хокук язмалары (XVIII–XX гасыр башы).** – Казан, 2023. – 224 б. – (32 нче китап).

**Нигъмәтулла Солтанбәков әсәрләре.** – Казан, 2024. – 248 б. – (33 нче китап).

**Раиф Мәрданов. Гарәп хәрефле татар кульязмаларының палеографик үзенчәлекләре.** – Казан, 2024. – 248 б. – (34 нче китап).

**Мөхәммәдьярның «Нуры содур» әсәре.** – Казан, 2025. – 316 б. – (35 нче китап).

**Мәүла Колый иҗаты: яңа табышлар.** – Казан, 2025. – 216 б. – (36 нчы китап).

# ЭЧТӘЛЕК

Кол Гали иҗат иткән «Кыйссаи Йосыф» әсәренең Татарстан Республикасы Милли китапханәсендәге кулъязма күчермәләре......3

Кулъязмалар тасвирламалары ............................................................21

Исемнәр күрсәткече ........................................................................136

География атамалар күрсәткече ......................................................139

Кулъязмаларның күчерелгән вакытлары........................................142

Кулъязмаларның китапханәгә алынган вакытлары........................144

«Кыйссаи Йосыф» әсәренең XVII гасыр күчермәсе (палеографик һәм текстологик үзенчәлекләр)................................146

Резюме ..............................................................................................189

«Татар археографиясе» сериясендә чыккан китаплар ...................191

# ОПИСАНИЕ РУКОПИСЕЙ ПОЭМЫ «КЫССА-И ЙУСУФ» КУЛ ГАЛИ, ХРАНЯЩИХСЯ В НАЦИОНАЛЬНОЙ БИБЛИОТЕКЕ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

(на татарском языке)

Составитель: Раиф Марданов
Ответственный редактор: Ирек Хадиев
Оформление: Ирина Мещанинова

Басарга кул куелды 01. 06. 2026. Форматы 60х84 1/16.
Тиражы 100 данә. Заказ № 510.
Татарстан Республикасы Милли китапханәсе.
«Милли китап» нәшрияты.
420015, Казан шәһәре, Пушкин ур., 86.

Подписано к печати 01. 06. 2026. Формат 60х84 1/16.
Тираж 100 экз. Заказ № 510.
Национальная библиотека Республики Татарстан.
Издательство «Милли китап».
420015, г. Казань, ул. Пушкина, 86.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең
редакция-нәшрият бүлегендә басылды.

Отпечатано в редакционно-издательском отделе
Национальной библиотеки Республики Татарстан.

[illegible]

حال وقت ده [illegible]

[illegible] معلوم [illegible] قيلمش ايدى

[illegible] اول ذو الحميد [illegible] بيلدى

[illegible] اردن [illegible]

[illegible] يوسفي آرر [illegible]

[illegible] آنلر [illegible] قيلدى

[illegible] آنلر دخی پيغمبر [illegible] بيلدى

[illegible] يوسفي جمالی كوردكده [illegible]

[illegible] اول ذو الحميد اول [illegible]

[illegible] اجابت دعا قيلدى اول [illegible]

[illegible]

[illegible]

اول ذو الحميد حق تعالى حضرتنه دعا قيلدى

[illegible]

اول ذو الحميدك دعاسى سبب قبول [illegible]

اول ذو الحميدى [illegible]

[illegible]

[illegible] آنده [illegible]

[illegible] طاعت قيلدى [illegible]

[illegible] آردى [illegible]

[illegible]